Мәдәни җомга

www.madanizhomga.ru

Татарстанда язылу индексы – П2355.

№ 29 (1445) 28 июль 2023 ел

БЕЗ СОЦИАЛЬ ЧЕЛТӘРЛӘРДӘ:
madani_zhomga
madanizhomga
madani_zhomga

1995 елның июленнән башлап чыга

1-4

Курган өлкәсендә 228 йорты янып беткән Эчкен авылына Татарстан хөкүмәте трактор һәм велосипедлар бүләк итте.

14-15

Цирк артисты Хәсән Мусин үз заманында Олег Попов, Юрий Никулин кебек клоуннар белән бер дәрәҗәдә популяр булган.

16-17

Бөек Тукайның якын дусты булган шагыйрь Сәгыйть Рәмиевнең исемен һәм иҗатын яңа арабызга кайтарырга кирәк.

Бергәлектә яшәү фарыз безгә Шатлыкта да, кайгы килсә дә!..

БЕР ҖӨМЛӘ БЕЛӘН...

- Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов традицион киңәшмәдә төбәк муниципалитет башлыкларына Украина махсус операция вакытында һәлак булган һәм «Россия Герое» исеме белән олыланган – 4, шулай ук вафатларыннан соң Батырлык ордены белән бүләкләнгән 200 дән артык якташыбызның исемнәрен мәңгеләштерергә кушты.

- Татарстан Республикасының Дәүләт киңәшчесе Минтимер Шәймиев Якутиянең «Олонхо театры» спектаклен карады һәм, артистларга баш иеп, рәхмәт сүзләрен җиткерде.

- Агымдагы елның 1 августыннан эшләүче пенсионерларга иминият пенсиясенең күләме арта һәм ул элеккеге 123,77 сум урынына максималь рәвештә 372,31 сум булыр дип көтелә.

- Республиканың Арча районындагы Ташкичү авылында «Сөлгеле капка» ачык фольклор фестивале булып узды.

- Мәскәүнең «Времена года» сәүдә йортында кайнар су торбасы шартлагач, 4 кеше пешүдән вафат булган, 70 кеше тән җәрәхәтләре алган.

- Донецк халык республикасының элеккеге оборона министры булган Игорь Гиркин (Стрелков) экстремизмда гаепләнеп кулга алынды.

- Татарстан Республикасының Тикшерү комитеты Казан янындагы Көек һәм Царево бистәләрендәге мәктәп һәм бакчаларда урын җитмәү сәбәпле җинаять эше ачты.

БЕЛЕП ТОРЫГЫЗ

29 июль – шагыйрә Фәридә Атилла кызы Рәсүлеваның тууына 75 ел (1948–2022).

30 июль – каллиграф, график, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстанның Г.Тукай исемендәге дәүләт бүләге лауреаты Нәҗип Фәйзрахман улы Нәккашка (Исмәгыйлевкә) 75 яшь (1948).

1 август – җәмәгать эшлеклесе, тарих фәннәре докторы, ТАССРның атказанган мәдәният хезмәткәре, Бөтендөнья татар конгрессының Милли Шура әгъзасы Ринат Зиннур улы Закировка 75 яшь (1948);

– Татарстан Республикасының халык шагыйре, җәмәгать эшлеклесе, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе, Г.Х.Андерсен исемендәге Халыкара Почётлы диплом иясе, Татарстанның Г.Тукай исемендәге дәүләт бүләге лауреаты Роберт Мөгаллим улы Миңнуллинның тууына 75 ел (1948–2020).

СЫНАМЫШЛАР

- Августта имән чикләвеге күп булса, игеннәр уңа.
- Томан озак таралмаса – көн аяза.
- Августта яшенле яңгырлар күп яуса, көз озын килә.
- Август яңгырсыз булса, көз җылы һәм коры килә.
- Эт үлән ашаса, яңгыр бик озак явар.

КОЯШ СӘГАТЕ

Бүген кояш **3 сәгать 41 минутта** чыкты, һәм ул **20 сәгать 01 минутта** офык артына күмеләчәк. Көн озынлыгы – **16 сәгать 20 минут.** Алдагы җиде көн дәвамында тәүлекнең якты вакыты **27 минутка** кыскарачак һәм киләсе җомгада, ягъни **4 августта 15 сәгать 53 минут** тәшкил итәчәк.

СӘЛАМӘТЛЕК КӨН ДӘ КИРӘК

Июль-августның магнитлы авыр көннәрендә хезмәттәшләрегез, якыннарыгыз сәламәтлегенә һәм, әлбәттә, үз-үзегезгә аеруча игътибарлы булыгыз. **Андый көнне исегезгә төшерәбез: 1 август.**

* * *

Гадәттә, айның беренче чирегеннән тулы айга кадәр **(26 июль – 1 август)** организм киңәюгә бара. Мондый көннәрдә организмны, бигрәк тә бавырны чистартуга бәйле процедуралар үткәрү файдалы.

ҺИҖРИ БУЕНЧА 1445 ЕЛ

Бүген мөхәррәм аеның 10 нчы көне

КӨН КАДАГЫНА

ЭЧКЕНГӘ ТОРМЫШ КАЙТА

7 май кичендә Курган өлкәсенең Эчкен – Йолдыз авылында булган янгын турында ишетмичә калган татар бик сирәктер. Ул коточкыч каза барышында авылдагы 228 йорт ихаталары белән бергә янып бетте, 7 кеше һәлак булды. Эчкен генә түгел, күрше авылларда да янгыннар дистәләгән йортны харап иткән. Эчкен – электән сакланып калган, үз йөзе, сөйләме, менталитеты булган татар авылы. «Йолдыз» исеме дә аңа Советлар заманында гына береккән. Чын һәм тарихи исеме – Эчкен.

Янгыннан соң авыл өстеннән сугыш үткән кебек. Йортлардан кирпеч моржалар гына күренеп тора, бөтен җирдә көл, төтен исе, һәр тарафта янган агач, металл, кешеләрнең гомер буе җыйган малы җәелеп ята.

Июнь ае башында без бу авылга тагын бардык. Ул чакта авылдагы тынлык, бушлыктан җан өшеп куйды. Бер ай элек кенә гөрләп яшәгән авыл дөнья йөзеннән юкка чыккан кебек, шомлы иде.

Янгыннан соң ике ай узгач, ТР Премьер-министр урынбасары, Милли шура рәисе Васил Шәйхразыев авылда Милли шураның күчмә утырышын үткәрергә, дип, вәкилләрне туплап, Эчкенгә алып килде. Шура вәкилләре, беренче эш итеп, янгында сакланып калган авыл мәчетенә кереп, дога кылды. «Җитди эшләрне без ике рәкәгать намаз укып, мәрхүмнәр рухына дога кылып башларбыз», – диде авылның имам-хатыйбы Әхмәдулла хәзрәт Хәбибуллин.

Ике айдан соң авылда балта, бензин пычкысы тавышлары ишетелә. 40 ка якын йортның төзелеше башланган, калганнары үз чиратын көтә, яки язмышына буйсынган. Искә төшереп үтәм: халыкның кайберләренә, Курган өлкәсенең Төзелеш министрлыгы стандартлары буенча, өйнең квадрат метры, ничә кеше яшәвенә карап, 1 миллионнан 4 миллионга кадәр сертификат бирелде. Ул сертификатлары булган кешеләргә дәүләт, яки шәхси подряд оешмалары йорт төзи. Икенче төр категория кешеләргә бары 500 мең генә эләккән, чөнки документлар буенча алар йә теркәлмәгән, йә тагын нииндидер матавыклары бар. Бу кешеләр белән подряд оешмалар килешү төземи, чөнки акчалары аз. Күбесенә эшмәкәрләр ярдәм итә. Өченче категориягә караучыларга бернәрсә дә эләкмәгән. Тик хакимият аларны да урамда калдырмаска вәгъдә итә.

Авылда төзелеш эшләре башлану керү юлыннан ук күренеп тора. Фундамент салынган, дивары бераз күтәрелә башлаган йортлар байтак. Үзе белән «фамилиям рус булса да, үзем татар» дип танышуручы Ирина Кондинаның да яңа йорты төзелә башлаган. Аңа Төзелеш министрлыгы стандартлары буенча 2,4 миллион һәм ихата өчен өстәмә 700 мең биргәннәр. Янган өе зур, ике катлы була аларның. «Үзебез дә өстәячәкбез, чөнки ул гына житми», – ди Ирина. Йортны аларга 15 октябрьгә тапшырачаклар.

– Бозауларым, үрдәкләрем янып үлде, дип, сыктап йөргән идем. Хәзер менә сөенәм. Атларым исән минем. Бәлки, берәр ничек ашлык белән булышып җибәрерләр. Яңгыр булмагач, печән дә корый. Ат абзарын эшләп чыга алырбызмы, юкмы, анысын белмим. Шиферлар алып кайттым, навес ясап, шунда биклэп торырбыз инде, – дип сөйләде Ирина Кондина.

Күршесендә генә авылның имам-хатыйбы Әхмәдулла Хәбибуллин йортына фундамент салынган. Аңа йортны Риат Фәйзуллин җитәкчелегендә Төмән эшмәкәрләре салыша. Алар авылда 2 гаиләгә йорт салып бирәчәк.

– Янгыннан соң төрле хисләр булды, күңелләр дә кайтып алды. 18 майда Казанда күрешеп сөйләшкәч, күңелгә рәхәт булып китте. Безнең «брат» Ринат Насыйров оешмалар барлыгын әйтте. Ринат Риатка чыкты, Риат бөтенесен җыйнады. Аллаһ Тәгаләнең рәхмәте белән эшләр бара, – ди Әхмәдулла хәзрәт.

Төмән егетләре үзләре дә дини. «Эшне Аллаһка тапшырып эшләсәң, җае чыгачак», – дип җөпли Абдулла Арсланов. – Берәр нинди мәшәкать булып, без Аллаһка мөрәҗәгать итсәк, аның ярдәме килә башлый. Монда бары бер шарт: без аны Аллаһка тапшырып башласак, Аллаһ Тәгалә ярдәмен бирә. Иң мөһиме – башларга кирәк. Мәчетләр салганда да шулай безнең: смета юк, мөмкинчелек юк, акча җитәме-юкмы икәнен дә белмибез. Башлап җибәрсәң, як-яктан ярдәм дә килә башлый. Кемдер бетон бирә, кемдер тәрәзә куя. Эшне Аллаһ Тәгаләгә тапшырып башларга кирәк. Шул очракта ярдәме дә килә аның», – ди ул.

Сертификат ярдәмендә һәм үз көченә таянып, Гүзәлия белән Җанбулат Мужеповлар да блоктан йорт күтәрә башлаган. Янган өйләре 8 метрга 9 метрлык булган. Инде монысын да шундый итәргә телиләр. «Бар шартлары белән саласыбыз килә. Балалар да кайтырлык булсын. Оныгыма да 4 яшь булды. Олыгаябыз», – дип сөйли Гүзәлия ханым. – Башта бернәрсә аңламадык. Китәсебез дә килде, китә идек, чөнки бу хәл бик авыр булды. Балалар да: «Калмагыз, китегез», – диделәр. Бик куркыныч иде, бөтен җирдә көл... Китәсе идек тә, тик без фатирда яшәргә теләмибез, безгә йорт кирәк. Без бит йортта яшәп өйрәнгән, бакчасы да булсын суганнар, бәрәңгеләр утыртырга. Читтә андый йортлар бик кыйммәт. Шуңа күрә калырга булдык. Эшчеләр дә бик әйбәт. Ирем вахтага китте, хәзер үзем контрольдә тотам.

Мужеповларның каршыларында гына торучы Наил абый Мәүлетов, кулына шуруповерт алып, фундаментны тирәтеп торган такталарны сүтеп ята. Наил абый турында язган идек. Бизәкләп эшләнгән капкалы матур йорт Наил абыйларныкы булган. Балта остасы булгач, барысын да үзе эшләгән Наил абый. Тик 500 меңгә генә өй салуы ай-һай авыр, дөресрәге, бөтенләй реаль түгел. Башкаларның күтәрелеп килүче өйләренә дә алар боегып карый. Наил абыйның теркәлүе шәһәрдә булган өчен, аларга миллионнар эләкмәгән. Йөрәк чирле кешегә шәһәрдә белгечләргә күренүе җайлырак булган. Тик бер рәхәтнең – мең михнәте икән шул.

«Эх, бераз яшьрәк чак булса», – ди 65 ен тутырган Наил абый. Аларга туганнары килеп булыша икән. – Йортыбыз зур иде. Хәзер үз көчебезгә салабыз, акча юк. 500 мең бирделәр, тик аңа беркем дә өй салырга теләми. Төзелеш компанияләре безнең белән килешүләр төземи. Күпме акчабыз җитәр инде. Кредит булса да алырбыз. Салырга кирәк, өй кирәк, – ди Наил абыйның хатыны Әнисә апа.

Кызу һәм бөркүлектән җирдән пар күтәрелә. Шуңа өстәп, тузаны да бөтерелеп-бөтерелеп оча монда. «Күләгәдә +40 градус. Безнең үзебездә курорт», – диешә халык. Эссе һавадан куркыта да, чөнки янгын хатирәләре әледән-әле калкып тора.

Людмила апа ихатасында тактадан салынган абзар күренә. Мулла кушкан исеме Сәхибә икән, Совет заманында Людмила дип эндәшә башлаганнар. Сәхибә апа, пенсия яшендә булуга карамастан, берүзе 13 терлек тота. Шулар өчен дип, иң башта ук бирелгән 60 меңгә абзар салдырып куйган. Маллары көндез көтүдә йөри икән. «Малларымны капларга кирәк бит. Яңгырлар булды, өши бит алар. Араларында кечтеки бозаулар да бар. 13 терлекне берүзем асрыйм, Саулыгым бар, тагын да асрыйм әле», – ди ул.

– Терлекләрне ничек саклап калдыгыз?

– Ут килүне күрү белән, барысын да куып чыгардым. Үзем күршеләрем белән качып киттем. Дөньяларымны саклап кала алмадым. Күршеләр, китә башлагач:

(Дәвамы 4 нче биттә).

Тынгысыз картлык

Мәгълүм геосәясәтче Генри Киссинджер узган атнада Кытайда берничә көнлек эш сәфәрендә булып, бу ил җитәкчеләре белән җитди очрашулар да үткәреп кайткан. Нәрсә мәҗбүр иткән соң быел майда үзенең инде 100 яшьлек юбилеен бәйрәм иткән ошбу геосәясәт патриархын мондый катлаулы эшкә алынырга? Әлбәттә, ул алай, ирекле көннән ясалган адым гына булмагандыр. Мәгәр аның чын максатын да тәгаен генә әйтеп булмый. Моның өчен, һичьюгы, аның бу илдә кем белән һәм нинди очрашулар үткәрүен ачыкларга кирәк. Ә сөйләшү нәтиҗәләрен, бүгенге глобаль сәясәттә урнашып килә тор-ган яңа вәзгыятькә нисбәттә гөман кылып, зур сәясәттә сакланган кайбер тотрыклы теорияләр белән дә бәйләп карау лязем. Хәлбуки, мондый адымга, бүген дөньяда киң колач җәйгән геосәяси кризис кына түгел, кешелек дөньясына адәми затның җинаятьчел ваемсызлыгы нәтиҗәсендә янаган глобаль һәлакәт тә этәрә. Ә Г.Киссинджер кебек катлаулы персонажлар тынгысыз картлыкка геосәясәттә озак еллар дәвамында билгән урыннары белән дә лаек.

Г.Киссинджерның бу сәфәре шәхси визит булып санала. Әмма сәяси экспертлар аның нәтиҗәләре хакимият һәм бизнес өчен дә файдалы булачагын әйтә. Мәгълүматларга караганда, әлеге «шәхси визит» берничә ай дәвамында әзерләнгән. Ә вакыты ягыннан ул Европа эмиссарларының быел апрельдә Кытайга ясаган һәм уңышсыз тәгалләнгән рәсми визитыннан соң, шулай ук АКШ дәүләт секретаре Э.Блинкен да июньдә Пекинда ике көн катлаулы сөйләшүләр үткәреп кайткач (гәрчә соңгысы АКШ президенты тарафыннан югары бәяләнсә дә) кылынды. Нәрсәләр тынгысызлый һәм нинди чатаклыклар борчый икән соң бүген дөнья тотучыларны? Мантыйк чылбырын очыннан башлыйк. Киссинджер Кытайга килгәч, иң элек (18 июльдә) бу илнең саклану министры Ли Шанфу белән очрашып сөйләшкән (ә ул кораллану сәясәте яклы һәм Мәскәү тарафдары да санала). Соңгысы анда, Пекинның һәрчак Вашингтон белән тотрыклы вә конструктив мөнәсәбәтләр урнаштыру яклы булуы турында әйткән һәм, АКШның кайбер рәсми затлары Кытай белән якынаюга бармый, дип тә зарланган. Ә Киссинджер аңа, безгә үзара аңлашмауны бетерергә, конфронтациядән китәргә һәм тыныч яшәргә кирәк, тарих вә тормыш АКШ белән Кытайның үзара дошманлашып яши алмавын ачык күрсәтә, бүгенге мөнәсәбәтләр траекториясе хәрби низагка гына китерергә мөмкин, дип җаваплаган. Ул шулай ук, ике як та зирәк булырга, бергә эшләргә һәм үсеш кичерергә, ике илдә дә армиялар үзара мөнәсәбәтләрне ныгытырга, бөтен дөньяда тынычлык вә тотрыклылык булдыру өчен тырышырга тиеш, дип тә өстәгән.

Ике көннән соң Г.Киссинджерны КХР рәисе Си Цзиньпин дә кабул иткән. Ул аны «иске дустыбыз» дип атаган һәм аның Кытай-АКШ мөнәсәбәтләренә керткән тарихи өлешен онытмаска вәгъдә иткән. Си шулай ук төп өч принципны атаган: бер-береңне хөрмәт итү, үзара тыныч яшәү һәм ике як өчен дә отышлы хезмәттәшлекне җәелдерү. Шулардан чыгып, ул Кытайның, АКШ белән генә түгел, дөнья өчен дә алгарышка илтә торган дөрес юлны сайларга әзер булуы турында әйткән. Киссинджер исә ул әйткәннәрне, Вашингтон-Пекин мөнәсәбәтләре ике илнең генә түгел, бөтен дөньяның да үсеше өчен хәлиткеч әһәмияткә ия, дип хуплаган. Ә алдагы көндә АКШ эмиссары Кытайның тышкы сәясәт буенча кураторы Ван И белән дә очрашкан. Соңгысы аңа, әлеге очрашуга нәтиҗә ясап, АКШның бүгенге җитәкчелегенә Киссинджер өслүбендәге зирәклек һәм Никсонга хас сәяси кыюлык җитми, дип белдергән. Шуны да искәртеп үтик, Киссинджер Кытайга тәүге сәфәрен 1971 елда ясый (шуннан соң ул анда инде 100дән артык тапкыр булган) һәм аның роле ике арада дипломатик мөнәсәбәтләр урнаштыруда да гаять зур (АКШ КХРны, «бербөтен легитим Кытай» буларак, 1979 елда гына, 1972 елда Шанхайда имзаланган коммюнике нигезендә таный).

Киссинджерның Кытайга кылган әлеге сәфәр нәтиҗәләрен бүгенге геосәясәт кризисы белән дә бәйләп карарга кирәктер. Чөнки, чыннан да, Кытай-Көнбатыш каршылыгын (ә бүген инде ул «Глобаль Көньяк-Көнбатыш» рәвешен дә ала) геосәяси ысуллар белән генә җайга салып булмый. Ә алга таба инде ул хәтта кайнар фазага күчәргә һәм кешелек цивилизациясенә нокта куя торган глобаль бәрелешкә дә китерергә мөмкин. Икенче яктан, яңа дөньяви тәртип урнаштыруда кулланылган Украина низагы да аның авторлары ниятләгәнчә генә бармый. Игътибарны шул ук Киссинджерның Украинаны Кырымнан баш тартуы хисабына НАТОга алу тәкъдиме дә җәлеп итә. Бәгъзеләр аны хәтта тарихка «Соломон планы» булып кереп калган һәм 3000 елга исәп тотып төзелгән геосәяси проектның бүгенге чагылышы итеп тә карый («Күкләр Иерусалимы» хакында Иске Гаһедтә дә әйтелгән). Кыскасы, мондый ук «тынгысыз картлык»лар юктан гына килмидер.

Фоат УРАЗАЙ.

Дөнья халыклары дөреслек эзли

БМО Генераль Ассамблеясе (ГА) 18 июль көнне бу оешманың Нью-Йоркта урнашкан штаб-фатирында, «Украинаның басып алынган территорияләрендәге вәзгыять» дигән темага багышлап, үзенең пленар утырышын үткәргән. ГА рәисе Чаба Кереши утырышны ачканда РФ вәкилләренә турыдан-туры мөрәҗәгать итеп: «Мин һәм күпләр сезнең милләткә вә мәдәниятегезгә хөрмәт белән карыйбыз. Бу сугышны сез башладыгыз. Аны туктату да сезнең көчегездән килә», – дип тә белдергән. БМО каршында эшли торган РФ даими вәкиленең беренче урынбасары Д.Полянский исә моңа каршы: «Мы всегда были готовы к выполнению целей нашей СВО и мирными, дипломатическими средствами, но это не вписывалось в интересы Вашингтона, Лондона и Брюсселя, не давших Украине заключить парафированный в марте 2022 года договор...» – дип җаваплаган. Аныңча, Украинага шул рәвешле, имеш, Россияне ул Көнбатыш коралы ярдәмендә җиңә ала, чөнки ул демократик кыйммәтләр вә ирек өчен сугыша, дигән фикерне сеңдергәннәр. Шул ук вакытта, дипломат Полянский Россия таләпләренең, халыкара хокук нормаларына гына түгел, ә суверен дәүләт буларак халыкара дәрәҗәдә танылган Украина Төп Законына да каршы килүен (ягъни, БМОның төп принциплары тупас бозылуын) әйтергә оныткан. Украина тышкы эшләр министры Д.Кулеба исә БМО әгъзаларын 12 июльдә Вильнюста үткән НАТО саммитында Украинаның иминлек гарантиясе буенча G7 илләре кабул иткән декларациягә кушылырга чакырган.

Игътибарны Украина оборонасы буенча контакт төркеменең 18 июльдә «Рамштайн» форматында һәм онлайн-режимда үткән очрашуы да җәлеп итә. Анда 50 дән артык дәүләт катнашкан. Алар Украинаны контрһөҗүм өчен кирәкле сугыш кораллары белән тәэмин итә торган карар кабул иткән. Сүз иң элек ПВО системалары, сугышчан авиация һәм артиллерия снарядлары турында бара. АКШ Украинага 1,3 миллиард долларлык хәрби ярдәмен инде җибәргән һәм атна ахырына әле 400 миллион долларлык өстәмә ярдәм дә күрсәтергә җыена. Хәрби ярдәмне башка илләр дә күрсәтә. ЕС исә, Киевнең хәрби запасларын 4 ел дәвамында тулыландырып тору өчен, аерым фонд та булдырырга җыена.

1 нче биттә – Эчкен авылы балалары Бөтендөнья татар конгрессы бүләкләре белән. Фото «Татмедиа» фотоархивыннан алынды.

«Апуш» – җиңүче

«Апуш» татар балалар театр студиясенең «Кечтүк» спектакле «Киләчәк буын» балалар театр коллективларының II Бөтенроссия фестивалендә 1 нче дәрәҗә лауреат исеменә лаек булды. Әлеге фестиваль «Казан дәүләт яшь тамашачы театры» тарафыннан Россия Мәдәният министрлыгы, Татарстанның һәм Россиянең театр эшлеклеләре берлеге ярдәмендә Татарстан Мәдәният министрлыгы белән берлектә уздырыла.

Конкурста илнең 29 төбәгеннән 100 дән артык балалар театр коллективлары, шул исәптән Мәскәү һәм Санкт-Петербургның театр студияләре дә катнашты.

Драматург Илгиз Зәйниев әсәре буенча куелган «Кечтүк» спектакле – «Апуш» студиясенең Ленин исемендәге мәдәният йортында иҗат итүче төркеменең тәүге иҗат эше. Ул фестивальнең өч номинациясендә иң яхшысы дип танылды:

– катнаш яшь төркемендә «Иң яхшы спектакль» номинациясендә 1 урын;

– «Иң яхшы сценография» номинациясендә 1 нче урын – рәссам, Татарстанның Рәссамнар берлеге әгъзасы Анастасия Бузунеева;

– «Иң яхшы хатын-кыз роле» номинациясендә I урын – студия шәкерте Ләйлә Таишева.

«Кечтүк» спектаклен чыгаруда «Апуш»ның тәҗрибәле остазлары, спектакльнең режиссерлары, актерлык осталыгы һәм сәхнә теле педагоглары – Татарстанның халык артисты, К.Тинчурин театрыннан Зөлфия Вәлиева һәм Татарстанның атказанган артисты, Г.Камал театрыннан Миләүшә Шәйхетдинова күп көч куйды. Спектакльгә көйләрне композитор Радик Сәлимов һәм Зөлфия Вәлиева иҗат итте, музыка бизәлеше һәм аранжировка Нияз Вәлиевнеке, шигырьләр авторы – Резеда Гобәева. Хореография остазы – Татарстанның атказанган артисты, «Казан» бию ансамбле солисты Ренат Мифтахов, вокал остазы – эстрада-джаз вокалының югары категорияле укытучысы Ландыш Фәттахова.

Фестивальнең бүләкләү тантанасы 19-22 сентябрьдә Казанда узачак. Биредә эксперт советы сайлап алган 5 спектакль-җиңүче катнашачак. Мәскәү, Санкт-Петербург һ.б. шәһәр-төбәкләрдән килгән балалар да булыр дип көтелә. Фестивальдә катнашучылар өчен «Кечтүк» спектакле 21 сентябрьдә Ленин исемендәге мәдәният йортында күрсәтеләчәк.

Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк, «Сәйдәш» мәдәни үзәгендә эшләп килүче «Апуш» студиясе моңа кадәр «Театраль Идел буе» балалар һәм яшьләр театр коллективлары фестивалендә 3 номинациядә – «Иң яхшы балалар спектакле», «Иң яхшы ир-ат роле» һәм «Иң яхшы музыкаль бизәлеш» номинацияләрендә җиңү яулаган иде һәм Пермь шәһәрендә узган фестивальнең бүләкләү тантанасында республика данын яклады.

ЭЧКЕНГӘ ТОРМЫШ КАЙТА

(Дәвамы. Башы 2 нче биттә).

Дөньяларымны саклап кала алмадым. Күршеләр, китә башлагач: «Әйдә, утыр, харап буласың», – диделәр. Озак та үтмәде, бөтен авылыбыз янып бетте. Йөрәкләрем чәнчә башлады. Стресс булды, тынычлана төшкәч, сәламәтлек какшады.

– Йорт салуда ярдәм итәләрме?

– Миңа 500 мең генә эләкте. Бер компания белән сөйләштем, Татарстан булышса, хәзер үк салып бирәбез, диделәр. Шул 500 гә бераз өстәсәләр иде. Инде үзем дә өстәр идем. Минем малларым бар, Аллага шөкер. Танамны, берәр сыерымны сатып җибәрер идем. Иң мөһиме, өем генә булсын иде. Озын гомер дә бирсен иде, – ди Сәхибә апа.

Ул үз куллары белән бәдрәф төзеп куйган. Мал абзарына идәнгә дип, такталар алган. Үзе хакимият биргән вагонда яши. «Беренче көн үзем генә кунарга шундый курыктым. Шулай да үз-үземне җиңеп, кундым. Бер көн кунгач, аннары ияләшәсең», – ди ул.

Авылда балалары мәктәптә укучыларга суыткычлар да тапшырганнар, тик Сәхибә апага эләкмәгән. «Сиңа тиеш түгел, сиңа болай да Татарстан булыша», – диделәр. Ә мин көн дә сыер савам. Сөт җыю машинасы килеп җиткәнче, ул әчи. Маллы кешеләргә дә бирергә иде ул суыткычларны», – ди ул.

Гомумән, «кайгы берләштерә» дисәләр дә, кайбер вакытта ул аера да икән. Кеше гаделлек эзли. Кемгәдер йорт салып бирәләр, кемгәдер – юк, кемгәдер акча бирәләр, кемгәдер – юк. Халык белән очрашуларда да, утырышларда да әйбернең бөтен кешегә дә житмәвен, закон буенча тиеш булмавын, бер-берсенә карата ихтирамлырак булуларын сорыйлар да бит. Сәхибә апа да авыл халкының аерыла баруын әйтте: «Хәзер «дружно» түгел булып киттек инде. Элек тә бик «дружно» түгел идек. Бүлгәләнде халык, сүз дә юк. «Менә койма да корып куйган», – диләр. Мин ул акчаны эчмәдем. Миңа ул 60 меңне бирделәр».

Аерылганны аю ашар, бүленгәнне бүре ашар, дияргә яратабыз. Авыл халкы үзара бүленсә дә, Эчкендәге янгын бөтен татар дөньясын берләштерде, дияргә була. Күпме гуманитар, материаль ярдәм җыелды, төбәкләрдәге татар эшмәкәрләре бушка йортлар салып бирүне үз өсләренә алды, Эчкен халкы турында бөтен Россия, ә бәлки, дөнья белде.

Янгын булу белән өлкә дәрәҗәсендә авылда фельдшер-акушерлык пункты ачу турында карар кабул ителгән. Курган өлкәсе губернаторы Вадим Шумков инициативасы белән төзелгән пунктны авыл халкы көтеп алды. Ачылу тантанасы алдыннан ук авыл халкы, апалар, әбиләр җыелып басты. Тантанада Курган өлкәсе губернаторының урынбасарлары Наталья Кириллова һәм Константин Ермаков катнашты. «Чын мәгънәсендә сәламәтлек йорты булсын», – дип теләде В.Шәйхразыев. Пунктны ачканда, кызыл тасманы кисү хокукын алар авыл халкына тапшырды. Авыл мәктәбендә 47 ел рус теле һәм әдәбияты укытучы булып эшләүче Анфиса Әминова белән мәктәп директоры урынбасары Гөлсимә Байтирәкова фельдшер-акушерлык пунктының ишекләрен ачты. Бина җиһазландырылган берничә бүлмәдән тора. Апалар, әбиләр шунда ук фельдшер янына чиратка тезелде. 84 нче яше белән баручы Хәдия апа Әбдрәшитова да кан басымын үлчәтте. Янгында аның да йорт-җире янып беткән.

Авылның мәктәбе янгыннан соң халык өчен штаб булды. Барырга урыны булмаган кешеләр шунда яшәде, гуманитар ярдәмне дә шунда сакладылар, халыкның җыелып, аралашу урыны да мәктәп булды. Бу юлы мәктәпкә матур вакыйга өчен бардык – Бөтендөнья татар конгрессы Эчкен авылы балаларына велосипедлар бүләк итте.

– Без балаларны читтә калдыра алмадык. Мәгариф министрлыгы аша балаларны лагерьга чакырдык. Алар берничә ай дәвамында Актаныш районында ял итте. Аннары Чаллы шәһәренә бардылар, «КамАЗ» командасы белән таныштылар, дельфинарийда булдылар. Шунда балаларга мәктәп формасы тегү турында карар кабул ителде, чөнки бар киемнәр дә янып бетте, ә Чаллыда бик яхшы комбинат бар, – дип сөйләде В.Шәйхразыев.

Балаларга велосипедлар эләксә, Эчкен фермерларына Татарстан тракторлар алып килде. Өр-яңа булмаса да, хуҗалыкка яраклы техникага сөенде фермерлар.

– Бодаем янып бетте. Бодайны сатып, трактор алырмын, дигән идем. Минем хыялым чынга ашты – Татарстан миңа трактор алып килде. Өем дә зур иде. Хатыным белән гел: «Безгә кечерәк өй кирәк», – дип әйтә торган идек. Аллаһ Тәгалә ишеткән, күрәсең. Менә Татарстан безгә кечкенәрәк кенә өй салып бирәчәк. Ул хыялым да чынга ашты, – ди Кәлимулла Миңнегәрәев. Аңа МТЗ-82 тракторы бүләк иттеләр.

Ринат Сәфәровның янгында тракторы да янып бетә. Ул гаиләсе белән 2000 елдан бирле фермерлык белән шөгыльләнә. «Нигездә бодай утыртабыз. Элек борчак, арпа да чәчә торган идек. 1-2 ел элек майлы культура белән шөгыльләнә башладык. Быел бик начар бездә, яңгырлар булган юк. Аллаһ бирса, бераз уңыш алсак, бәлки, ныгып китәрбез. Иң мөһиме хәзер – өй инде. Татарстанга зур рәхмәт. Трактор бик кирәк иде», – диде ул.

Ринат абый йортны, үз көче белән, әтисенең нигезенә сала. Чөнки үзенең йорты урынында документлар буенча төзелеш булырга тиеш түгел, чөнки ул җирләр су басу куркынычы булган зонада урнашкан икән. Бу хакта да алар документлар артыннан йөри башлагач кына белгән. «Өем 10 метрга 12 метрлы иде, җылытылган подвалы да, ихатада бөтен хуҗалык бар иде. Беренче көнне бик көчле стресс булды. Нәрсә уйларга да белмәдек. 2 айдан соң күпмедер тынычландык инде. Хәзер фундаментны салып куйдык».

– Авылдан китү теләге булмадымы?

– Юк. Минем белән зур җегетем дә (улы) йөри. Ул да: «Китмим, авылда калам», – диде. 3 балам бар минем. Шуңа хуҗалыкны торгызырга кирәк. Йә олысына, йә кечесенә калдырырмын. Авыл калсын өчен инде, – ди Ринат абый.

Эчкен авылы шулайрак яшәп ята. Авырлыгын да, шатлыгын да кеше барыбер күтәрә инде. Һәрберсенең үз язмышы, үз юлы. Барысын да уртак кайгы берләштергән халыкның һәрберсен бер теләк – өйле булу теләге берләштерә.

«Безнең бурыч – салкыннарга кадәр кешеләрне түбә астына кертү. Әлеге янгын авылны берләштерүгә көч булырга тиеш», – диде Васил Шәйхразыев Милли шура утырышында. Ул көз көне Милли шура вәкилләре кабат Эчкенгә килеп, скверда агачлар утыртачагын да әйтте.

Көз айларында Эчкендә өй туйлары гөрләр. Һәрберсенә дә андый бәхет тәтесен иде.

Энже ГАБДУЛЛИНА.

intertat.tatar.

Журналистларның аяныч язмышы

Июль аеның бер иртәсендә Чечняда адвокат Александр Немов һәм «Новая газета» журналисты Елена Милашинага һөҗүм иткәннәр. Зыян күрүчеләр хәбәр итүенчә, аэропорттан шәһәргә таба барганда, аларның машиналарын үткәрмәгәннәр. Милашина һәм Немовны хәрби киемнәр киенгән кешеләр бик каты кыйнаган, техник җиһазларын ватып бетергәннәр.

«Журналист Елена Милашина һәм адвокат Александр Немов белән булган хәлләргә комментарий бирүе дә авыр. Бу – коточкыч. Кыйнаганнар, пычак белән кискәннәр, бармакларын сындырганнар, мәсхәрәләгәннәр – зеленка койганнар, башларын пеләшкә кырганнар. Ир-атлар болай эшләми. Кешеләр болай итми», – дип яза «Телеграм» каналлар.

Адвокат Немов һәм журналист Милашина Грозный шәһәренә Зарема Мусаевага хөкем карарын чыгару уңаеннан килгән булган. Мусаеваның тарихы түбәндәгечә бәян ителә: 2021 елның гыйнварында Чечня хокук саклау хезмәте вәкилләре республиканың элеккеге судьясы Сайди Янгулбаев фатирына бәреп кергән. Сорау алу сылтавы белән хатыны Зарема Мусаеваны Чечняга алып китәләр. Чечня Башлыгы Рамзан Кадыйров хәбәр иткәнчә, әлеге хатын-кыз полиция хезмәткәренең битен тырнап бетергән һәм чак кына аны күзсез калдырмаган.

Бүген Зарема Мусаеваны колониягә озату турында хөкем карары чыкты, ул гомеренең 5,5 елын шунда үткәрәчәк. Грозныйның Ахматов районы суды Чечня оппозиционерлары Янгулбаевларның энисе Зарема Мусаевны алдауда һәм полиция хезмәткәренә карата көч куллануда гаепле дип тапты.

Интертат.Telegram.

● Таиланд башкаласы Бангкок иң озын исемле шәһәр буларак Гиннесснын рекордлар китабына кертелгән, ул без телне сындырмасын өчен генә кыскартып әйтелә, тулысынча исә болай яңгырый: Крунгтеп Маха Накорн Амон Раттанакосин Маханиндра Аюттая Махадилок Поп Нопрарат Ратчатани Буриром Удомратнивет Махасатан Амонпиман Аватансатип Сапкакатия Висанукампасит.

● Испан рәссамы Пабло Пикассоның тулы исеме менә мондый: Пабло Диего Хозе Франциско де Паула Хуан Непомукено Криспин Криспиано де ла Сантисима Тринидад Руиз Пикассо – барлыгы 93 хәрефле.

● Дөньяда иң популяр хатын-кыз исеме – Анна (100 миллион), ирләр исемнәре арасында беренче урында Мөхәммәд тора.

Башкортстанның халык артисты, авылдашым Марс Сафиуллинның сәхнәләргә күбәләктәй очып чыкканын, бәлки, күргәнегез дә булгандыр. Ул биегәндә читек табаннарыннан очкын сибелгәндәй була, йөрәкләр җилкенә, күңелләр талпына. Юк, һич арттыру түгел, чынында шулай.

Сәхнәләрдә күбәләктәй очты

Дөнья күләмендә танылган Фәйзи Гаскәров исемендәге Башкорт дәүләт халык биюләре ансамбле солисты Марс Сафиуллин, дип тыйнак кына әйтү дә күп нәрсәләр турында сөйли. Егерме елдан артык республика сәнгатенә хезмәт итү чорында шушы коллектив Халыкара, Бөтенроссия конкурслары лауреаты исеменәренә лаек булды. Алай гына да түгел, ансамбльгә шулай ук С.Юлаев һәм Г.Сәләм премияләре дә бирелде. Бу зур казанышларда Марс Галим улының да хезмәте бәяләп бетергесез. Чыгышлар ясаганда аның иҗади осталыгын, өзеп-өздереп басуларын карап, мөкиббән бирелеп, берчә соклазур осталык белән башкара һәм җиңүгә ирешә. Жюри әгъзасы, ул чакта Башкорт дәүләт халык биюләре ансамбленең сәнгать җитәкчесе, күренекле балетмейстер, заманында бөек Рудольф Нуриев белән Ленинградта бергә эшләгән Хашим Мостаев икенче көнне Марсны филармониягә чакырып ала һәм монда эшкә килергә тәкъдим итә. Бу аның өчен көтелмәгән хәл була. Туган ягына канатланып эшкә кайткан егет бер айдан республикабызның зур сәхнәсенә аяк баса. Профессиональ артист өчен мөһим булган бию композицияләрен үзләштерүдә аңа остазы, БАССРның атказаннып утырган чаклар шактый булды заманында. Хәтта горурланып та куя идем. Ул бит әле минем авылдашым (Бишбүләк районының Кыңгыр-Мәнәвез авылында туган), бер чорда бер мәктәптә белем алдык, җәмәгать эшләрендә катнаштык. Әле булса хәтеремдә: 7 «Б» сыйныф укучылары Ильяс Габдрәхимов һәм Марс Сафиуллин башкарган «Матрос биюе» КВНда югары бәя алган иде. Алар җырлаган шаян «Балыкчы» җыры бүген дә балачакның кайтавазы булып яңгырый сыман.

Сәнгатькә гашыйк егетне хыялы Стәрлетамак мәдәни-мәгърифәт училищесына алып килә. Анда ул төрле милли биюләрнең нечкәлекләрен өйрәнә. Махсус уку йортын уңышлы тәмамлагач, Марс Совет Армиясенә алына. Яраткан шөгылен биредә дә ташламый, сәнгать дөньясы белән кызыксынучы солдат-сержантларга төрле биюләр өйрәтә. Хәрбиләр алдында уңышлы чыгыш ясаганы өчен ул берничә тапкыр часть командованиесенең рәхмәтенә лаек була.

Туган якларын сагынып кайткан яшь солдат, озын-озак ял итмичә, Бишбүләк районы Мәдәният сараенда сәнгать җитәкчесе вазыйфасында эшли башлый. Төрле түгәрәкләр оештырып җибәрә. Училищеда алган белемнәрен авыл яшьләренә өләшә, алар белән бергә үзе дә өйрәнә.

1972 елның ноябрендә Уфада үзешчәннәрнең республика смотры була. Анда Марс Сафиуллин да катнаша, мари, грузин халыкларының биюләрен ган артисты Марсель Мәҗитов, бию сәнгатенә өйрәткән беренче укытучысы Зәйтүнә Заманова олы ярдәм күрсәтә. Бию осталыгының серләренә төшенүдә яшь артистка БАССРның халык артистлары Хисбулла Зөбәйдуллин, Рим Әбделманов, Җәүдәт Бикбирдин, Әнвәр Фәхретдинов дөрес юнәлеш бирә.

Марсның беренче гастрольләре Украина, Литва, Латвия якларына була. Өч айдан артыкка сузылган гастрольләр аның күңелендә бию сәнгатенә булган мәхәббәтне арттыра. Шул ук елда ул гомерендә беренче тапкыр чит илдә – Франциядә була. Бетмәс-төкәнмәс тәэссоратларга баеп, туган ягына сагынып, ашкынып кайта ул.

Җаен туры китереп, җәй айларында Кыңгыр-Мәнәвезгә дә кайтып килә. Ни дисәң дә, үсмер чакларда күңелләрдә онытылмаслык хатирә булып калган шаулы Сабантуйлар, болыннарда чыңлаган чалгы тавышлары, кичләрен авыл өстенә таралган сихри гармун моңнары һәрвакыт үзенә дәшеп тора...

«Бөтен нәрсә шул газиз туган җирдән башланадыр, мөгаен, – дип еш кына әйтә торган иде Марс Галим улы. – Миңа калса, туган як бизәкләре, аның кабатланмас моңнары бию сәнгате белән бергә үрелеп баргандыр да. Алар иҗади хезмәтемә илаһи көч, дәрт өстәде. Шунсыз мөмкин дә түгел. Һәр башкарган биюем тамашачы күңеленә онытылмаслык бер моң булып барып җитсә, чиксез шатланыр идем».

Марс бигрәк тә үзе куйган «Тиле яшьлек», районндашы Минзыя Насыйбуллина-Ханнанова белән берлектә иҗат иткән «Шаян кызлар» биюләрендә табигыйлекне, тормышчанлыкны чагылдырырга тырышты. Бу биюләрне төрле илләр сәхнәсенә куеп, сәнгать сөючеләрне күп тапкырлар сокландырдылар.

Ансамбльдә озак еллар эшләү дәверендә Марс егермеләп илдә башкорт, татар, урыс һәм башка халыкларның сәнгатен уңышлы пропагандалый. Испаниядә, Финляндиядә, Шри-Ланкада, Италиядә һ.б. илләрдә булырга туры килә. Биюче чит илләрдә гастрольләрдә йөргәндә аларның мәдәниятенә, бигрәк тә бию сәнгатенә игътибар итә. Испан, грек, Африка, һинд, болгар, монгол биюләрен отып кайту, республикабыз тамашачыларының күңеленә дәрт-дәрман өстәү – тынгысыз эзләнүләр нәтиҗәсе. Димәк, халык иҗаты, аның энҗеләре, еракларда якынга, күңелдән-күңелгә күчә. Шуңа да Марс Сафиуллин бию аша кешеләр күңеленә канат куюны, халык сәнгатен халыкка җиткерүне үз максаты итеп санады. Бию күңелне яшәртә, бию аша дуслар табыла. Аңа заманында Һиндстаннан, Италиядән килеп торган хатлар шулар турында сөйли.

Биюче легендар ансамбль белән илебезнең төрле төбәкләрендә чыгыш ясады. Кайда гына булмасын, башкалабызның, шулай ук башка шәһәрләрнең мәрмәр сарайларындамы, авылның кечкенә клубларындамы, Марс һәр биюне бөтен булмышын, күңелен салып башкарды. Чөнки бүгенге таләпчән тамашачы профессионаллардан күпне өмет итә. Марс шуңа да һәр такт-элементка, һәр хәрәкәткә сак карады, теге яки бу халыкның биюен бербөтен, аны нәкъ балетмейстер куйганча, төгәл итеп җиткерергә тырышты.

Заманында Рәшидә Туйсина белән «Зарифа», «Гөлнәзирә», шулай ук «Тау марилары», «Төньяк амурлары», «Гопак» һәм башка биюләрне башкарганда да бу моментларны күз уңында тотты, үзенә һәрчак таләпчән булды. Тормыш юлында нинди генә киртәләр очраса да, Марс һөнәренә хыянәт итмәде.

Шулай, 1988 елның декабрендә филармониядә дәртле грузин биюен биегәндә Марсның тез капкачы ярыла, әмма йөрәге ярсып, дәрте ташып торган егет каушап калмый, идәннәрне дер селкетеп биюен дәвам итә. Шулай да яра үзенекен итә. Бу вакытта аңа дуслары ярдәм кулы суза, бу күңел канатын һыгытып җибәрә. Ул үзе белән бергә эшләгән танылган биюче һәм курайчы Риф Габитовны, БАССРның халык артистлары Гүзәл Габсаттарованы, Рим Гәбделмановны һәрвакыт ихтирам белән искә ала иде.

М.Сафиуллин төшенкелеккә бирелмәде, янә сәхнәдә утлар уйнатты. Шат йөзле, ихлас тамашачылар яраткан артистның бию ритмына кушылып, дәррәү кул чапты.

1988 елда М.Сафиуллин туган авылыбызга Башкорт дәүләт халык биюләре ансамбленең зур составын автобуслар белән алып кайта. Алар арасында минем белән кайчандыр университетта бергә укыган, бер бүлмәдә яшәгән, Башкортстанның халык артисты, С.Юлаев исемендәге премия лауреаты, танылган биюче Риф Габитов та була. Марс шушы кайтуында безнең йортыбызны эзләп табып, инәкәй янына килеп, концертка чакыру билеты китереп биргән. Инәкәй исә, үз чиратында, ачлы-туклы йөргән артистларга күпереп пешкән икмәген, сөтен, катыгын, каймагын биреп җибәргән.

...Марс замандашым биюче генә түгел иде. Ул Уфа «Нур» татар дәүләт театрында репетитор, шулай ук Уфа дәүләт сәнгать институтында мөгаллим вазыйфаларын да башкарды. Аның сыздырып баянда, моңлы итеп курайда, фортепьянода, шулай ук кубызда уйнаганын да хәтерлим. Бу һөнәрләрен ул үз вакытында авылдашларга да күрсәтеп калды. Шулай, үз башлангычым белән 1996 елның 4 мартында танылган шагыйрь, җырлар авторы Рамил Чурагуловны, Башкортстанның атказанган артистлары Фәридә һәм Роберт Тимербаевларны, әлбәттә, Башкортстанның халык артисты Марс Сафиуллинны туган авылым Кыңгыр-Мәнәвезгә алып кайткан идем. Ул чакта инәкәй дә исән-сау иде әле. Ул дусларымны ихлас каршы алды, мул ризыклары белән сыйлады. Тансык концерт исә авылдашларым өчен күркәм, бер матур бәйрәм булып истә калды.

Шул ук вакытта Усак-Кичү, күрше Мәнәвезтамак авылларында да чыгыш ясарга туры килде. Һәр җирдә безне ихлас каршы алдылар. Хәзер инде боларны сагынып сөйләргә генә калды. Бу исә, күрәсең, танылган артистның, авылдашыбыз Марс Сафиуллинның туган яктагы соңгы талпынышы, соңгы балкышы булгандыр...

Гадәттә, кешенең күркәм сыйфатлары, нинди дер сәләт гаиләгә дә йогынтысыз калмый. Кече уллары Илнур Уфа дәүләт сәнгать институты каршында махсус балалар музыка мәктәбендә, соңрак Мәскәүдә белем алды. Ул да фортепьянода, баянда уйный. Өлкән уллары заманында спорт белән мавыкты. Ә инде тормыш юлдашы Суфия Корбангалиева-Сафиуллина белән таныштырып торасы да юктыр. Ул – Мәҗит Гафури исемендәге Башкорт дәүләт академия драма театрында танылган актрисаларның берсе, шулай ук җырчы да, Башкортстанның халык, РСФСРның атказанган артисты. Бер үк вакытта инде күп еллар Уфа дәүләт сәнгать институтында укытучылык эшен дә уңышлы алып бара.

Бу дөньяда эшләп туеп та булмый кебек. Ә гомер коясы исә акрынлап баюга таба якынлаша. Иң мөһиме – ул заяга үтмәгән, җирдә үзеңнән соң ниндидер якты эз калган. Дөнья матур ул, ямьле ул, максат куеп, аның кадерен белеп, яшисең килеп яшәгәннәргә...

Әнвәр СӨЛӘЙМАНОВ,
журналистика ветераны.
«Кызыл таң» газетасыннан.

Олпат әдипнең яңа романы

1933 елның 22 апрелендә дөньяга аваз салган Марат Әмирханов – һәм яше, тормыш тәҗрибәсе, һәм иҗаты белән соңгы дәвер татар әдәбиятының иң күренекле вәкилләреннән берсе. Мәшһүр Актаныш якларында туып, шунда һәм Казан педагогика институтында урта һәм югары белем алган, армия сафларында хезмәт иткән, Карабаш эшчеләр бистәсендә дистә елдан артык укытучы, мәктәп директоры урынбасары, «Социалистик Татарстан» газетасында 17 ел, «Азат хатын» («Сөембикә») журналында чирек гасырга якын әйдәп баручы журналист булып эшләгән бу мөхтәрәм затка күптән түгел 90 яшь тулды.

Узган йөзнең 70-80 нче еллар аралыгында әдәбиятка килеп кергән М. Әмирханов – күпләгән очерк-хикәяләр, роман-повестьлар авторы. Болар арасында «Гөлнәзирә» (1998), «Тояк эзе» (2003), «Тәкъдир» (1999), «Әлвидаг» (2011), «Бибимәмдүдә» (2016) һәм бераздан телгә алыначак кайбер башка әсәрләре аеруча мәгълүм. Аның иҗаты хезмәттәшләренең, әдип-тәнкыйтьчеләрнең дә игътибар үзәгендә. Мәсәлән, Аяз Гыйләҗев «Бәрәкалла, Әмирхан!» исемле мәкаләсендә («Мәдәни җомга». – 4. 04. 1997) авторның «Дөя муены» повестен бик тә югары бәяли. «Аның күзе – прожектор, без күрмәгәннәрне күрә. Фикере – ачык, максаты бер: ул халкыбызны, һәр җан иясен коллыктан коткарырга омтыла». Без фәкыйрегезнең дә М.Әмирханов хакында язмалары бар. Мәсәлән, әдипнең тууына 85 яшь тулу уңае белән басылган «Әдәбиятыбызның әмир-ханнарыннан берсе» исемле мәкаләдә («Казан утлары». – 2018. – 4 нче сан. – 158-163 б.) язучының тормышы, иҗади эшчәнлеге турында шактый гына фикер-күзәтүләр бәян ителә. Ул язма мондый юллар белән төгәлләнә: «Марат ага Әмирханов үзенең яше (85 е), фамилия-атамасы белән генә түгел, ә кабатланмас бай иҗаты белән дә әдәбиятыбызда ханлык, әмирлек дәрәҗәсенә ирешкән олпат зат. Ул сүз сәнгатендә тирән эз калдырган адашлары Фатыйх Әмирхан, Әмирхан Еники традицияләрен уңышлы дәвам иттерә. Кылган игелекле гамәлләре өчен аңа ихласи зур рәхмәтләр юллыйбыз, исәнлек, иҗади уңышлар телибез, 90 яшенә җиткәндә дә халкыбызны куандырырлык әсәрләр тудырсын». Шөкер Ходайга: ул безнең үтенеч-теләкләрне кабул иткән. Хөрмәтле затыбыз, гәрчә аерым кайгы-мәшәкатьләргә дучар булса да (иң авыры, мөгаен, шактый еллар бергә гомер кичергән хатыны – Ләлә ханымны җирләү булгандыр, 2022 ел), исән-сау килеш унынчы дистәсенә дә аяк басты, яңадан-яңа иҗат җимешләрен укучыларга җиткереп торды. Шундыйларның берсе – һәм иң күренеклесе – «Казан утлары» журналының 2023 елгы 4-5 нче саннарында басылып чыккан «Яугирә» романы. Хәзер игътибарыбызны шул әсәргә юнәлтик.

* * *

М.Әмирханов язмалары идея-тематик, жанр, стиль ягыннан төрле. Сатира-юмор да аның өчен чит түгел. Авторның әсәрләрендә төрле чор вакыйга-хәлләре, гадәти затлар һәм тарихи шәхесләр дә гәүдәләнеш таба. Әдип иҗатында, мәсәлән, Тукай тематикасына шактый урын бирелә. Шагыйрьнең әнисен үзәккә куйган «Бибимәмдүдә» бәяны киң катлам укучылар тарафыннан яратып укыла. «Мәйдан» журналының 2023 елгы июнь санында басылган «Җаекның бунтарь егете» бәяны да кызыклы гына. Анда Габдулла Кариев, Газизә (шагыйрьнең апасы) һәм кайбер башка шәхесләр белән мөнәсәбәттә Тукайның үзенчәлекле сыйфатлары, эш-гамәлләре гәүдәләндерелә. Әсәрдә Җаек тормышына кагылышлы мөһим генә факт-мәгълүматлар да бар.

М.Әмирханов иҗаты тематик һәм жанр ягыннан төрле булса да, анда халкыбызның Урта гасыр тарихын, шул чорның күренекле затларын роман жанрында яктырту өстенлек итә. Аның «Үрбәт ханәкә гыйшкы», «Гәүһәршад» (2009), «Әлвидаг» (2011) әсәрләренә (аларны трилогия дип тә атарга мөмкин) ялганып киткән «Ир-Мамай» (2013), «Тәхетсез патша» (ягъни Симеон Бикбулатович, 2017) романнары (үзенә күрә бер «хәмсә» (бишлек)) – шуның күркәм мисаллары. Аларда авторның тарихи, язма чыганаклардан, фольклордан (аеруча – дастан-бәетләрдән) хәбәрдар булуы нык сизелеп тора.

2023 елда дөнья күргән «Яугирә» романында М.Әмирхановның халкыбыз тарихын сәнгати гәүдәләндерү традициясе алга таба уңышлы гына дәвам иттерелә һәм үстерелә. Авторның, гомумән, тел-стиле бай. Бу романда ул исә тагын да байый, камилләшә төшә. Язучының канатлы сүз-гыйбарәләрне, мәкаль-әйтемнәрне, әдәби детальләрне оста һәм урынлы куллануына сокланырлык. Китапны укучы аларга үзе дә игътибар итәр. Шуңа күрә биредә мин берничә мисал китерү белән чикләнәм. «Орыш уен эш түгел, вакытында поса бел, поссаң торып баса бел, акылыңны җуйма» (№ 5. – 30 б.), «Ир-егеткә гашыйк булу өчен җидегә кадәр санау да җитә, диләр» (№5. – 52 б.), «Биле ныкның гына иле нык булыр...» (№ 5. – 57 б.), «Үз балаңның җылысыннан да җылырак, татлырак, сихәтлерәк җиңеллек юк ул дөньяда...» (№5. – 76 б.), «Дошман дустан арала...» (№ 4. – 60 б.), «Кәҗә биргән ат алыр...» (№ 4. – 61 б.) һ. б.

Гомумән, романда телебездә элек иркен кулланылган, шул чорның гореф-гадәтләрен, яшәешен чагылдырган шактый гына сүзләр, детальләр күзгә ташлана. Аларның кайберләренә аңлатмалар бирү дә соралып тора.

М.Әмирханов моңа кадәрге тарихи роман-бәяннарында, нигездә, Алтын Урда чоры һәм аннан соңгы гасырлар белән чикләнә иде. «Яугирә» әсәрендә ул халкыбыз тарихының тагын да элгәрәк дәверләренә мөрәҗәгать итә. Биредәге төп вакыйга-хәлләр IX йөзнең ахырларында – X гасырның беренче дистә елларында Урта Иделдә, төгәлрәк әйткәндә, Болгар җирләрендә бара. Багдад хәлифенең 500 кешелек делегациясе чакырылуына һәм килүенә мөнәсәбәттә бу кодрәтле мәмләкәтнең башкаласын тасвирлауга да романда билгеле бер урын бирелә. Шунысын да искә төшерик: Болгар чоры, тормышы гарәп-фарсы телле чыганакларда, аеруча Ибне Фадлан, Әл-Гарнатый һәм кайбер башка авторларның хезмәтләрендә, урыс елъязмаларында, фольклорда шактый гына гәүдәләнеш тапкан. Археологлар да бу юнәлештә нәтиҗәле генә эшлиләр. Н.Фәттахның «Итил суы ака торур» романы (1970) – Болгар дәверен сәнгати гәүдәләндерүнең матур бер үрнәге булу күпләргә мәгълүм. Бу чорның фольклорын, дастан-легендаларын махсус яктырткан фәнни хезмәтләр дә язылды, хәтта докторлык диссертациясе дә якланды (И.Закирова). Рухи мирасыбызны өйрәнүгә, халыкка җиткерүгә зур өлеш керткән Әнвәр Хәйринең туган авылы Шәрбәннең нигезләнүенә 1100 ел тулу уңае белән язылган «Шәһре Бану – Шәрбән кыйссасы» китабы да белгечләргә таныштыр дип уйлыйм. Бу төр чыганакларны, басма хезмәтләрне М. Әмирханов шактый җентекле өйрәнгән, аларны, аеруча Ибне Фадлан, Ә. Хәйри китапларын материал буларак та мул файдаланган. Әсәрдә Болгар чорына теге яки бу дәрәҗәдә нисбәтле булган факт-мәгълүматлар, авыз иҗатыннан мисаллар, язма чыганаклардан алынган өзекләр китерү романның тарихи нигезен ныгыту, ышандыру көчен арттыруга ярдәм итә.

Мәгълүм ки, IX-X гасырлар аралыгы, ягъни әсәрдә сурәтләнгән еллар – Болгарның дәүләт буларак оешып, шәкелләшеп килгән чор. Автор бу процессның катлаулы, каршылыклы булуын шактый тулы тасвирлый. Мәмләкәтнең тышкы мөнәсәбәтләре. шул исәптән күрше-күләннәр белән элемтә-багланышлары да игътибардан читтә калмый. Хезмәттәшлек, сәүдә итү белән бергә, юлбасарлык, үзара сугыш-бәрелешләр, фаҗигале хәлләр дә булып тора. Романның үзәк геройларыннан булган Дөрмән бәкнең, Ярмәк һәм Бану ханымның күршеләр – «кызылбашлар» белән бәрелештә бакыйлыкка китеп барулары да күп нәрсә хакында сөйли.

М.Әмирханов, башка тарихи әсәрләрендәге кебек, «Яугирә»дә дә халыкның, илнең гореф-гадәтләрен, йолаларын сурәтләүгә бик игътибарлы. Текстка гыйбрәтле мисаллар, мөһим детальләр дә кертеп җибәрә.

Табигать гомумән, аеруча элекке чорларда кеше тормышында гаять мөһим роль уйный. Шуңа нисбәтән автор вакыйга-хәлләрне, кеше образларын табигать күренешләре, җир, үсемлекләр, хайваннар дөньясы аккошлары, җил-яңгыр-карлары белән тыгыз мөнәсәбәттә бирә, адәм балаларының рухи халәтләрен яктыртуда алардан оста файдалана. Ат – элеккеге яшәешнең, татар тормышының бик тә мөһим компоненты. Әсәрдә дә ул нәкъ шулай бирелә.

Ислам безнең халыкка бу дин барлыкка килү дәвереннән үк керә башлый. Хәтта ул 737 елда әби-бабаларыбызның зур өлеше яшәгән Хәзәр мәмләкәтендә рәсми рәвештә дә кабул ителә. Болгар илендә дә ул әкренләп тамыр җибәрә һәм 922 елда аның рәсми дәүләт диненә әверелә. Романдагы төп вакыйга-хәлләр шуңа мөнәсәбәттә бирелә һәм үстерелә. Әйтергә кирәк, автор исламның асылын, «Коръән»нең төп кануни сыйфатларын яхшы үзләштергән, аларны белеп, урынлы куллана.

«Яугирә», – гәрчә тарихи факт-мәгълүматларга, чынбарлыкка тапкыр килешле вакыйга-хәлләргә гаять бай булса да, ул әдәби әсәр. Аның үзәгендә төрле язмышлы, төрле холыклы кешеләр, аларның эш-гамәлләре, күңел дөньялары. Болар арасында Силки, Алмуш, Багдад хәлифе кебек хөкемдарлар да, Ибне Фадлан шикелле каләм әхелләре дә бар. Үзәктә, әлбәттә, Бәхтияр бәкнең һәм Хәдичә бикәнең кызы Бану. Ул кыю, уңган, зирәк, төрле һөнәрләргә, шул исәптән сугыш гыйлемнәренә дә ия. Кальгә – калалар да төзетә. Бу зат романдагы төп вакыйгаларны ялгап, тоташтырып торучы шәхес. Юкка гына әсәрнең исеме дә аңа мөнәсәбәттә бирелмәгәндер. Болгарда хатын-кызларның җәмгыятьтә мөһим роль уйнаулары билгеле. Бану образы – моның күркәм бер мисалы. Аның Ярмәк белән көчле мәхәббәте, гаилә корулары укучыларны дулкынландыра. Бу батыр һәм куркусыз зат яу кырында һәлак була. Бу хакта Ибне Фадлан авызыннан мондый сүзләр дә әйтелә: «Болгарда хатын-кызлар, күкәй эчендәге сары кебек икән, абруйлылар» (№5 – 68 б.). Бану исемнәре җисемнәренә туры килешле Хөснеруй, Хөснеҗәмал, Хөсникамал исемле өч кызын Ярмәк рухында тәрбияләп үстерә. Кече кызы зирәк Хөсникамал гаскәр башлыгы, әти-әнисенең, нәсел-нәсәбенең лаеклы дәвамчысы буларак таныла.

* * *

Без бу язмабызда Марат ага Әмирхановның яңа әсәре хакында кайбер фикер-күзәтүләребезне бәян кылырга җөрьәт иттек. Безнең карашыбызча, бу роман автор иҗатында гына түгел, ә гомумән тарихи тематикага соңгы дәверләрдә иҗат ителгән әсәрләр арасында да мөһим урынны алырлык. Ул халкыбыз үткән юлларның борынгырак сәхифәләрен яктырта. Анда бүгенге буынга сабак, гыйбрәт алырлык яклар да күп. Роман кинофильмнар, спектакльләр өчен дә менә дигән материал, әсәр.

Хатыйп МИҢНЕГУЛОВ,
филология фәннәре докторы,
КФУ профессоры.

КОРЪӘН

Үз-үземә беркөн сорау бирдем,
Кем китергән, диеп, бу җиргә?
Җавап эзләп шушы сүзләремә,
Сорау бирим микән мин җилгә...
Сорау бирим икән мин кемгә?

Нигә тудым,
Кайдан килдем соң мин,
Җир-йортымның бармы атасы?
Җан әрнетеп торган соравыма
Килә төпле җавап аласы.

Кулларыма алдым изге китап –
Соравыма җавап эзлимен.
Күңелемә сүрәләр сеңдергән
Раббыбызга: «Ярдәм ит», – димен.

Изге китап килгән гасырлардан –
Нурлар балкый аның эчендә.
Аллаһыдан иңгән изге сүзләр
Җавап бирде миңа барсына, –
Ул мәңгегә кала көчендә.

ЗӘМ-ЗӘМ

Чыктым бүген ком чүленнән тибеп,
Яшь пәйгамбәр табан астыннан.
Җил дә исми, бары Һаҗәр ана,
Тәгам эзләп, су тамчысы күзләп,
Әрле-бирле йөгерә таңнан.

Чыктым менә, ком астыннан бәреп,
Өстәр өчен ике җанга ямь.
Ана күреп, Һаҗәр ана күреп,
Көмеш суым юкка чыкмасын дип,
Як-ягыма учлап ком өя,
Әйтә-әйтә: «Чишмә, зәм, зәм, зәм*!»

Белде дөнья, белеп барлыгымны,
Бире килә торды кәрваннар.
Тукталдылар алар рәхсәт сорап,
Тукталдылар минем янәшәмә
Адашканнар, юлда арганнар.

Күчеп килде авыр хәлле кавем,
Илаһ биргән шушы рәхәткә.
Бу – могҗиза бөек Аллаһымнан:
Һаҗәр ана җан җылысы белән,
Мөселманнар күрке, бәгъре булып,
Җир өстендә калыкты Мәккә!

*Зәм-зәм – татарча мәгънәсе: җыел-җыел.

СУКЫР ЗАМАН

Ак җаннарны безнең изә-изә,
Албастылар таптап үттеме?
Яшәү өчен типкән йөрәкләрне
Газраилләр кочып үптеме?

Сукырайды заман, күрми күзләр,
Аермыйбыз акны карадан.
Иблис үзе бәйрәм итә-итә
Йөри түгелме соң арада?

Хак икән шул изге Коръән сүзе:
Безне ташлап акыл китәчәк,
Азгын йөзләр баскач дөньябызны,
Кәгъбә ташын берәү сүтәчәк...

УРАЗА – БЕЗНЕҢ ӨМЕТ

Үткәннәргә таба җилдерәмен,
Утырып уйлар чанасына.
Ак каеннар анда бөреләнә,
Шул каенлык эчләрендә, уйнап,
Егет белән кыз чаба сыман.

Болыт ярыгыннан кояш карый,
Карлар эри, шыта яшь үлән.
Күңел сизә: тиздән җиһан буйлап
Җәеләсен чәчәкле келәм...

Алмаз Әхмәтгалиев 1981 елда Татарстанның Балтач районы Кариле авылында эшчеләр гаиләсендә туа. Норма мәктәбен тәмамлагач, 96 нчы һөнәр лицеенда белем ала. Аның шигырьләре «Идел» һәм «Мәйдан» журналларында, «Мәдәни җомга» һәм «Ватаным Татарстан» газеталарында, «Безнең гасыр авазы» китабында дөнья күрде.

Алмаз ӘХМӘТГАЛИЕВ

Менгәндә әле дә сынаулар тавына, Язмышның күзенә карыйбыз елмаеп...

Тик бүгенге көнем сискәндерә,
Язны чикли бездән таҗлы чир.
Йа Раббым, дип, намазлыкка баскан
Мәйдан тоткан гаярь, данлы ир.

Бу зәхмәткә бармы икән дәва,
Ничек итеп аннан арыныйк?
Бар дәвасы – Изге Рамазан ул,
Әйдә бергә, әйдә әле, халкым,
Таңнан алып, кояш баеганчы
Кара гөнаһларны кагыныйк.

ӘСТӘГЪФИРУЛЛАҺ

Кичер, Аллаһ, барыр юлларымда
Сылу күрдем, шайтан заты күрдем.
Акылымны күмдем буй-сынына,
Үрмәкүчтәй аңа ятьмә үрдем.

Кичер, Аллаһ, минем күзләремне, –
Төбәлгәнгә кыска җиңнәренә;
«Мәчет»емнең манарасын кистем,
Карап аның шәрә иңнәренә.

Кичер, Аллаһ, үзе тагын әйди:
«Ир солтаны, бире, бире кил!» – ди.
Егет чакта кызлар серле иде,
Хәләл сорау туа иде башта:
Туташларның чәч төсләре нинди?!

ӘЛ-ХӘКИМ

Офыкта юк болыт әсәре – көн аяз,
Зәңгәр күктә кояш көлә – күңелдә яз.
Пошкырды берзаман Әл-Хәким** атларны,
Кояшның тәрәзен ак пәрдә каплады.

Бәрхеттәй кар-келәм җәелде кырларга,
Акъегет көй уйнап тотынды җырларга;
Урманда һәр агач, һәр куак агарды,
Күз ачып йомганчы табигать яңарды!

**Әл-Хәким – Аллаһыбызның исеме.

ТУЛПАР-БУРАННАР...

Бу тулпар-бураннар нигә соң ашыга,
Агартмак буламы киң дала күкрәген?
Ярсыган сулышы җаныма кагылса,
Суыктан сискәнә лачындай йөрәгем.

Бу тулпар-бураннар нәрсәдән өркегән,
Курыкканмы әллә мин яккан учактан?
Һәр тояк астыннан ак карлар сибелә,
Үзләре сиена кап-кайнар кочакка.

Бу тулпар-бураннар кайларга ашыга,
Артыннан иярте океан җилләрен;
Талпынамы әллә аклыка урарга
Өзелеп яраткан туган як җирләрен?!

ПОЕЗДЛАР КАЯ СОҢ АШЫГА?

Мин торам вокзалым каршында,
Поездлар офыкка ашыга.
Ачыла ишекләр, ябыла –
Язын да, көзен дә, кышын да.

Кемне соң зарыгып мин көтәм,
Кем өчен җанымны мин өтәм?
Ачыла ишекләр, ябыла –
Яңадан борылып мин китәм.

Еракта ак утлар күренә,
Кулларым кочарга үрелә.
Ачыла ишекләр, ябыла –
Өметем чаткысы сүрелә...

Поездлар кая соң ашыга,
Ник исә салкын җил каршыма?
Миңа ул килде бит, дигәндә –
Ишекләр
Ачыла...
Ябыла...

ВАКЫТ СЫНЫЙ

Нигә вакыт чабышкыдай чаба? –
Көн тудымы, шундук төн җитә.
Күзләремне йомып кына куям, –
Таң җилләре биткә чиертә.

Хәтерләтеп үткән көннәремне,
Уйлар баса килеп каршыма;
Ул уйларның елгыр карашыннан,
Аң-капкамның ишекләрен ачып,
Зиһен керә минем башыма.

Үтә бары керфек каккан ара,
Бүгенге көн каршыма баса.
«Әйдә, кешем, әйдә, алга!» – диеп,
Күкрәгемә медаль элгән сыман,
Намусыма сынаулар аса.

* * *

Хәтерлисең микән: танышканда
Төннәре дә аның ак иде.
Шул аклыкта койма ярыгыннан
Сине күзләп йөргән чак иде.

Гөлбакчаңда яна иде утлар,
Адым саен серле лампалар.
Кочагыма сине алган чакта,
Куәтлерәк итеп яктырды да,
Иреннәргә ирен үрелгәндә,
Берәм-берәм сүрелде алар.

Бу тыйнаклык шушы нурлы төннең
Булды онытылмас мизгеле.
Ә син, иркәм, кайнар мәхәббәтнең –
Гөлбакчаңда үскән гүзәллекнең –
Таҗын ачкан хисле бер гөле.

БЕЗ ИКӘҮ

Бу төндә янәдән без икәү калыйк та
Сөйләшик әле бер үткәннәр турында.
Яшьлектә без дә бит куышлы уйнадык
Җәйләрнең хуш исле чәчәкле кырында.

Күзләрдә озаттык аккошлар төркемен,
Тик менә үзебез адаштык кышларда.
Туктады бураннар, килде яз җиһанга,
Йөрәкләр кавышты, сайрашып кошлардай.

Ул язның таңында кабыздык кояшны,
Сүндердек без икәү ахыргы йолдызны.
Мин тәкъдим ясадым, мәхәббәт аңлатып,
Мәңгелек яр иттем син гүзәл, шук кызны.

Кордык без икәүләп гашыйклар оясын,
Эшебез уңмаса, тормадык моңаеп.
Менгәндә әле дә сынаулар тавына,
Язмышның күзенә карыйбыз елмаеп.

КАЙЧАН ЯЗ БУЛЫР

Миндә кояш, синдә дулый буран,
Сөю бөреләрен өшетә.
Ялгызлыкта газапланган җаным
Офыклардан һаман яз көтә.
Синдә салкын, синдә дулый буран.

Үтте җәй дә, миндә алтын көзләр,
Синдә әле кайчан яз булыр?
Кайчан кайтыр сиңа сандугачлар,
Алма бакчаң моң белән тулыр?!
Үтте көз дә, миндә инде кышлар.

Миндә буран, синдә яңгыр ява,
Кайтарырга теләп язларны.
Гөрләвекләр ярсып акты инде,
Тоя алмый синең назларны.
Миндә буран, миндә карлар ява...

ТАТАР

Сембер – Ульяновск каласы җәмәгатьчелекнең аңына «бөтендөнья революциясенең юлбашчысы» Владимир Ульянов туган кала буларак кереп калган. Менә шул Ульяновны күкләргә чөю совет чоры идеологиясендә Сембер каласының элекке болгар-татар ханлыклары чорында мөһим милли үзәкләрнең берсе булып торуын да, аның татар дөньясында нинди мөһим роль уйнавын да читкә этеп куйды. Гәрчә Сембер җиренең татар милләтенә бертуган сәүдәгәр Акчуриннарны, Камал театры сәхнәсендә СССР халык артисты дәрәҗәсенә ирешкән Габдулла Шамуковны һәм тагын әллә никадәр талантлы шәхесләрне үстереп бирүе хакында без яхшы беләбез. Менә шушы тарихи эзне җуймау һәм яңарту максатыннан, бу елның җәй башында «Татмедиа» акционерлык җәмгыятенең берничә редакторы Ульян өлкәсенә сәяхәт кылды һәм Сембер губернасы чорында ук чәчәк аткан мәдәни учак традицияләрен күзаллап кайтты.

Кол Гали һәм җанисәп йомгаклары

Ульяновскидагы «Татар мәдәни үзәге» каладагы һәммә җәмәгатьчелек һәм мәдәни эшчәнлекне көязгедәге кебек чагылдырып тора. Үзе генә дә зур символ – мәдәни үзәк каршында безнең иске татар әдәби теленә нигез салучы бөек Кол Гали һәйкәле куелган. Казаннан үзеннән тыш, Россия буйлап сибелгән татар дөньясының башка бер генә төбәгендә дә бөек шагыйрьгә куелган андый һәйкәл юк. Өстәвенә, әлеге икенче ягы да бар бит: үзен «өлкән агай» дип игълан иткән урысларда да 800 ел элек үк барча кешелеккә бөек шагыйрь булып танылган Кол Гали белән янәшә куярдай сыңар борынгы талант та юк, тәүге иҗатчылары да фәкать XVII-XVIII гасыр чигендә генә пәйда була башлый. Димәк, татар милләтенең «өлкән»нәргә караганда биш гасыр элек үк формалашуын һәм дан атуын раслап тора алган олуг дәлил дә бу. Әлеге һәйкәл калкып чыгу өчен без тулысынча Ульяновск өлкәсендәге татар милли-мәдәни автономиясе рәисе Рәмис Сафин атлы милләттәшебез алдында бурычлы. Ходайга мең шөкер, ул бүген дә автономия белән уңышлы җитәкчелек итә.

Рәмис 2023 елда ил буенча үткәрелгән җанисәп нәтиҗәләре белән һич тә риза түгел.

– 2002 елда булып узган җанисәп вакытында Ульян өлкәсендәге татарлар саны 170 меңнән дә артып киткән иде, 2010 елда безнең санны 150 меңгә генә калдырдылар. Ә соңгы җанисәп барышында өлкәдәге татарлар саны 38 меңгә киметеп күрсәтелде. Бернинди дә глобаль сугыш хәрәкәте бармый, ачлык яки эпидемияләр дә күргәнебез юк. Татар халкы үзе туган нигезне ташлап чит җиргә дә китми, ә санныбызны хәрәмләшеп бары-бер киметәләр. Әле шул килеш тә өлкә халкының 15 процентын тәшкил итәбез бит. Сан ягыннан күбрәк булуыбызны да аңлыйбыз, ләкин тәзәтергә дилбегәләр безнең кулда түгел.

Татарларга борыннарын түбән төшермичә яшәргә өлкәдәге «Сембер» бизнесменнар җәмгыяте ярдәм итә. Нәкъ менә шулар тырышлыгы белән «Милли-мәдәни үзәк»кә ремонт үткәрелгән, шушы ук җәмгыять кала үзәгендә Кол Гали һәйкәлен калкыткан. Хәзер җәмгыять каршына үзәк фәрманы буенча кысылган туган телебезне һәм татар мәктәпләрен саклап калу бурычы килеп баскан.

Бар мәктәпкә сыңар укытучы

Ульян каласында 1990 елларда татар теле укытылган, милли компонентлар кулланылган урта мәктәпләр байтак булган әле. Ә хәзер «революцияләр юлбашчысы» Ленин ватанында фәкать 28 номерлы урта мәктәп кенә этномәдәни компонентлар кулланып гомерен дәвам итә. Аның директоры Әсгать Фәизов сүзләре буенча, мәктәптә бер татар гына түгел, ә өлкәдә яшәүче башка милләтләрнең дә телләре һәм тарихы өйрәнелә. Әмма татар телен киләчәктә дә укыту зур хәвеф астында, чөнки мәктәптә аны укытырлык бер генә мөгаллим торып калган. Казанда 140 ел буена эшләп килгән һәм барча Идел буе өлкәләрен татар мөгаллимнәре белән тәэмин иткән педагогия институтын 15 ел чамасы элек шатырдатып ябып куйдылар. Ә хәзер тарих, география, җәмгыять белеме фәннәрен генә түгел, хәтта татар теле һәм әдәбиятын укыта алырлык мөгаллим әзерләүче югары уку йортлары юк дәрәҗәсендә. Хөкүмәтнең менә шушы рәвешчә татар теленә төкереп каравы аркасында туган телгә хөрмәт мәктәп укучылары, хәтта ата-аналар сафында да нык какшады. Мәктәптә укучы балаларның йөздән бере генә татар телен һәм әдәбиятын яратып өйрәнә, ә калганнары техник өлкә белән математика-физика фәннәрен генә тирәнтен үзләштерергә ашкына. Үзебез утырган ботакка үзебез балта чаптык, хәер, анысының да саплары хуҗалар кулында шул...

Әлеге мәктәп диварына безнең өчен үтә аяныч булган истәлек тактасы куелган. Биредә байтак еллар буе татар телен Венера Солтангәрәй кызы Айзятова укыткан да, 1990 еллар ахырында Казан каласына күчеп киткән икән. Ул андагы 175 номерлы гимназиядә яңадан да балалар укыткан, әмма бер тилемсә кузгаткан коточкыч атыш вакытында Венера ханымның да гомере өзелгән...

● Ульяновскидагы Кол Гали һәйкәле.

Ульянда ислам үзәге

Ульян каласындагы «Биләр» мәдрәсәсе барча өлкә татарлары өчен бүген гыйлем үзәге дә булып тора инде. Өлкә мөфтие Илдар хәзрәт Сафиуллин аңлатуынча, диндарлар «Биләр» исемен дә юкка гына сайламаган. «Биләр – үз заманында зур Болгар ханлыгының мәркәзе булган кала бит. Анда шәкертләргә дарелфөнүннәрдә югары белем биргәннәр, анда бер мең ел элек үк дивар һәм идәннәре торбалардагы су буенча җылытыла торган мунчалар да булган». Бүген «Биләр» мәдрәсәсендә булачак имамнарны һәм ислам динен тирәнтен үзләштерергә омтылган шәкертләрне укыталар. Мәдрәсә якын киләчәктә хатын-кызлар бүлеге ачып җибәрүне һәм үз каршыларында мөселман балалар бакчасы ачып куярга да әзерләнә. Бакчаның бинасы әзер, бизәү эшләре генә калган.

Мәдрәсә китапханәсенә бик күп дини һәм гыйлми китаплар тупланган. Мөфти сүзләренчә, бирегә ислам дөньясының йөзләгән үзәгеннән фәнни чыга-

● Җәмигъ мәчете.

СЕМБЕРЕ

● Ульян каласындагы «Биләр» мәдрәсәсе.

наклар җыелган. Мәдрәсә җитәкчелеге хәзер кульязмаларны цифрлаштыру, аларны киләчәк буыннар өчен дә саклап калу өчен бөтен көчен куя. Безнең бабаларыбыз язып калдырган китап һәм кульязмаларны юкка чыгару өчен большевиклар хакимияте болай да аз көч куймады. 1929 елда игълан ителгән Сталин фәрманы буенча, йортының идән астыннан яки чормасыннан гарәп язучы кәгазьләр табылган мөселманнарны ким дигәндә 10 елга Себергә сөрделәр, ә галимнәр һәм муллаларыбызны диварларга терәп атып үтерделәр. Ислам тарихын, мөселманча язмаларны янә дә юкка чыгаруга юл куярга ярамый.

Каддафи Коръәне

Өлкәнең мөселман җәмгыяте үзенең киләчәк үсешен яшь буында күрә. Мөфтинең яшьләр сәясәте буенча махсус урынбасары бар, бу эш Рәсүл Фәтхуллова тапшырылган. Мөселман җәмгыяте тырышлыгы белән каладагы икенче Җәмигъ мәчетенә ремонт үткәрелгән. Эшләрен тагын да җәелдерү өчен мәчет янәшәсендәге тагын бер бинаны сатып алганнар. Анда ислам балалар бакчасы ачу планлаштырыла. Шул ук бинада Рамазан ае барышында Ифтар ашлары да уздырганнар. Мөфти урынбасары сөйләвенчә, мәҗлесләрнең һәркайсына 150-180 диндар чакырылган. Мондый һәр мәҗлес өчен 30 мең сум чамасы чыгым таләп ителә, Аллаһыга шөкер, аларны уздыру да бизнесчы туганнар һәм ислам җәмгыяте ярдәмгә килә.

Икенче Җәмигъ мәчетенең үзгәлеге шунда – бинада кабатланмас Коръән нөсхасы саклана. Зурлыгы буенча ул аркылыга бер метрдан да артып китә. Бу реликвияне үзвакытында Ливия дәүләтенең лидеры булган Муаммар Каддафи Россиягә ясаган соңгы визиты барышында бүләк иткән икән. Коръән күпмедер ара Мәскәүдә сакланылган, аннары Ульяновск өлкәсе мөфтиятенә бүләк ителгән. Әйбәт ядкәр. Үз илендәге һәр яңа өйләнешүче парга 60 ар мең доллар акча белән ярдәм иткән, һәр студентын чит илләрдәге иң мәртәбәле университетларда дәүләт хисабына укытып кайтара алган башка бер дәүләт башлыгы җиһанда юк. Каддафи уч төбе кадәрге илдә коммунизм төзеп күрсәтте, әмма долларны юкка чыгару турында сүз башлаган лидерны яллы җанкыярлар шундук юкка чыгарды. Мондый лидер якын арада бик тиз күренмәстер, ә бүләге шул ягы белән дә үтә кыйммәтледер.

Семберлеләр өмете

Ульян өлкәсендә яшәүче һәр татарга дөньякүләм вакыйгалар барышын татар телендә нәшер итәлә торган бердәнбер «Өмет» газетасы җиткереп тора. Аны тәҗрибәле матбугатны Исхак Хәлимов җитәкли. Газета 1990 еллар башында ук гамәлгә куелган, өлкә казнасы хисабына чыгарыла.

● Муаммар Каддафи Россиягә бүләк иткән Коръән.

Бүген газетаның атналык тиражы – 4600 данә. Аны Казан типографияләрендә бастыралар һәм өлкәнең барча район почталары аша тараталар. Редакция газетага реклама бастыруга басым ясамый, күбрәк әбунәчеләр ярдәменә таянып дөньяга тарала. Редакциядә 7 хезмәткәр эшли. Газета үзенең сайлаган юлына хыянәт итмичә, татар мәнфәгатен яклый, милләтнең тарихын кайтару, татар теленең кулланылышын җәелдерү өчен көч куя. Абруе зур. Газетаны күрше өлкәләрдә дә байтак алдыралар.

Студентлар янында

«Татмедиа» вәкилләре Ульяновск дәүләт университетында да кунакта булды. Аларны ректор Борис Костишко үзе каршы алды. Дустанә әңгәмә барышында университет сайлаган тармаклар һәм өлкәдә аеруча таләп ителгән профессияләр турында сүз кузгалды. Ульян университеты 1988 елда Мәскәүдәге Ломоносов исемендәге университетның филиалы буларак эшли башлаган. Беренче елда 200 генә студент кабул иткәннәр. Әмма 1995 елда университет инде мөстәкыйль уку йортына әверелгән. Бүген анда 14 меңгә якын студент белем ала. Сәере шул: студентларның байтагы тора-бара күрше республика һәм өлкәләргә, хәтта Мәскәү белән Петербургка да күчеп китү, ягъни укуын шунда дәвам итү ягын карый икән. Шуңа күрә университет коллективы хәзер мәктәпләр белән турыдан-туры элемтә урнаштыру һәм Ульян өлкәсендәге предприятиеләр белән дуслашу сәясәтен алып бара.

Югалган китапханә

Сембер каласының тарихы татар милләте белән тыгыз бәйләнгән. Революциягә кадәр үк Сембернең үзендә сәүдәгәр Акчуриннар яшәгән бит, алар районнарда мануфактура фабрикалары да тоткан. Дөрес, алар тырышлыгы халык талап кесә калынайтуга гына калмаган, үз туганнарын гыйлемле итү өчен дә бик күп көч куйганнар. Акчуриннар татар җәмгыяте өчен 400 мең данә китаптан артык мирас туплаган зур китапханә ачкан. Ни кызганыч, бүген Карамзин исемен йөртүче өлкә китапханәсендә Акчуриннан фондыннан 200 генә китап сакланып калган. Моны китапханәнең сирәк кульязмалар бүлеге мөдире Людмила Ивашкина да яшерми. Акчуриннар төзеп калдырган китапханә ядкәрләренең беренче битендә мөһер һәм француз теленә күчерелгән атамасы ярылып яткан булса, хәзер тулысынча диярлек «каядыр» юкка чыккан. Акчуриннар аеруча Шәрык тарихы, әдәбияты һәм ислам китапларын туплауга көч сарыф иткән бит, ә большевик комиссарларга алар кирәкмәгән.

Китапханә аеруча 1864 елгы янгын вакытында ук коточкыч зыян күргән. Улчакта Карамзин китапханәсенең дә меңәрләгән китаплары янган. Ә Акчуриннар китапхәчесенең йөз меңләгән китабын кайсы базга кертеп тутырганнар, әллә тулысы белән яндырып юк иткәннәрме, белүче юк.

Кайнар очрашу

«Тетмедиа» вәкилләре, соңгы эш итеп, өлкә губернаторы Алексей Русских белән очрашу уздырды. «Татмедиа» агентлыгың генераль директоры Айдар Сәлимгәрәев губернаторга Карамзинның «История государства Российского» китабын һәм татар ядкәрләрен бүләк итте. Матбугат редакторлары катнашкан әңгәмә барышында Татарстан белән Ульяновск өлкәсе өчен иң әһәмиятле юнәлешләр буенча хезмәттәшлек, татар халкының милли йөзен саклап калу буенча бурычлар турында сөйләшүләр булды.

«Миллиард татар» челтәреннән.
Русчадан Вахит ИМАМОВ тәрҗемәсе.

Мәдәни җомга
28 июль
№29, 2023

Бу хикәятнең авторы – Зыя Вәли улы Латыйпов 1891 елда Казан губерниясе Тәтеш районы (хәзерге Апас районы) Тутай авылында туа. Ул безнең бабабыз – Галиев Садыйкның ике туган абыйсы.

Ул Үзбәкстанның Ташкент шәһәрендә яши иде. Аның без кечкенә вакытта Ташкенттан Тутай авылына кайтуын, әти-әниләрнең аны бик хөрмәтләп каршы алуларын хәтерлим. Без аны «Зыятдин абый» дип йөртә идек. Аның безнең авылда да, бүтән авылларда да дуслары бик күп иде.

Апаның әйтүе буенча, соңгы кайтуында ул Тутай авылының тарихы турында мәгълүматлар җыйган. Бу 1968 еллар булган. Ни кызганыч, әти исән вакытта Зыятдин абый турында сорашып калмадык.

Бу хикәятне 2000 еллар башында Ташкенттан аның улы Инсан абый (ул хәзерге вакытта мәрхүм) икетуган апабыз артыннан җибәргән иде.

Илсөяр Кадыйрова.
Казан шәһәре.

ПАРОХОДТА ОЧРАШУ

Зыя ЛАТЫЙПОВ

Мин «Самолет» җәмгыятенең «Лермонтов» атлы пароходында иң арзанлы билет белән кереп утырырга урын таба алмыйча, машиналар әйләнгәнне карап, тимер бүрәнәләрне пош-пош көчәнеп, кем генә әйләндерә икән дип шаккатып тәрәзәләр аркылы карап торганда, искәрмәстән бик көчле тавыш белән кычкырып җибәргәнгә сискәнеп киттем. Бу тавыш миңа: «Әй, малай, анда нәрсә карап йөрисең!» – дигән төсле тоелды. Ул арада тагын әллә ничә кыңгырау берьюлы шылтырап, калын бүрәнә төсле тимерләр акрын гына бер югары менеп, бер түбән төшеп, үзләре төсле үк тимерләрне әйләндерә башлады. Бу тимерләрне алар икәүләшеп әйләндерә икән дип ныклап ышана төштем, аннан соң да кычкырып, шылтыратып сөйләшүчеләр ике-өч мәртәбә кабатланганнан соң, әлеге авыр бүрәнәләр бөтенләй туктап калды. Шуннан соң бер тавыш «на место» дип кычкырды да, кешеләр берсен-берсе этеп-төртеп, пароходның тышка чыга торган ишегенә таба йөгерә башлады. Карасам, пароход үзем утырган пристань төсле үк бер дебаркадерга туктаган икән. Ул бер шәһәр булып чыкты, анда бик зур цемент заводы бар икән. Аннан пароход туктауга, брезент тужурка, чалбар кигән кешеләр тимер мичкәләрне тәгәрәтеп пароходка кертергә тотынды. Алар ашыга-чаба иде, шулай да аларның безнең телдә сөйләшүен аңлап өлгердем. Боларның һәр мичкәсе ун поттан булса, бу пароход ике йөз генә мичкә ала, дигән сүзләре колагыма керде.

Алар бер сәгать эчендә пароходны аяк та басар җир калдырмыйча тутырып та куйды. Аның белән генә дә бетмәде, ике җирдән идән астын ачып, мичкәләрне аска шудырдылар. Аларның бөтен хәрәкәте машина төсле: мичкәләрне бер алкага югары башын бәйләнгән арканга тәгәрәтеп кертәләр дә, үзләре кире ярга йөгереп чыга, өстә ике кеше әлеге арканнар буенча мичкәләрне аска тәгәрәтеп тора.

Мин аларның шулай кызып эшләгәннәрен карап торганда, әлеге әйләнгән җирдәге урыныма мичкәләр тезелгән, ул мичкәләрнең өстенә яңа шушы пристаньнан кергән халык та төялгән. Алар янына барып, бу минем урын дип әйтерлек бер генә дә билгеле нәрсәм юк, мин бер борылып әйләнеп карап чыктым да, анда утыру-яту түгел, басып торырлык та җир юк, мичкәләр белән каюталар арасында бер генә кеше кысылып йөрерлек урын калган. Мин чак кына торгач бер кечерәк, бушрак җир күреп, шунда читкәрәк сыендым. Анда яңа гына суккан бакыр акча төсле ялтырап торган трубаларга тоташтырган ике җиз бочканың берсеннән бөркеп пар чыгып тора иде.

Шул арада пароход баягы тавыш белән озак кына сузып акыртып торды да, күз ачып йомганчы гына туктап торып, тагын бер мәртәбә чабыштан килеп тирән сулыш алган йөгерүче сыман,бөтен күкрәге белән уфылдап куйды. Ул аның белән генә калмыйча, тагын да ике тапкыр уфлап, өченче мәртәбәсендә тагын да катырак итеп уфлап, берәүне бик каты итеп орышкан-сүккән төсле, нигә мине ычкындырмыйсыз, минем һәр минутым акча, дигән төсле кычкырта иде. Мин инде бая карап барган юан тимер бүрәнәләрне якыннан ук сөялеп карый алмыйм, миңа андагы үзләре күренми генә сөйләшкән ике кешенең тавышлары баягыдай ишетелми, ерактан бүленеп яңгырый иде. Пароходта утлар яндырылды, көн кичкә әйләнеп бара, утырып аякларны ял иттереп алырлык җир дә юк, аз гына артыңны терәргә дисәң, юк, бу җирдә әнә кем ята, бу кеше урыны, диләр.

Минем әлеге посып торган почмагым да үземә насыйп булмады, бер сап-сары сакаллы күн фуражка кигән кеше килде дә, «ну-ка…»дип тагын нәрсәләрдер әйтте. Мин «ну-ка!» дигәч, бу сүзләрнең минем файдага түгел икәненә төшендем. Шул җирдә якын гына утырган бер мишәр абзый миңа матросның кайнап торган куб янында якын торырга ярамый дигәнен анлатып бирде. Мин ике сүзгә төшендем, теге кызыл бакыр кисмәкне «куб» дип әйтәләр, ә бу күн кәпәч кигән урысны «матрос» дип йөртәләр икән. Шул көннән соң мин кайда гына күн кәпәчле кеше күрсәм, матрос, дип йөрдем. Ә бәлки ул чынлап та шулай булгандыр?

Мин һич кая урнашырга да рәт булмагач, әнинең чәйдән бушаган калай тартмага салып биргән бер йомарлам мае белән ярты арыш ипие салынган ямаулы киндер капчыгымны ике бот арасына кысып, бер чуен бүкән өстенә барып утырдым да әкрен генә карап барам: өске сәкедә уку яшендәге бер ир бала һәм ике кыз бала кулдан төшермичә көлешә-көлешә китап укый. Мин өчен иң кызыгы – аларның урысча китапны тоткарсыз укуы һәм укырга мөмкинчелек бирелү, барыннан да бигрәк сокландырганы өске сәкедә тәгәрәшеп уйнашып ятулары булды: алар шушы минутта нинди бәхетле иде!

Минем дә бит кечкенә генә булса да сөеп укый торган бик кадерле китапчыгым бар, аны капчыкны җайлап куеп, үзең утырып рәхәтләнеп укырлык бер урын булса иде дә бит… Тагын да теге күн кәпәчле, зәңгәр күлмәк-ыштанлы сары сакал килеп, монда утырырга ярамый, дип куа башласа? Әле бит капчыгыңны алдың да, тордың да киттең түгел. Уйланып утыра торгач тегеләргә кызыктым да, азрак ачуым да килде. Ни булса шул булыр дип, минем күтәрә алмаслык йөгем юк бит әле дидем дә, капчыгымны чишеп югарыда әйткән сөекле берничә биттән генә торган сурәтле-көйле «Иман шарты» кадәрле генә китапчыгымны алып, аны тагын ике аягым арасына кыстым да укый башладым. Шул минутта җәелеп утырырлык урыным да булса, мин югарыда яткан өч баладан күпкә бәхетле булыр идем.

Шул китапчыкны укып утырганда аркама берәү килеп кулын салгач, мин очкын чәчрәгәндәй атылып тордым. Мин бу кулны теге күн кәпәчле сары сакалның кулымы әллә дисәм, артымда миңа караганда шактый олы гәүдәле, матур гына, өсте-башы да җүнле генә үсмеррәк татар егете басып тора иде. Ул сүзгә керешүдән элек кулымдагы кечкенә китабымны алды да башыннан ахырына кадәр берәм-берәм битләрен актарып карап чыкты. Миңа карап:

– Син кайда утырдың? – диде.

Мин утырган пристанемны әйткәч:

– Шунда торасызмыни, әллә авылыгызда китап кибете бармы? – дип сорады.

– Юк, мин авыл малае, китапны миңа бер Казанда укучы мулла малае истәлек итеп, Казаннан кышкы ялга кайтканда алып кайтып биргән иде.

– Кара син, мулла малае булса да, күңеле киң икән, – диде.

Мин ул вакытта әле кешеләрне аера белми идем. Егет тагын сүз башлап:

– Ул мулла малаең укытучы булырга укыймы, әллә берәр доктор фәлән булачакмы? – диде.

Халыктан ишетүемә караганда аны әти-әниләре мулла булуын тели икән, ә шәкерт алар әйткәнгә якын да килми имеш, мин язучы булам ди икән.

– Аның әтисе сезнең авылда мулла мыни?

– Юк, күрше авылда, бездән алты-җиде чакырым, Кыр Тәүгелдесе дигән авылда.

– Син аны кайдан белеп, ничек таныштың?

– Безнең авылга якын гына торган Кишер Аксуы дигән авылдан бер кибетченең кызы Казанда укый. Алар көзен китеп укый да, кышкы ялга кайтып, авылда бергә була. Менә шул вакытта бу шәкерт Аксуга баргалап йөри икән. Безнең эти бу кешеләргә һәр атнада Казаннан мал кайтара, эти алар белән яшьтән үк, Шәрәфи байның атасы Хөсни бабай вакытыннан ук чын хезмәтчеләре булып беткән. Кышкы көннәрнең берендә безнең эти мал төяп Казаннан Шәрәфи абзыйларга кайтып керсә, бу шәкерт шунда була, алар сөйләшеп китә. Шул арада сүзгә Шәрәфи абзыйның Шиһап дигән туганы шәһәрдән укып кайтса да, бер эшкә бил бөкмичә сәүдәгә катнашып киткән авылдагы баласы да кушыла. Шәрәфи абзыйның биш ир бала, биш кыз бала. Шиһаптан кала балаларының барысы да Казанда, барысы да зур кешеләр рәтендәгеләр. Шиһап абзый этигә тәкъдим ясый. Г. абзый менә бу шәкерт фәлән хәзрәтнең баласы, Казанга китәргә кирәк иде, югыйсә укуына кичегә, – ди. Эти каршы бер сүз дә әйтми: «Ярый, кайчанрак китә соң ул. Миңа дүшәмбе юлга чыгарга кирәк», – ди. Шәкерт шул көнгә риза була. Эти әйтә: «Син шәкерт якшәмбе көнне кичтән бездә булырга тиеш, мин кире якка барып йөри алмыйм», – ди.

Менә шәкерт якшәмбе көнне безгә көндездән үк килеп төшә.

Мин мәктәптән кайтып керсәм, бездә бер яшь кенә, баласыман гына бер егет утыра, ул яңарак кына килгән икән. Мин аны шунда ук, бу шул кеше икән дип уйлап куйдым. Мин сәлам биреп керүгә бишмәтемне, каталарымны чишкәнне дә көтмичә, ул минем кулларымны кысып: «Туңдыңмы?» – диде. «Шушы мыни инде төпчек шәкертегез?» – дип, этидән сорап куйды, ул миннән күп нәрсәләр турында сорашты.

Әлбәттә белә микән дигән сорашу булмагандыр, миңа төшендерү нияте белән сорашкандыр инде, ул вакытта мин нәрсә беләм соң әле. Ул миннән: «Габдулла Тукайны беләсеңме?», – дип сорады. Мин ишетеп кенә беләм, дидем.

– Кемнән ишеттең?

– Безнең күршегә Әхмәтша абзый белән хатыны Нәгыймә апалар һәр кышны Гайшә дигән кызлары белән кайта, Гайшә апа безгә үзенең кечкенә генә гармунын уйнап, Габдулла абыйның үзе язган һәм үзе җырлаган матур көйләрен өйрәтә. Ул песи баласы кадәр генә гармунның тавышы, тәрәзәләр ачык булса, күрше авылга да ишетелеп торыр иде. Гайшә апаның бигрәк тә «И, туган тел» – дип, үзе уйнап, үзе җырлый торган бер матур көе бар иде, ул менә бу көйне балалар да, картлар да яраталар дип уйнап җырлый иде, ул аны безгә дә өйрәтте, мин бөтен мәктәптәге балаларга өйрәттем! – дигәч минем янымда басып торган җиреннән кузгалды да эскәмия өстенә куйган кечкенә чемоданын барып ачты, китаплары арасыннан кечкенә генә сурәтле бер китап алып бирде.

(Дәвамы киләсе санда.)

Гүзәл авылым Байсар

(Тарихи китаптан өзекләр)

(Ахыры. Башы 26-28 нче саннарда).

Бөек Ватан сугышына Иске Байсар авылыннан 300 дән артык яугир киткән дә, 221 е әйләнеп кайтмаган. Исән калганнар арасында Байсар урта мәктәбендә ким дигәндә 30 ел буена директор урынбасары яисә укыту мөдире булып эшләгән Шәриф абый Әгъзәмов бар иде. Бер аягы юк, протез киеп йөри. Бәйрәм көннәрендә күкрәгенә орденнар да тагып килә иде. Инде байтак еллар узгач кына белдек: ул Волхов фронтында, һәрьяклап дошман чолганышында, адәм баласы күтәрә алмаслык коточкыч шартларда яу кылып йөргән икән. 1990 елларда, тарихи хакыйкать беркадәр ачыла башлагач кына аңладык: Ленинград блокадасын Любна каласы ягыннан бәреп кереп өзәбез һәм анда ачтан кырылган бер миллион кешене коткарабыз, дип 1942 елның 29 гыйнварында генерал-лейтенант, әле бер ай элек кенә шәхсән Сталинның үз кулыннан Ленин ордены алган Власов кул астында 392 мең солдаттан хасил 2 нче армияне Волхов казанына кертеп җибәргәннәр. Апрель аенда шушы ук казанга үз теләге белән Муса Җәлил дә «Отвага» газетасында эшләргә килеп төшкән. Чолганышта калган совет солдатларын унар тапкыр йә Любнага, йә Мясной Бор юнәлешендә һөҗүмнәргә ташлап караганнар. Ләкин ярты ел элек үк тимербетон дот һәм блиндажлар төзеп куйган немец фашистлары аларның һәр һөҗүмен әйләндереп аткан. Күз алдыгызга гына китерегез: фашист самолетлары чолганышта ятучы совет солдатларының позицияләрен көн саен бер үк төрле график буенча, тәүлегенә 20 шәр тапкыр бомбага тотып торган. Ә безнең яктан өстәмә корал, өстәмә патрон һәм снаряд кына түгел, хәтта солдатларга ризык китерүче дә юк. Тоташ сазлыктан хасил бу казанда ач солдатлар түмгәкләрдә тишеп чыккан һәр мүк җиләген төбе-тамыры белән, ә агач кайрыларын өч метр чамасы биеклеккә кадәр ашап бетергән!.. Ниһаять, 15 июнь тирәсендә 2 нче армия солдатларына Мясной Бор юнәлешендә һөҗүм ясап, чолганыштан чыгарга рөхсәт бирелгән. Ләкин андагы коридорның киңлеге кайбер җирдә ике километрдан, ә иң тар бугазларда 600-700 метрдан да артып китә алмаган. Армия хезмәтен узган ирләр белә булыр: автомат яисә мылтык пулялары километр ярымга кадәр ераклыкка оча. Ә ике яктан да туктаусыз атып торган туп һәм пулеметлар уты, күктән дәһшәт бөркеп яуган самолет бомбалары астында ул шешә бугазыдай тар коридордан ничек исән-имин көе чыга аласың ди? Кайбер урыннарда өчәрдүртәр катлы мәет өемнәре үсеп чыккан, халык чебен урынына кырылган. 26-27 июнь тирәсенә чолганыштан исән көе чыгу бәхетенә ирешкәннәр саны 30 меңгә дә тулып җитә алмаган... Ләкин әле совет ягында да яртысыннан артыгы яралы булган солдатларны Смерш роталары көтеп тора бит. Исән чыкканнарның яртысы шундук сөргеннәргә таба юл алган...

Беребез дә сорашмады, без белмәдек: мәктәп коридорларында протез шыгырдатып йөргән Шәриф абый менә шушы Волхов мәхшәрен кичеп чыккан икән, бер аягын шунда өздергән. Математикадан укытучы Флүн абый Сәлаховның бер кулында бармаклары юк иде, ул да шушы казанда газап чиккән. Без сорашсак та, алар әйтмәс иде. Фронтта соңыннан илнең иң зур хыянәтчесенә әверелгән генерал Власов кул астында хезмәт иткән булу – йә, горурлыкмыни?.. Тик бер сорау борчый, Шәриф абый белән Флүн абый ул Волхов казанындагы газапларга ничек түзде икән? Әллә, каһарман Җәлил язгандай, аларга да пистолетлары хыянәт иткәнме?..

Исән кайткан дип саналучы Газдали абый Шәйхеразыевның исемен дә телгә алыйк. Ул – авылның беренче шоферы булган кеше. Фашистлар басып кергәч тә, яу кырына Зис-5 – «Полуторка» машинасы белән бергә китеп барган. Әлбәттә, окопларга снаряд һәм патрон тартмалары ташырга да туры килгән. Бервакыт аның өстенә дошман самолеты килеп чыккан да Газдали абый машинасын бомбага тота башлаган. Газдали абый машина рулен уңга-сулга боргалап качарга маташкан маташуын, иллә мәгәр сул кулын пыяласы төшерелгән ишек тәрәзәсеннән алу турында уйлап өлгермәгән. Кирәк бит, әй, фашист соңгы бомбасын ыргыткач як-якка таралган кыйпылчыкларның берсе Газдали абыйның тәрәзәдән чыгып барган кулын кылычтай кисеп төшергән...

Сугыш башлангач, Байсарга да Балтыйк буе республикаларыннан эвакуацияләнгән качакларны китерәләр. Өч елга якын гомерен Байсар мәктәбендә немец телен укытуга багышлаган Лилли Промет соңыннан эстон халкының күренекле язучысына әверелә. Аның «Ирләрсез авыл» дип исемләнгән романы Байсар төбәгендәге вакыйгаларга нигезләп язылган. Соңыннан күренекле шагыйрь булып китәчәк Әминә Бикчәнтәева да сугыш елларында Байсар мәктәбендә татар теле һәм әдәбиятыннан дәрес бирә.

● **Авыл үзәгендә җирле үзидарә бинасы һәм аның каршына куелган Ш.Шәймәрдәнов бюсты.**

● **Немец әсирләре 1915 елда төзегән диспансерның сакланып калган бер бинасы.**

Сугышның менә шундый коточкыч шартларында да Татарстан халкы, авызыннан өзеп, фронтка 23 мең данә кыска тун, 54 мең пар киез итек, 59 мең сырма фуфайка, 106 мең пар җылы эчке киемнәр озата. Моннан тыш, 1941 елның икенче яртысында ук халыктан оборона фондына «ихтыяри-мәҗбүри» рәвештә акча җыю башлана. 1942 ел башына бу фондка республика 16 млн сум акча тупласа, 1943 ел ахырына бу сумма 51 млн сумга җитә. Өстәвенә, әле «Социалистик Татарстан» исемен йөртәчәк авиаэскадрилиясе төзү өчен дә җай табарга кирәк, 102 өстәмә хәрби бомбардировщик та шул рәвешчә халык акчасына җыела...

● **Сөн елгасы аша төзелгән асылмалы басма.**

Әле сугыш тәмамланып та бетмәгән көйгә Татарстан халкы җилкәсенә өр-яңа бурычлар да ява. Немец полкларын Сталинград янында тар-мар итеп куугач ук, тәмам җимерелеп беткән каланы торгызу, дошманнан азат ителгән Орел өлкәсен сафка бастыру өчен 1943 елда эшелон-эшелон яшьләр төзелеш эшләренә озатыла. 1944 елда Севастопольне азат итүгә, җир белән тигезләнгән каланы торгызу өчен Татарстаннан янә 4 поезд эшелоны Кырымга юл ала. Сүз дә юк, алар арасында актанышлылар да бик аз булмагандыр...

Иске Байсар төбәге өчен бик тә мөһим булган зур бер үзгәрешкә тукталырга кирәк. 1948 елның көзендә Байсар авылында да, ниһаять, мөстәкыйль машина-тракторлар станциясенә (МТС) нигез салына. Аның директоры итеп Әзһәр Даутов билгеләнә. Шул елның көзге кыр эшләрен, ягъни сөрү һәм чәчүне МТС механизаторлары башкара. Тәүге елда МТС карамагында 8 трактор, 6 комбайн, 7 автомашина булса, ун елдан соң аның сафында инде 40 трактор, 36 комбайн, 18 автомашина исәпләнә. 1958 елның башында Байсар МТСы Калинин районының Пучыга урнашкан станциясенең филиалы гына булып кала. Ә бер елдан соң тәмам бетерелә...

Әмма 1960 елларда «Кызыл Сөн» колхозы үзе дә аякка баскан иде инде.

1965 елда ук колхозның машина-трактор паркында 48 трактор, 24 комбайн, 16 автомашина исәпләнә иде. Хуҗалык карамагында булган 7038 гектар чәчүлек җиренең һәрбер гектарыннан 15 центнер чамасы иген уңышы, кукуруздан хәтта 666 центнер уңыш алдылар. Фермаларда 1834 баш мөгезле эре терлек, 409 баш ат, 1834 баш сарык һәм 1191 баш дуңгыз асралды. Колхозның бер еллык чиста кереме генә дә 866 мең 543 сум белән бәяләнә иде...

1967 елның 26 июлендә Иске Байсар мәдәният йортында колхозчыларның гомуми җыелышы булып узды һәм «Кызыл Сөн» – Шәймәрдәнов исемендәге колхоз итеп үзгәртелде. Алдагы ел авыл хуҗалыгы өчен бик кулай килде дә, берләштерелгән, 8 авыллы колхоз игеннәрнең һәр гектарыннан 23 центнер уңыш алуга иреште. Савым сыерларының гомумсаны 780 баш исәпләнә иде, аларның һәркайсыннан 2232 килограмм сөт алдылар, ул елда дәүләткә 3979 центнер ит тә озатылды. 1970 елда савымчы Фәндәрия Зәкиева һәр сыердан 3380 килограмм сөт савып, район күләмендә алдынгылар сафына басты. Шул ук елда, В.И.Ленинның тууына 100 ел тулу уңаеннан колхоз механизаторлары Салихҗан Хөсәенов белән Назыйф Шәемов, терлекче Галия Бәхтиева хөкүмәт тарафыннан Октябрь Революциясе орденнары белән бүләкләнде...

Ферма һәм ындыр табагы биналары сакланып калса да, Шәймәрдәнов исемендәге колхоз да 30 ел чамасы элек үк юкка чыкты инде. Авылда хәзер җаваплылыгы чикләнгән «Ташкын» җәмгыяте эшли. Аны 40 ел буена Россиянең атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре, авылыбызда туып-үскән Рәүхәт Салихҗанов җитәкли.

Вахит ИМАМОВ.



«МИЛЛИ НИГЕЗЕБЕЗНЕ

Башкортстанның Октябрьск шәһәрендә яшәп иҗат итүче милләттәшебез, рәссам Гөлнара Фәләхованың иҗаты һәрчак милли тема белән үрелеп бара.

Аның хезмәтләренә карата тамашачылар фикерләре һәрвакыт бертөсле: «Рәсемнәре беркем эшләренә дә охшамаган! Рәссам – зәвык иясе!» Гөлнараның ямьле, кызыклы иллюстрацияләре иҗат белән бәйле социаль челтәр битләрендә дә беркетелә. Аларны карап баручы сәнгать сөючеләрнең фикерләре дә нәкъ шундый. Алар Гөлнараның рәсемнәре нәшер ителгән китапларны, дивар календарьларын, тәбрикнамәләрне дә җыеп бара. Аның әсәрләренә гашыйк булучылар: «Гөлнараның искиткеч иҗаты – йөрәк түребездә», – дип соклана.

Гөлнара кечкенәдән бирле рәсемнәр ясаса да, балалар сынлы сәнгать мәктәбенә бик теләп йөрмәгән. «Сәнгать мәктәбендәге белем бирү программасы күңелемә ошамый иде, – дип искә ала ул. – Киләчәктә дә үземне рәссам булырмын дип бик күзалламый идем. Әмма урта мәктәпне тәмамлагач, барыбер Башкортстанның М.Акмулла исемендәге дәүләт педагогика институтының сынлы сәнгать-графика факультетына укырга керергә карар кылдым. Ни дисәң дә, рәсемнәрне яхшы ясый идем һәм, моңа өстәп, үземдә игътибарлык, әйләнә-тирә дөньяга сокланып карау хисе булуын тоеп үстем. Югары уку йортын 2008 елда тәмамладым. Институтта белем алганда да, аннан соң да сынлы сәнгатьтәге төрле ясау алымнарын өйрәндем. Институтта укыткан остазларым арасыннан талантлы рәссамнар Рөстәм Мөгыйн улы Фәтхуллин һәм Тәлгать Хәсән улы Мәсәлимовны аеруча истә калдырдым, аларга биргән белемнәре өчен рәхмәт яусын!

Этника тематикасындагы рәсемнәремне ясаганда күңелемнән балачагымны барлыйм: минем әбием Фәимә һәм бабам Салих Татарстанның Мөслим районындагы Шуганка авылына яшәде. Алар янына кунакка кайтып йөргән чакларым әле дә истә. Алар минем белән бары тик ана телебездә генә сөйләште. Шуганкада хәзер дә ерак туганнарыбыз гомер итә. Ләкин дәү әниебез, дәү әтиебез вафат булгач, анда бик сирәк кайтам, әмма ул яклар белән бәйле хатирәләремне кадерләп саклыйм. Миллилек кушылган рәсемнәр өчен мөһим булган илһам әлеге истәлекләрем аша да барлана. Минем, әлбәттә, Казанга һәм Болгарга да килгәнем бар... Татар мохитенең игелекле булуы анда аеруча сизелә, дияр идем.

Әти-әнием исән-сау. Алар, минем карашка, иҗатка гашыйк затлар. Әтием Равил дәфтәр битләренә рәсемнәр ясарга ярата. Әнием Зөлхәбирә фармацевт булып эшләде, хәзер лаеклы ялда. Сеңлем Альбина бүгенге көннәрдә иллюстрацияләрем мотивлары буенча эпоксид сумалалы брошкалар ясый башлады, ул да иҗаты үз итә...»

Гөлнара Фәләхованың 2008 елны әзер булган «Йолдызлык» сериясе дә останың үзенчәлекле иҗатны үз итүче талант иясе икәнен раслый. Чөнки аның институттагы диплом эшенә караучы портретлары... киптерелгән яшел яфракларны ПВА җилеме беләнябыштырып һәм әзер сурәт өслекләрен лак белән ныгытып ясалган. Аларда – җырчылар З.Рамазанова, Ю.Шевчук, балет йолдызы Р.Нуриев, шагыйрь М.Кәрим сурәтләре. Билгеле, сәнгать өлкәсендә яфракларны тегәләр дә, аларга төсле җепләр белән чигәләр дә, аларны хәтта челтәрләп-челтәрләп кисәләр дә... Әмма бары тик төсле яфракларны гына

кулланып ясалган портретлар сирәк күренеш. Мондый сәнгати флористикада япон рәссамнары гына аеруча тырыштыр, мөгаен... Гөлнараның хәзерге рәсемнәре арасында да төп сюжетка табигать күренешләре өстәлгәннәре шактый.

Әлеге рәссам үз хезмәтләрен заманча компьютер программаларын кулланып иҗат итә. «Болай тизрәк ясала, уңайлы да. Әгомумән, миңа графика юнәлеше дә ошый әле. Шул ук вакытта цифрлы программалар белән генә үз хис-кичерешләремне күп төсләрдә күрсәтүгә дә өстенлек бирәм. Кайчак, кәефкә карап инде, катнаш техника да кулланам. Әйтик, рәсемне башта акрил буяулар һәм гади яисә акварель каләмнәр белән ясыйм да, аннары цифралы программада камилләштерәм.

Төрле мавыктыргыч китаплар өчен иллюстрацияләр иҗат итәм һәм әлеге төр иҗатка аеруча җаваплылык белән карыйм. Бу җаваплылык хисе нәшер ителгән китапны кулыма алып, аның битләрен ачып-ачып карагач кына юкка чыга... Заказлар Уфа, Казан, Санкт-Петербург китап нәшриятларыннан да бул-

НЫГЫТЫЙК!»

ды. Минем фикеремчә, безнең татар халык әкиятләре башка халык әкиятләреннән бер яклары белән дә ким түгел. Аларның бай эчтәлекләре буенча бик шәп рәсемнәр ясарга мөмкин. Әиң беренче китап иллюстрацияләрем 2017 елны ук рус телендә басылган «Зилян» («Җилән») татар халык әкияте белән бәйле булды. Бер дистәдән артык иллюстрациям 2021 елда Казанның «Юлбасма» нәшрияты тарафыннан татарча һәм русча нәшер ителгән «Үзем белдем, диген» татар халык әкиятләре китабы битләрен дә бизәде, бу китап уңыш казанды. Моннан кала «БХВ»да «Россия халык әкиятләре» сериясенә караган Ә.Фәйзинең «В стране смельчаков» дип аталган татар әкияте китабын бизәү өчен дә миңа мөрәҗәгать иткәннәр иде. Тиздән шушы ук нәшриятта тагын бер китап чыгачак, аның битләрендә төрек мотивлары аша чишелгән яңа иллюстрацияләремне күрерсез. Илһамны тормышның үзеннән, тирә-юнемдәге иҗатчылар әсәрләренә соклanudan, табигатьтән, татар көй-җырларыннан, төрле халык мәдәниятләреннән, дастаннарыннан җыям. Яңа проектларым өчен образлар уйларымда да туа, татар һәм башкорт халык әкиятләре аша да барлана...»

Моннан кала Гөлнара Фәләхова киездән келәмнәр, кием-салымнар да иҗат итеп караган. Әкайбер әсәрләрен, аеруча башкорт гүзәлләре ясалганнарын, инде зур күләмле киезләргә дә күчерергә өлгергән. «Киез сәнгате белән моннан берничә ел элек үк, төгәл итеп әйткәндә, 2008 елны, квалификацияне күтәрү курсларында танышырга туры килде. Башкорт авылларына барып, балалар сынлы сәнгать мәктәбе, югары уку йорты укытучылары, остазлар һәм студентлар белән бергәләп киез әйберләр ясауның борынгы алымнарын өйрәндек. Бер атна буе шәһәрдән еракта булдык, табигатькә сокландык. Киез басу процессын бик ошатам, чөнки соңгы этапта нинди сурәт килеп чыгасын алдан чамалап та булмый бит... Киездәге рәсемне энә белән киезләп ачыклау да ошый миңа, бу хезмәт хәтта аерым бер төр медитациягә дә тартым. Киез әсәрләр ясау нечкәлекләрен бүгенге көндә дәресләр вакытында үз укучыларыма теләп өйрәтәм», – ди оста. Талантлы рәссамыбыз Октябрьск шәһәренең балалар сынлы сәнгать мәктәбендә ун елдан артык укытучы булып эшли.

Аның хезмәтләре Башкортстан һәм Татарстан күргәзмә залларында экспозицияләнгән инде. Башкортстанның Көнбатыш рәссамнары иҗади берлеге әгъзасы Гөлнара Фәләхова әсәрләре «Урал» галереясында, М.Кәрим исемендәге Яшьләр театрында, Башкортстанның М.Акмулла исемендәге дәүләт педагогика университетының сынлы сәнгать-графика факультеты музеенда, Россиядәге һәм күп кенә чит дәүләтләрдәге шәхси тупланмаларда да бар.

«Минем балаларга сәнгати белем бирүдән туктап торган чагым да булды, ләкин үз белемем, туплаган тәҗрибәм белән уртаклашырга теләвем тагын сәнгать мәктәбенә укытырга кайтарды, – ди әңгәмәдәшем. – Һәр укытучы да үзе мавыккан сәнгать юнәлешләрен алга этәрергә омтыла, мин дә укучыларымны яңа идеяләр, яңа материал, чималлар белән кызыксындырам, аларны уңышлы композицияләр төзергә өйрәтәм. Иҗат ул игътибарлылык таләп итә, әбүгенге балалар бик игътибарлы димәс идем... Кайчак аларны милли темага кертеп җибәрү дә авыр. Хәзерге көндә заманчарак итеп язылган яңа әкиятләр дә бик кирәк дип саныйм. Бүгенге балаларга шундый әсәрләр күбрәк ошый. Гомумән алганда, алар милли темага рәсемнәрне теләп ясап китә». Гөлнара Равил кызының укучылары – сәләтле, тырыш балалар. Аларның Бөтенроссия күләмендәге бәйгеләрдә күп тапкыр җиңеп чыгуы Гөлнараның талантлы остаз булуын тагын бер кат раслый.

Рәссамның үз әсәрләрендәге этнографик детальләре гаять сокландыра. Аларда: милли киемле мөлаем хатын-кызлар төрледән-төрле уен коралларында моңлы көй барлый, яланяклы сылулар ни хакындадыр уйлана, гашыйк җаннар болын моңына колак сала, курку белмәс баһадирлар яңа җиңүләргә юнәлә, кечкенә шук кызлар дөньяларын онытып бии, көлә... Аның кәгазь битләрендә «Һөнәрле үлми, һөнәрсез көн күрми», «Үги кыз», «Зөһрә», «Өч кыз» кебек татар халык әкиятләренә багышланган эшләре дә бар.

«Тамашачыларымның, китап сөючеләрнең хезмәтләремә карап, мәхәббәт, тынычлык хисләре кичерүләрен, әкайберләренең үз нәсел тамырларын барлауларын, халкыбыз тарихына, аның традицияләренә, мәдәниятенә тагын да якыная баруларын телим», – ди Гөлнара Равил кызы.

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА.

● Хәсән Мусин.

ЦИРК АРТИСТЫ

Хәсән Мусинны клоун, шамакай, дияргә тел әйләнми. Аренада тамашачының күңелен ачса да, ул кеше көлдереп яшәмәде. Цирк сәнгатендә зур үрләрне яулады. Абруйлы язучылар аның турында китаплар язды. Фаҗигале үлеме дә бушка вакыт уздыручы шамакай түгеллеген, тирән, үтә нечкә хисле шәхес булганын искәртә.

Хәсән Ташкентта дөньяга килгән. Ата-анасының кем булуы, Хәсәннең ни өчен урамда калуы төгәл билгеле булмаса да, аның тормышын сурәтләп язган урыс вәкилләре татарга таш атырга онытмаган, «рано сбежал от татарских родителей» дигән сүзләр белән булса да милләтебезне мыскыл итәргә тырышкан. Татар ата-анасыннан качканга гына кеше булган, янәсе.

Бер көнне эсседән котылу өчен ул цирк галеркасына качып керә һәм шунда артистларның күзенә чалына. Арадан Аристархов фамилияле берәү баланың сыгылмалы тәненә игътибар итеп, үз канаты астына ала, акробатика серләренә өйрәтә башлый. Берничә ай үтүгә, алар бергәләп арена куполы астында төрле трюклар куя. Хәсән музыкага бик сизгер булып чыга. Аристарховта исә нинди генә музыка уен коралы юк! Мусин барыннан да бигрәк нәни генә гармунны ошата һәм гомере буе аннан аерылмый. Чарли Чаплинның таягы кебек, нәни гармун артист Мусинның аерылгысыз сәхнә юлдашына әверелә. Аристархов Хәсәннең цирк номерлары арасында тамашачының күңелен аучы артистлар чыгышларын яратып каравына игътибар итә. Тиз арада цирк аренасында Хәсән Мусин исемле йолдыз кабына. Башта ул Чарли Чаплинга охшатып уйнаса, соңрак берәүнекен дә кабатламый торган үз йөзен таба һәм шуның белән Советлар Союзы цирк сәнгатенең тарихына керә.

Фойеда касса өстендә «На Мусина все билеты проданы» дип язу чыгарып элгәннәр. Циркта керем кая төшсә, Хәсәнне шул шәһәргә керемне күтәрергә юллаганнар. Мусин «касса җыючы гастролер» булып халык теленә кергән. 1930 елларда Хәсәнне «Хезмәт Кызыл Байрагы» ордены белән бүләкләгәннәр.

Белгечләрнең әйтүенә караганда, татар артистын бүтән көлдерүчеләрдән нечкә юмор хисе, тормышны яратуы, зур иҗат куәсе, шуның белән бергә самимилек, балалык аерып тора. Бүтән клоуннар тамашачының игътибарын яулау өчен сәхнәгә шаулап, кычкырып, чиләк кагып чыкса, Мусин песи кебек йомшак басып, бернинди тавышсыз аренага керсә дә, барыбер бөтен тамашачыны үзенә карата. Музыкага сәләте дә егеткә иҗатта нык ярдәм итә. «Мусинның бөтен тәне җырлый сыман. Аның чыгышын карагач, үзеңне ритмика һәм пластика бәйрәмендә булып кайткандай рәхәт хис итәсең. Бу артистның йөзе, тәне, кул бармакларына кадәр җырлый кебек», дип язалар газета рецензияләрендә. Хәсәнебезгә «Арена Шаляпины» дип исем кушалар.

«Бал кортының балга сиземе ни дәрәҗәдә булса, Мусинның юморны сизүе дә шул чама», –дигән аның турында бөек артист Юрий Никулин. Грузин клоуны А.Тедиашвили татар артистының чыгышын затлы, кыйммәтле коньяк белән чагыштырган. Чордашы клоун Марк Городинский Мусинның чыгышын караганнан соң профессиядән китәсе килүе турында әйткән, гап-гади кеше Хәсән Мусин дәрәҗәсенә җитә алмый, дип аңлаткан ул. Артист Аркадий Райкин яшь чакта һәр кич саен циркта Мусинны каравы, аннан күп нәрсәгә өйрәнүе турында язган, яхшы комиклар күп булса да, көчәнмичә, җиңел тамашачының күңелен күтәрү сәләтенә бары тик Мусин гына ия, дип искәрткән. Танылган кино һәм театр актеры, театр институты профессоры Василий Меркурьев, студентларын циркка йөртеп, Мусинны карарга мәҗбүр иткән. МХАТның өлкән буын артистлары, Мусин гына эчкерсез, самими, аннан өйрәнегез, аның номерларын карап кына да бөтен Станиславский системасын өйрәнергә була, дип яшьләргә үгет-нәсыйхәт биргән. Әрмән циркының фәлсәфәче клоуны буларак телгә кергән Леонид Енгибаров Хәсәнебезне «клоуннарның клоуны», дия торган булган. Матур тасвирлау сәләтенә ия, күпләгән әсәрләр иҗат иткән әрмән артисты Мусин турында фантастик жанрда «Чуть-чуть» исемле бер миниатюра да язган. Анда вакыйгалар XXI гасырда бара. Яңа чорда бер цирк артисты Мусинның танылган номерын кабатлый, имеш. Башта – бармаклары белән урындыкка, аннары манеж инспекторының башына суккалый. Инспекторның башы буш, янәсе. Заманында Хәсән аганың самими бу номерыннан зал егылып көлә торган булган. XXI гасырда исә клоун нәкъ шуны ук кыланса да, беркем көлми икән. Урындыкка һәм инспектор башына бер үк ешлыкта сугылсын өчен, артист тырышып хәленнән тая. Ахыр чиктә, Мусин номеры яздырылган пленканы компьютерга салып карасалар, урындыкка һәм кеше башына сугу ешлыгы бер үк түгел икәнен аңлап шаккаталар. Артист Мусин секундларны исәпләп утырмаган, аны хәтта яза белмәгән, хәреф танымаган, имзасын куйганда да ярты сәгать маташып, тирләп пешә торган булган, диләр. Шуңа да карамастан зур уңышка ирешкән, чөнки сәнгатьтә салкын исәп түгел, күңел сизгерлеге кадерле. Аларны исә бер-берсеннән аз гына ара аера. Бу араны миниатюраның исеме үк әйтеп тора. «Чуть-чуть»...

● Валерий Хәсән улы Мусин.

Хәсән Гали улы Мусин хөрмәтенә «Раз. Два. Три. Четыре» дип исемләнгән халыкара мим-фестиваль үткәрә башлаулары да татар артистының нинди зур абруй казанганын раслый.

Бер рецензиядә Хәсән аганың башка күп комиклардан аермасы сыер мае һәм маргаринныкы кебек дип язалар. Аның турында китап язган артист, язучы Рудольф Славский Мусинны сандугач белән чагыштыра. Кенәри кошы матуррак булса да, ни ишетсә, шуны гына кабатлый, сандугачның исә һәр җыры үзенеке, дип ул татар артистының бүтән күпләгән көлдерүчеләр белән аермасын сурәтләп күрсәтә.

Ә бервакыт, атаклы «Бродяга» һинд фильмы экраннарда шаулап барган көннәрдә, Ленинградка анда баш рольне башкарган танылган артист Радж Капур килә. Һинд вәкилләген циркка алып баралар. Аренада – Мусин, залда – Радж Капур. Тамашачы кайсын карарга белми. Соңыннан һинд артисты сәхнә артына кереп, Хәсән аганың кулын үпкән, диләр. Һинстанда хөрмәт-ихтирамны шулай белдерәләр икән. Радж Капур Гали улы Хәсәнне Һиндстанга комедиядә төшергә чакырган. Кая ул елларда Һиндстанга бару...

Шулай да, Х.Мусин комедиядә төшә. Бөек Ватан сугышы алдыннан «Ленфильм» студиясендә комедия шәлкеме төшерергә уйлап, тәҗрибәле комедиограф К.Минцка мөрәҗәгать итәләр. Хатын-кыз роленә танылган Янина Жеймоны сайлыйлар. Ир-ат ролен безнең Хәсәнгә тәкъдим итәләр. «Приключения Корзинкиной» дип исемләнгән комедияне интернетта эзләп табарга мөмкин. Анда кассада билет сатучы тиктормас Корзинкинаның иҗат бәйгесендә уңышсыз чыгыш ясаган кыюсыз яшь артистка кабат сәхнәгә чыгарга ярдәм иткәндә пәрдә артында төрле кызык хәлләр булуы турында бәян ителә. Кыюсыз артистны безнең Хәсәнебез уйный. Ахырдан яшь чибәр Корзинкинаның мәхәббәтен сизеп батырайгач, ул Мефистофель куплетларын шундый итеп башкара ки, экраннан күзләрне алып булмый. Йөзендәге һәр сызык-җыерчыгы, кашлары да җырлый сыман, җырлап бетергәнче әллә никадәр рәвешкә керә. Артист дисәң дә артист! Комедия өчен музыканы атаклы композитор Дмитрий Шостакович иҗат иткән һәм Мусинның нәни генә гармунында уйнаган көйне кинофильмга кертеп җибәргән.

Кинокомедияне Бөек Ватан сугышы вакытында госпитальләрдә, военкоматларда, Ленинград кинотеатрларында күрсәтәләр. Гади, самими бу фильм сугышчыларга көч өсти, күңелләрен күтәрә, беразга булса да мәхшәрне оныттырып тора.

Беренче фильм уңышлы килеп чыкса да, комедия шәлкеме шул урында туктала. Атаклы артист Ролан Быков безнең Хәсәнне «Айболит – 66» фильмында өлкән разбойникны уйнарга чакыра. Мусин бу юлы да шәп уйнап чыга. Әмма ни кызганыч, экран карьерасы шуннан ары узмый. Юкса Юрий Никулин, Георгий Вицин, Сергей Филиппов, Савелий Крамаров, Михаил Пуговкин кебек популяр артист булачак иде ул, дип язган үзенең китабында артист, язучы Рудольф Славский...

1949 елның ахыры. Ленинград шәһәре. Кеше үтерүчеләр, талаучыларга амнистия игълан ителгән вакыт. Хәсәннең жонглер һәм акробатлар чыгышлары арасында уйный торган бер номеры була. Бөек Ватан сугышы истәлегенә жонглерлар реквизит пистолет, винтовка, гранаталар ыргытып уйнаганнан соң, коралларны җыеп тартмага тутырганда Мусин әле берсен, әле икенчесен чәлдермәкче була. Тамашачы егылып көлә. Ниһаять, бер наганны

ХӘСӘН МУСИН

● Кабатланмас Хәсән Мусин.

эләктерә. Ялгыш басып, наган атып җибәрә. Мусин коралны манежга атып бәрә. Наганга исә махсус пружина беркетелгән һәм ул манеж буйлап «сикереп» ата да ата. Мусин, куркудан төшеп киткән ыштанын һәм нәни гармунын сөйрәп, аның артыннан сикерә. Реквизит коралны бикләнә торган махсус тартмаларда саклыйлар. Әмма гонаһ шомлыгына, ул кичне карт реквизит саклаучы урынында булмый һәм Мусинга наганны тамашадан соң үзе белән алып кайтып китүдән бүтән чара калмый. Өстендә Аристарховтан калган кадими замандагы тун, башында рәхмәтле тамашачылар бүләк иткән төлке бүрек. Төн. Караңгы. Петр I һәйкәле янында Мусинны ике билгесез адәм туктата. «Сал туныңны, алайса җәһәннәмгә олактырабыз», – дигән сүзләрен ишетеп, Хәсән куркып кала. Мусин эчке кесәсендәге наганга үрелә. Шул вакыт кечерәк буйлысы өстенә сикерә, кулында пәкесе ялтырап китә. Мусин читкә китеп өлгерә. Әмма һөҗүм итүче төлке бүреген эләктереп өлгерә. Хәсән атып җибәрә. Аннары нәкъ номерда каралганча, наган артистның кулыннан ычкынып, карга төшә һәм сикерә-сикерә атуын дәвам итә. Карт һөҗүмчеләр өнсез кала. Озын буйлы явыз килбәтсез итеп карга барып төшә, икенчесе исә күздән юк була. «Тор, агай, тор», – дип Хәсән бәдбәхет һөҗүмчене ничек өнгә китерергә тырышмасын, тынсыз гәүдә җирдә ята бирә. Мусин анда бәрелә, монда йөгерә. Тик урамда бер җан иясе дә юк. Нева проспектына борылгач кына постта торучы толыпка төренгән, аякларына итек кигән бер милиционерны күрә.

– Иптәш милиционер, анда бер кеше ауды.

– Ничек ауды?

– Куркудан.

– Кайда?

– Император алдында.

– Нинди император! Син исерекме, берәр җирдән егылып, башыңны имгәттеңме?

– Юк ла.

– Каян килеп чыктың әле син?

– Цирктан.

– Хәзер күрсәтәм мин сиңа цирк! Милициядән көлергә уйладыңмы?

Постовой Мусинны якындагы милиция пунктына илтеп тапшыра.

– Фамилияң, атаңның исеме, туган елың?

– Беспризорник мин. Маршал Малиновский да беспризорник булган.

– Мин синнән Малиновский турында сорамыйм бит. Кая эшлисең?

– Циркта.

– Син шаяртуыңнан тукта, без циркта түгел, милициядә.

– Сың, циркта ат һәм филләр генә түгел, кешеләр дә эшли.

– Документларың нишләп юк?

– Бар. Үзем белән йөртмим. Мине болай да беләләр. Миңа «Сез» дип эндәшсәгез дә ярый, яшем дә олы. Мусин мин. Бөтен шәһәр буенча афишалар эленгән. Күргәнегез бардыр бит...

– Ишеткән бар бугай. Шулай да, сержант, бар Таһирны чакыр әле, ул тәгаен белә.

Йокысыннан айнымаган Таһир күренә.

– Монда милләттәшең, Мусин мин дип, безгә борчак сибә.

– Нәкъ үзе, – дип җавап кайтара, шатлыгыннан татлы йокысын онытткан Таһир.

Мусин һәйкәл янында булган хәлне сөйләп бирә. Наганны чыгарып өстәлгә сала. Кизү торучы милиция башлыгы бутафор коралны алай әйләндерә, болай әйләндерә дә, «чыннан да, цирк» дигән сыман каһәгатьсез башын чайкап, протокол кәгазенә нидер сырлап куя.

Җыйнаулашып Петр I янына баралар. Озын кара гәүдә урыннан кузгалып та карамаган, ничек ауган булса, шулай ята... Артист һәм реквизит саклаучыны ике ел төрмәгә хөкем итәләр. Циркта эшләүче халык һәм түрәләр ялварып сорагач, ике елны шартлы срокка алыштыралар. Тикшерү вакытында төлке бүрекне сатарга маташкан икенче һөҗүмчене тоткарлаулары һәм аның бергә амнистияләнгән дусты белән Мусинга һөҗүм итүе турында сөйләве дә бик ярдәм итә...

● Валерий Мусин Ю.Куклачевка кадәр үк мәчеләр белән чыккан.

Дөрестерме-юктырмы, Мусин шуннан соң эчә башлаган дип язалар. Нечкә күңелле артистка эчәр өчен ул елларда бүтән сәбәпләр дә хәттин ашкан, билгеле. Репрессияләр, ачлык, бандитларның бәйдән ычкынуы, пролеткульт сәнгатьне алга сөреп, буржуаз идеологиягә каршы көрәшү өчен фрак, цилиндр, ефәк, бәрхет, каурыйлар, ялт-йолт килгән сәйлән бөртекләрен тыеп, Чарли Чаплин һ.б. танылган сәхнә образларына табу салу гына да артистны эчәр дәрәҗәгә җиткерергә мөмкин ич. Аек акыл белән шуларга түзеп кара! Исереп онытылу нечкә күңелле иҗат кешесе өчен исән калуның бердәнбер чарасы булгандыр, бәлки...

Хәсән Мусин турында очерк язган Эдуард Кочергин язмышы гына да уйланырга мәҗбүр итә. Ата-анасын репрессияләр. Үзе Бөек Ватан сугышы вакытында балалар йорты белән Себергә эвакуацияләнә. 1953 елга кадәр Россиянең әле бер, әле икенче шәһәрендә үзенә урын таба алмыйча каңгырып йөргәннән соң, Лениградка, репрессиядән көч-хәл белән котылган анасы янына кайтып егыла. Затлы нәсел баласы барыбер үз юлын таба, РСФСРның халык рәссамы, Россия Сәнгать академиясенең академигы дәрәҗәсенә ирешә, ике тапкыр СССР Дәүләт премиясен, бер тапкыр Россия Федерациясе дәүләт бүләген ала. Э.Кочергин бәхетле йолдыз астында туган. Ә аның кебек язмышка дучар ителеп әрәм булган иҗат ияләре күпме? Шуны күреп яшә дә, аек акыллы булып кал, имеш...

Директорлар Хәсәннән йөз чөерә, циркка җәлләп кертсә дә, аренага якын җибәрми. Мусинны еш кына атлар янында күрәләр. Әле солы, әле яшелчәләр белән сыйлап, Хәсән аларга зарын сөйли. «Роза, бәгырь, мин аның авыру икәнен каян белим? Үзе һөҗүм итте ич. Әйт, Хәсән, гаепле түгел, диген, кулындагы пәкесен күргәч кенә, атып җибәрде, диген. Ышанасыңмы миңа, бәгырь?». Ат «әйе» дигән сыман башын селки. Хәсән рәхмәтен белдереп аны битеннән үбә, кылларын назлап сыйпый. Аннары Җитез исемле ат янына килеп, аны ышандырмакчы була...

«Элек керем күтәрә идем, хәзер тәмәке төпчеге күтәрәм», – дип Хәсән үзе турында шаяртып әйтә торган булган. Әмма язмыш аңа кабат елмая. Юлына цирк артисты Петр Маяцкийны китереп чыгара. Ул исә Украинада цирк коллективы туплый икән. Цирк велосипед кебек ике көпчәктә тора, аның берсе атлар булса, икенчесе клоуннар, дип Петр Маяцкий бу ике төр һөнәргә зур игътибар бирә. Һәвәскәрләрдән төркем туплап, аларга тәҗрибәле артистларны беркетә. Шулай итеп, Мусин Украина циркына барып чыга. Һәм 1956 елда яңа коллективы белән Чехословакиягә бара. Анда уңышлы чыгыш ясап, Украина циркының йөзек кашы сыман кадерле артистына әверелә.

Гомеренең соңгы көннәрендә ул кыргыз, татар циркларында, Новосибирск труппасында эшли һәм туган шәһәре Ташкентка әйләнеп кайта. Үләренә ике-өч ел кала фатирлы була. Хәер, аңа Ленинградта ук фатир биргән булалар. Әмма сугыш башлангач, ул фатирын яшь балалы ире сугышка киткән акробаткага калдырып, күрсәтмә буенча Уралга китә.

1982 елда атаклы артист, 68 яшьлек Хәсән Мусинны Ташкент циркы бусагасында табалар. 1 апрель – Көлке көнендә Бөтенсоюз күләмендә танылган комикны соңгы юлга озаталар...

Ни кызганыч, 1940 елгы улы Валерий Мусин мәшһүр этисе кебек зур үрләргә ирешсә дә, шул ук чирне йоктырып арабыздан бик иртә китә. РСФСРның атказанган артисты Валерий Мусин Куклачевка кадәр үк аренага мәчеләр белән чыккан. Монакога барыр алдыннан Валерий Мусин кояш нурларын тотып уйнаучы клоун турында номер куя. Әмма юлга кузгалырга өч көн калгач, каты авырып, үзе бара алмый, номерны тиз арада Олег Попов белән сәхнәләштерәләр. Попов конкурста гран-при ала һәм «кояшлы клоун» исеменә ия була. Бу хакта 2014 елда Павел Броништейн «Ржевский весник» исемле газетада «Украденный успех» исемле мәкалә дә бастырган. Валерий шуннан соң эчүгә бирелде, дип фикерен җөпләп куйган автор...

Миләүшә ГАЛИУЛЛИНА
әзерләде.

Рудольф Славскийның «Чародей смеха: очерки жизни и творчества» китабы һәм Эдуард Кочергинның «Реприза дядушки Хасана. Цирковая быличка» очерклы файдаланылды.

● Х. Мусин.

Мәдәни җомга
28 июль
№29, 2023

Соңгы ике-өч елда »Мәдәни җомга« газетасы битләрендә Сәгыйть Рәмиев турында шактый күп язылды. Без хезмәттәшләребез белән өлкән каләмдәшебез Сәгыйтьнең туган ягы – Күгәрчен районындагы Ибрай авылына да, ул дүрт ел буе »Идел« газетасын чыгарган һәм гомер иткән Әстерхан каласының Тияк бистәсенә дә бару бәхетенә ирештек. Ләкин ни кызганыч, элек Акман исемен йөрткән, хәзер Ибрайга әверелгән авылда бөек Тукайның талантлы замандашы, аның иң якын дусларыннан берсе булган Сәгыйть агай турында ишетеп, укып белүче сыңар кеше дә юк. Әстерхан каласында да сыңар гына урам яки ул яшәгән тыкырык та Сәгыйть Рәмиев исемен йөртүгә лаек табылмаган. Гомумән, Әстерхан каласында Сәгыйть Рәмиевка багышланган сыңар такта яки истәлек ташы да эзләп таба алмадык. Заманында Сәгыйть чакыруы буенча бөек Тукайның Әстерхан каласында бер ай да бер атна буе кунак булуы хакында да санаулы татарлар гына сөйләп бирә ала.

Безгә бөек Тукай белән серләр бүлешкән, иҗатташ дуслар булган Сәгыйть Рәмиевнең иясез, иске бүрек урынына типкәләнеп йөрүе бик кызганыч. Зыялырак кешеләр һәм галимнәр укып, бераз гына булса да бөек шагыйрь Сәгыйт Рәмиев истәлеге каршында баш ия, аны санлый башламасмы икән, дип, газетабызга талантлы шагыйрьнең бөек Тукай вафатына багышлап язылган хатирәсен матбугат битләрендә чыгарырга булдык. Рухлары рәнҗемәсен. Сәгыйть остаз мирасы һәм исеме арабызга әйләнеп кайта күрсен.

Сәгыйть РӘМИЕВ

2 АПРЕЛЬ

● Габдулла Тукай.

● Сәгыйть Рәмиев.

1913 нче елның 2 нче апрель көне – безнең татар галәмендә хисапсыз күп булып үтеп киткән һәм үтә килгән үкенечле көннәрнең берсе һәм үкенечлеге һәркемгә беленеп үткәнедер.

Ул көндә безнең Габдулла Тукаев дигән мәшһүр бер кешемез үлгән иде. Тукаевның вакытсыз үлеп китүе, әлбәттә, бик табигый булды, ягъни аның тиз үләчәге бик көтелә иде. Чөнки Тукаев кебек зәгыйфь бәдәнле, аз канлы, көчсез бер вөҗүднең (даим булмаса да) озак бер вөҗүд булып тора алмаячагы, тегермән ташы астындагы бер ярманың ярылмый кала алмаячагыннан да ачык иде. Ул үлде. Татарлар аны зур тантана белән кабергә күмделәр дә аннан соң кайгырыштылар.

Безнең халык шулай инде: ул, ярмасы булса, аны тегермән ташы астында издерә дә он итеп бетерә; бетергәч кайгыра. Әмма аны саклап, тагы сачып үстерү ягын һич уйламый.

Тукаев мәрхүм дә татар хәятенең шундый бер корбаны булды. Ул татар галәме өчен бүрткән бер ярма, зур бер гатыя (бүләк) иде. Аның вөҗүд булуы, үсүе, бер кеше татар җәмгагасының каравына карап, тәрбиясенә тапшырылган иде. Татар җәмагасы үзе дә аның әзер бер ярма, зур бер гатыя икәнен ачык белгән иде. Ләкин һәрвакыттагы мәнсез (мәгънәсез)легенчә: «Бер тарыдан ботка булмас», – дип, халкымыз шуны күрәләтә тегермән ташы астына издертеп харап итте.

Хәзер инде мәрхүмнең сагынып сөйләргә бер исеме генә калды.

Менә бүген, 1914 нче ел 2 апрельдә, шул мәрхүм Габдулла Тукаевның вафатына бер ел тулды. Ел тулу мөнәсәбәте белән, исемен искә алып, хакында берничә сүз сөйләмәк буламын.

Сөйләячәк сүзләрем, сөйли алачак сүзләремнең бик аз гынасы булса да, мәрхүмнең иң якын иптәше вә гаять самими, бәлки, бер калеб (күңел), бер җан дусты тарафыннан сөйләнәчәк һәм юк-бар хиссияткә бирелмичә, бары нәфсе әмердәге (күңел кушудагы) хакыйкатьне генә ифадә (аңлатып бирәчәк) итәчәк сүзләр булганлыгы өчен, мәрхүмне азмы-күпме якыннанрак күреп белергә теләгән укучыларга файдадаи хали (буш) сүзләр булмаслар дип уйлыймын.

Мәрхүмнең килеш-килбәте

Мәрхүмнең килеш-килбәтен әйтер алдыннан, шуңар мөкаддимә (кереш сүз) сымак итеп, берничә сүзне дә кыстырып үтим.

Мәрхүм 1907 нче елда Уральск шәһәреннән Казанга килгәнендә, салдатка каралыр өчен дип туган авылы ягына кайтышлый килгән иде. «Болгар» нумирларына төшкән икән. Мин дә ул вакыт Казанда «Болгар» нумирларында тора идем. Гаяз әфәнденең Казан төрмәсендә торган чагы (Исхакый 1907 елның 4 июнендә кулга алына), шул мөнәсәбәт белән безнең дә бик кайгылы көннәремез иде.

Числасы хәтеремдә юк, беркөнне Фуад Туктаров, Шакир Мөхәммәдъяров, Хөсәен Әбүзәрев һәм башка иптәшләремез, мөшавәрә (киңәш) итеп, Гаяз әфәнде хакында бертөрле хәрәкәттә булынырга карар кылган идек. Минем өлешемә дә бер вазифа төште.

Вазифам авыр вазифа түгел, шулай да вазифам булганлыгы өчен аңар зур кодсият (изгелек) биреп һәм әдасендә (үтәвендә) дә бик зур кодсият күреп, вазифамны әда юлында бер кешегә бардым. Ләкин зур хәкарәт (кимсетү) күреп кайттым. Кайттым да чәй алдырып нумирыма ябылдым. Такать (көч,куәт) итә алмаслык бер гарьлек, бер хәсрәт эчендә утырамын. Көн кич булган, урам дөм-караңгы, нумирда эликтрик яна иде. Бер-бер кешене түгел, үземне-үзем күрәсе килми утыра идем. Шул минутта нумир ишегемне ачып:

– Сәгыйть әфәнде Рәмиев шушында торамы? – дип, бер малай килеп керде.

Карадым: яланбаш, кара күзлектән, өстенә казакимы, җөббәме (җилән), иске генә бернәрсә кигән, аягында тузган кара буркалы шыксыз гына бер малай, минем «ие» дигән сүземне дә көтмичә, каршымда, өстәл кырыена, буш торган урындыкка килеп тә утырды. Имеш, «Уральскидан килгән, Камил әфәнде Мотыйгый сәлам әйткән!..»

Нигә кирәк миңа Уральские да, нигә кирәк миңа аның әллә нинди Камил Мотыйгыйларының сәламе!

Йөземне тәрәзә ягына таба чәвердем. Һичнәрсә күрү мөмкин булмаса да, урамга карап утырам. Бик озак шулай утырганнан соң, табигатемдә юк тәкәбберлек булмасын өчен генә, мөсафиргә таба яртылаш кына борылдым да, үземә генә чәй ясап (тегенәргә юк, ыстакан да соратмыйм), йөзенә күтәрелеп карамыйча гына:

– Сез анда бер шәкерт идеңезмени? – дидем.

– Шәкерт тә идем, хәлфә дә идем, – диде.

«Булырсың инде, хәлфә булырга кыяфәтең килгән!» – дигән кебек итеп, аның кулы янындарак торган шырпымны алдым да тагы дөм-караңгы урамга таба йөземне чәвердем. Тәмәке тартып утырам.

Аның миңа бер сүз дәшүе йә бер сөаль бирүе арасында унбишәр минут өзеп тора иде. Эчем пошып бетте, һаман утыра биргәненә ачуым килә.

Инде: «Әфәндем, минем вакытым юк, икенче вакыт керерсез, хәзергә чыгып китсәңез иде», – дияргә гасабларым (нервларым) калтырый башлаганда гына тәге:

гырьләр дә яза, шигырьләрен газетамызга без бик яратып дәреҗ итә (бастыра) идек.

Кинәт кенә үзенә таба әйләндем дә:

– Соң, Сез кем буласыз? – дидем.

– Габдулла Тукаев булам, – диде.

– Соң, кергәч тә шулай дип әйтсәңез ни була! Мин Сезне икенче төрлерәк каршы алган булыр идем! Әй, Тукаев, Тукаев! – дип, торып, үзе берлә яңадан күрештем һәм звонок биреп ыстакан да сорадым. Ләкин чәемез боз кебек булып беткән иде. Шулай да берәр ыстакан чәй эчтек тә, шул арада мин кәефсезлегемнең вөҗһесен (сәбәбен) сөйләдем. Ул да кәефсезлегемә иштирак итте (кушылды), аннан соң аның шигырьләре вә минем шигырьләрем һәм

● Урта рәттә утырганнар (сулдан уңга): Зәйни Солтанов, ГабдуллаТукай, Сәгыйть Рәмиев.

– Сәгыйть әфәнде, мин Сезгә «Царь-голод»ның (А.Бахның «Царь-голод» китабы) тәрҗемәсен йибәргән идем. Сез аны басмадыңыз да һәм идарәдән бер җавап та бирмәдеңез, – диде.

Бик исемдә, «Царь-голод»ның тәрҗемәсен безгә Габдулла Тукаев дигән кеше йибәргән иде. Һәм ул безгә шиозакламый булачак әдәбият кичәсе тугрысында бераз сөйләштек тә сыйлашыр вә кунак булышыр өчен икенче йиргә чыгып киттек. Бөтен эч серләремезне ачышып, төнге сәгать берләрдә, икеләрдә кайтып ятканмыздыр.

Иртәнгесен иртә белән ул тагы минем нумирыма керде. Күп сүзләр арасында

КӨНЕ

● Габдулла Тукай Клячкин хастаханәсендә вафатына 1 тәүлек кала.

муллалар тугрысында да сүзләр булып, мин аңар бер остазым Габдерәхим әфәнде Дәмини җәнапларыннан ишеттегем «Кафате хәмсә»не («къ» хәрефе белән башланган биш сүз) сөйләдем. Ягъни «Муллаларның сөйгәне казы, кузый, каз, кыз, кымыз гына инде; үзләре боларны бергә җыеп, «Кафате хәмсә» дип атыйлар икән», – дидем.

Бу сүзне Тукаев бик яратты да: «Тукта әле, мин моңардан бернәрсә эшлим», – дип, уз нумирына чыгып китте дә бер ун-унбиш минуттан соң кулына:

Әй, Ходай! мәгълүм сиңа, тик яхшылыкта касдымыз (ниятебез);

Зикеремездер (искә төшерү): казы, кузый, яшь кенә кыз, каз, кымыз,

дип язылган бер кәгазь күтәреп керде (Сүз Тукайның «Бер шәехнең мөнаҗәте» дигән шигыре турында).

«Шәп!» – дидем. Кулларымызны кысыштык-күрештек тә, шул сәгате белән үк ул җыенып, салдатка каралыр өчен дип, авылына кайтып китте.

Бер ун-унбиш көннән тагы әйләнеп Казанга килде. Бу дәфга (кат) килгән көннәре Гаяз әфәнденең Казан төрмәсеннән сөргенгә озатылган көннәре иде *(Исхакый 1907 елның октябрендә өч елга Архангел губернасына җибәрелә)*.

– Гаяз әфәндене күрә алмам микәнни инде? – диде.

– Булмас шул инде, – дидем.

– Казанга килүемнән бер максатым сезләрне күрү өчен генә иде. Әле авылда үткәргән минутларымны да мең бәла белән генә үткәреп, тизрәк сезнең яныңызга килергә ашыктым. Инде, Сәгыйть әфәнде, бергә-бергә торсак иде, – диде. Һәм шунда Казанга килүеннән беренче истифадәсе (файда) – татар сүзләренең гыйльме гарузда мәзкүр вәзеннәрдән (шигырь төзелешендәге үлчәмнәр) башка вәзеннәргә дә сыя икәнене һәм татар шигырьләре башка бәхерләрдщ (шигырь үлчәме) дә языла ала икәнене белгәнен сөйләде. Һәм русча итеп: «Мин бу көнгәчә паезия илә маральне аермый йөргәнмен икән», – диде. Вә аның шул хакта язган бер шигыре дә бар иде. Басылган мәҗмугаларында шул шигыре минем күземә чалынмады.

Әле мин мәрхүмнең килеш-килбәтен сөйләмәкче идем. Мөкаддимәм озаккарак сузылды.

Мәрхүмнең килеш-килбәте кеше кызыгырлык түгел иде. Ул һәрвакыт йә азрак таррак, йә бик киң киемдә йөри иде. Башына кигәне йә кепка (нимес фуражкасы), йә бик киң рус фуражкасы була иде.

<…>

Мәрхүмнең төсе

Мәрхүмнең төсе коңгырт иде. Бәдәне зәгыйфь кенә булса да, әгъзалары бер-берсе илә бик мөтәнасиб (туры килү), бер күзенә ак төшкән булса да, йөзенең килешләре белән ямьсез түгел, бәлки уртача матур, биек маңгайлы; борыны килешле вә һәрдаим тулы булып ачылып торган зур күзле иде.

Казанга килгән чакларында 21–22, вафаты елында 27 яшьлек кеше булса да, һаман 14–15 яшьлек бер бала кебек кенә күренә иде.

Бу көнгәчә сатылып йөри торган аткрыткалардагы рәсеме бер дә Тукаевның үзе түгел.

Мәрхүмнең әхлакы

Мәрхүм үзе, болыт (губка) кебек, әйләнәмездә булган һәммә тәзаһерәт (күренеш), хәрәкәт (явление)ләрдән бик мөтәәссир була (тәэсирләнә), аларны бик тиз үзенә сеңдереп ала торган бер зат иде. Әхлакы үзенә махсус иде: күрепме яисә гаибанәме (күрмичәме), үзе сөеп, үзе күрәсе килеп күрмәгән кешеләр белән күрешкәндә һәм алар белән утырдаш булганда, аларга һәрвакыт ышанычсыз күз белән (недоверие белән) карый иде.

Танымаган яисә танып та яратмаган кешеләренә каты бәрелүдән, хәтерләрен калдырудан бер дә тартынмый иде.

Ят кешеләр мәҗлесендә бер сүз дә сөйләми; сөйләсә, сөйләячәк мәүзугының (темасының) тыңлаучылар каршында әһәмияте бармы-юкмы икәнчелегенә һич игътибар итми, бик кечкенә мәсьәләләрне дә зур итеп, аны үзенә махсус бер җитдият белән сөйли торган иде. Мәсьәләнең хакыйкатькә яхуд берәр фәнгә хилаф түгелмелегендә һич эше юк иде. Үзенең ышанган бер кешесеннән ишеткән йә укыган сүзне рәһбәр (юл күрсәтүче) итеп алып, башка хакыйкатьләрне шуңар гына салып үлчи иде.

Үзенең яраткан кешеләренең даирәсендә йөргәндә, аңар каршы даирәгә бу да каршы була. Тарафдарларын һәммә гаепләрдән арындырырга тырыша, аларга каршы тарафлардан, әлбәттә, бер шигырь язып көләргә ярата иде.

Мәрхүм үзеннән көлгәнне, үзен тәнкыйть иткәнне бер дә сөйми, хәтта ачу тота иде.

Мәрхүмнең фикере

Мәрхүм Тукаевның эчендә үзенә башка һәм кеше бар иде, үз эчендә мәрхүмнең үзе генә юк иде. Әле ул үзенә махсус төпле бер фикер утырта алмый йөдәп йөри иде. Сәбәбе төпле фән вә төпле мәгърифәт тәхсиленнән (гыйлем алудан) мәхрүм калдыгы иде.

Мәрхүмнең үзенә мөстәкыйль булып сөйләгән фикерләреннән ике генә фикере хәтеремдә калган: берсе – ул рус шагыйрьләреннән Надсонны яратмый иде: «Егълак, көчләнеп шагыйрь булырга тырышкан кеше», – ди иде һәм үземезнең шагыйрьләремездән дә берәүне шуңар охшатып яратмый иде.

Икенче – рус мөхәррирләреннән Гогольнең комедияләренә аның бер дә исе китми иде.

Гоголь үзе тотып берәүнең битен карага буйый да аннан соң үзе шуңардан көлә, – ди торган иде.

Мәрхүм хакында халкымызның карашлары

Мәрхүмнең иткән хезмәтләре хакында халкымызның карашлары мең төрлечә булырга мөмкин. Аның хезмәтенә китапчыларның карашы бар, мөгаллимнәрнең карашы бар һәм боларга башка янә үзендә бер аерым җан, аерым хәят бар кешеләрнең карашы бар.

Китапчылар, мөгаллимнәр Тукаевның иткән хезмәтеннән бик канигъ (канәгать) була алырлар. Чөнки китапчыларга Тукаевның шигырьләре бик үтемле мал булды. Китапчыларның иң беренчеләренең мыеклары шикелле, иң соңгыларының да мыеклары майланып калды. Шуның өчен аларга артыгы кирәкмәс тә. Шулай ук мөгаллимнәрнең дә бик күбесенә Тукаев шигырьләре шәкертләргә бирер өчен, аларны авызларына каратып тотар өчен бик зур маддә булды. Шуның өчен аларга да артыгы кирәкмидер, әмма үзләрендә аерым бер җан, аерым бер хәят бар кешеләрнең канәгатьләре ач күзлек итсә, итәр шул. Бер дә гаҗәп тә түгел. Бер дә гөнаһ та түгел. Зур корабка йөрергә дә зур диңгез кирәк.

Хәзерге көндә матбугатымызда бәгъзы әфәнделәрнең Тукаев хакында мөнәкъкыйдләр (тәнкыйтьче) үзәренә һөҗүмнәре һәм «Ялт-йолт» журналында күренгән бер-беремезне тәмсез тешләшүләр шул югарыда мәзкүр карашлардагы аерманың нәтиҗәседер. Ләкин әфкярда (фикердә), нәзарда (караш) истикъляль (бәйсезлек) намына һәм шуның бер кәсе (кешесе) уларак әдәбиятымызның иркенләп үсүе шәрәфенә андый тәмсез тешләшүләрнең кирәк түгеллеге беленсен иде!

Мәрхүм хакында үз карашым

Мәрхүм Габдулла Тукаев русларның Пушкиннары, Лермонтовлары дәрәҗәсендә чын һәм татар галиме өчен муҗид (иҗат итүче) бер шагыйрь булырга туган иде. Ләкин без татарларда мәгарифнең һәм төпле фикер вә гакылның юклыгыннан, ул мәрхүм, йөрәк ярып күкрәп, кот очырып яшенләп тә, яңгыры яумый үткән болыт кебек, бары талантын вә мәүһибәи илаһияләрен (Аллаһы бүләкләрен) генә ялтыратты да, муҗид шагыйрь була алмый үлде.

Ул иске «Кисекбаш», «Бакырган» вә «Йосыф» китапларын гына яңа төрләләттереп, аларга соңгы мода сүзләрдән төзелгән кушымталар гына калдырып китте.

Әрәм булды. Татар галәме үзенең кулына сузылган зур бер бәхетне күрәләтә очырды. Моннан соң инде Аллаһы безне кашыксыз ятып төшендә кесәл күргән чуаш кебек итмәсен иде!

1914 ел, 2 апрель.

Айга карама

Халык медицинасы чаралары белән дәвалануга керешкәнче, табиб белән киңәшү зарур!

29 июль (шимбә). ***Мөхәррәм аеның 11нче көне. 13 нче Ай тәүлеге. Ай Укчы йолдызлыгында, 19.00 сәгатьтә калка, 0.25 сәгатьтә бата. 2нче фаза. Көн озынлыгы 16.16 сәгать.***

Үзгәрешләр көне. Үткәннәр турында уйланып, нәтиҗәләр ясау яхшы. Ач торырга ярамый – теләсә нәрсә ашарга була. Аралашу, белем алу өчен уңай вакыт. Йөрәк, тире, кан тамырлары зәгыйфь. Чикләвек ашау файдалы.

Чикләвекле бал

Йөрәк мускулын ныгыту өчен, 1 стакан чистартылган эрбет чикләвеге (яки көнбагыш орлыгы), 1 әр аш кашыгы мәк һәм балны кушып, яхшылап болгаталар, йоклар алдыннан 1 аш кашыгы ашыйлар (бик әйбәтләп, катнашма сөтсыманга әйләнгәнче чәйнәргә кирәк). Эрбет чикләвеге йөрәккә файдалы биологик актив матдәләргә бай, кан тамырларының сыгылмалылыгын саклый. Мәк тынычландыра, йөрәк ритмын нормага китерә. Балдагы углевод һәм микроэлементлар йөрәк мускулын ныгыта.

30 июль (якшәмбе). ***Мөхәррәм аеның 12нче көне. 14нче Ай тәүлеге. Ай Кәҗәмөгез йолдызлыгында, 20.06 сәгатьтә калка, 1.30 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 16.13 сәгать.***

Иң әһәмиятле эшкә тотыну өчен уңайлы көн. Бүген башланган эш бик яхшы тәмамланачак. Теләсә нинди вак-төяккә игътибарлы булу сорала. Эчәклек һәм тирене чистарту уңай нәтиҗә бирә. Ашказаны асты бизе зәгыйфь. Балан, фасоль, борчак, арпа ашау файдалы.

Миләш дәвалый

Баш авыртканда, йокысызлык интектергәндә көн буена 10 миләш җиләге ашыйлар. Салкын тигәндә, грипп вакытында 2 аш кашыгы кипкән миләш, 1 әр аш кашыгы кипкән кара карлыган җиләген һәм яфрагын кичтән термостагы кайнар суга салып калдыралар, икенче көнне чәй урынына эчәләр. Мондый чәй бөерләрне дә дәвалый. Гипертониядән, атеросклероздан дәвалану өчен, 1 әр аш кашыгы кипкән миләш һәм гөлҗимешне 2 стакан кайнар суда 5 минут пешерәләр, сөлгегә урап, җылы урында 12 сәгать төнәтәләр, сөзәләр, көненә 3-4 тапкыр, ашаганчы, яртышар стакан эчәләр.

31 июль (дүшәмбе). ***Мөхәррәм аеның 13нче көне. 15нче Ай тәүлеге. Ай Кәҗәмөгез йолдызлыгында, 20.38 сәгатьтә калка, 2.57 сәгатьтә бата. 2нче фаза. Көн озынлыгы 16.09 сәгать.***

Авыр энергетикалы көн. Бүген кеше үз нәфесенең теләк һәм коткыларына бигрәк тә бирешүчән. Тәэсирләнүчән кешегә аеруча кыен. Балан, мүк җиләге ашау файдалы.

Шикәрне киметү (Ванга рецепты)

Шикәр чиреннән интеккәндә, 300 әр г петрушка тамыры һәм сарымсак, төшләре алынган 1 кг лимонны иттарткычтан чыгаралар, караңгы урында 2 атна төнәтәләр, аннары көн саен ашар алдыннан 1әр чәй кашыгы кабалар.

(Дәвамы 18 нче биттә).

Айга кырын карама

1 август (сишәмбе). ***Мөхәррәм аеның 14 нче көне. 16 нчы Ай тәүлеге. Ай Сукояр йолдызлыгында, 21.15 сәгатьтә калка. 21 сәгать 32 минуттан тулы Ай. Көн озынлыгы 16.05 сәгать.***

Тыныч, иҗади, уңышлы көн. Һәрнәрсәдә гармониягә омтылу, җан тынычлыгын саклау мөһим. Дулкынландыргыч очрашулар булырга мөмкин. Килешүләр төзү уңай нәтиҗә бирә. Беркемгә дә үпкә сакларга ярамый.

Солы кесәле

Гастритны кисәтү һәм дәвалау өчен, 1 аш кашыгы солыны яхшылап юалар, өстенә 1 стакан кайнар су салып, төнгелеккә калдыралар. Иртән 1чәй кашыгы бал кушып ашыйлар. Кесәлне тагын да файдалырак итеп була. Ярты стакан солы, 1 аш кашыгы йөзем яки 2-3 курагәне термоска салып, өстенә 1 литр кайнар су агызалар, 1 канәфер кадагы өстиләр. Иртән кесәлен эчәләр, җимешләрен ашыйлар. Мондый кесәл иммунитетны да ныгыта.

2 август (чәршәмбе). ***Мөхәррәм аеның 15 нче көне. 17 нче Ай тәүлеге. Ай Сукояр йолдызлыгында, 21.42 сәгатьтә калка, 6.15 сәгатьтә бата. 3 нче фаза. Көн озынлыгы 16.01 сәгать.***

Мәхәббәт, иҗат, яшәү шатлыгы көне. Бернәрсә дә планлаштырмыйча, теләгән нәрсәне генә эшләү яхшы. Нерв һәм эндокрин системаларга, күзгә игътибарлырак булу сорала. Яшелчәләрне күбрәк ашау файдалы.

Тайтояк айныта

Эчкечелеккә сабышкан кешеләрне аракыдан биздерү өчен, порошок итеп төелгән тайтояк (копытень) тамырын пычак очына элеп эчкеченең ризыгына сибәләр. 3 тапкыр ашый икән – 3 тапкыр сибәләр. Әмма дозаны арттырырга ярамый, үсемлек агулы! Янсә 3 аш кашыгы вакланган тамырны 1 стакан суда 10 минут пешерәләр, көн дәвамында 2-4 әр аш кашыгын эчкеченең ашына һәм чәенә кушып бирәләр. 3 ай буе көн саен эчәргә кирәк.

3 август (пәнҗешәмбе). ***Мөхәррәм аеның 16 нчы көне. 18 нче Ай тәүлеге. Ай Балыклар йолдызлыгында, 21.52 сәгатьтә калка, 7.51 сәгатьтә бата. 3 нче фаза. Көн озынлыгы 15.57 сәгать.***

Алдашу, ялганга бай көн. Бизләр системасы, бил, бөер, тире, сукыр эчәк зәгыйфь. Мунчага бару, массаж ясату, ач тору, төрле дәвалану чараларын куллану файдалы. Кәеф төшәргә мөмкин.

4 август (җомга). Мөхәррәм аеның 17 нче көне. 19 нчы Ай тәүлеге. Ай Балыклар йолдызлыгында, 21.52 сәгатьтә калка, 7.51 сәгатьтә бата. 3 нче фаза. Көн озынлыгы 15.53 сәгать.

Авыр энергетикалы көн. Күп аралашмаска, күз тиюдән, чит тәэсирләрдән сакланырга кирәк. Бурычка алырга да, бирергә дә ярамый. Нерв системасы, эчәклек, арканың өске өлеше зәгыйфь.

Кыяр маринадлау

Стерильләштерелгән банкаларга орлыкланган укроп башы, сарымсак салалар, юылган кыярларны тутыралар да, шаулап торган кайнар су коялар. 15 минуттан соң ул суны түгәләр, кыяр янына хуш исле борыч, канәфер һәм башка тәмләткечләр салалар да, 4 литр суга 1 стакан шикәр, ярты стакан тоз, 1 стакан 9 процентлы серкә исәбеннән ясалган кайнар тозлык агызалар, тимер капкач белән ябып, банкаларның астын өскә әйләндереп куялар.

Эльзаның хыялый дөньясы...

Ягымлы-йомшак һәм искиткеч булдыклы – ул шушы ике сыйфатны үзендә берләштерә алган. Сүзем Казандагы беренче Күбәләкләр паркын оештырган Эльза Гегель кызы Миргаязова турында. Туксанынчы елларда туган, ирек һавасын сулап үскән «суверенитет балалары»ның берсе. Эльза Мөслимнән, гап-гади гаиләдә үсә, мәктәптә бик яхшы укый, күп фәннәр буенча олимпиадаларга йөри. Республика олимпиадаларында гына да 17 тапкыр җиңү яулый ул! Мәктәпне алтын медальгә тәмамлап, КФУга керә, филфакта инглиз һәм алман телләрен өйрәнә, Алман илендә стажировка үтеп кайта.

Укытучылары да, әти-әниләре дә сәләтле кыз фән юлын сайлар, галимә булыр, дип көтә. Тик Эльза тота да 3 курста укыганда ук кияүгә чыга. Азат белән алар Татар конгрессы үткәргән чарада – «Мин татарча сөйләшәм!» акциясендә таныша. Берсе – оештыручы, берсе – волонтер. Икесе дә милли җанлы, укымышлы. Озак уйлап йөрмичә, өйләнешеп тә куялар. Туй акчасын нишләтергә,

дип уйлый торгач, бер карарга киләләр. Юк, чит илгә ялга да китмиләр, берни сатып та алмыйлар, ә Казандагы иң беренче хосусый татар балалар бакчасын ачып җибәрергә була алар. Шулай итеп, шәһәребездә яшь гаилә белән бергә 2017 елда «Ябалак» дип аталган татар бакчасы да барлыкка килә. Башта бакча офис бинасында ачыла, аннары шәһәр читеннән коттедж алып, шунда күчәләр. Дүрт ел буена бу бакчаны күтәрүгә күпме көч, йөрәк җылысы салынганын Эльза үзе генә белә. Нәтиҗәсе дә күренә: тәркемнәр туп-тулы, тәрбиячеләр командасы яхшы, әти-әниләр канәгать. Тик Эльзаның холкы шундый – нәрсәнедер үзе өчен ачып, өйрәнеп, төбенә төшкәннән соң ул яңа киңлекләр эзли башлый. Дүрт ел буе күтәргән бакчаны үзе кебек үк милли җанлы, тәҗрибәле кешегә сата да, алга таба атлый. «Ябалак» үзенең концепциясен үзгәртми, ул бүген дә саф татар бакчасы. Ул гына да түгел, эшен киңәйтеп, филиалларын да ачарга җыеналар.

Ярты еллап сулу алганнан соң, Эльза ире белән Дубайга бара. Анда зур Күбәләкләр бакчасында булып, исе-акылы китә аның. Тыныч музыка, искиткеч матурлык, шат балалар… Җәннәт почмагы кебек тоела аңа. Шул тәэсирләрне күңеленә салып, Казанга кайта. Ә нигә безнең шәһәрдә дә мондый матурлык булмаска тиеш әле, дигән фикер тынгы бирми. Чит илләрдәге шундый паркларның эшен өйрәнә башлый. Беренче партия курчакларны Филиппин утрауларыннан заказ биреп кайтарта да, башта өйдә үстереп карыйлар. Аннары бина эзләү, ремонтлау… Бер ел элек шәһәребезнең нәкъ үзәгендә ачылып эшли дә башлый Күбәләк паркы. Монда тропикларда яшәүче искиткеч матур күбәләкләрне якыннан карарга, фотога төшәргә, хәтта өйгә күбәләк фермасы да сатып алырга була. Ул гына да түгел, күбәләк курчагы чәчәк бәйләме дә әзерләп бирәләр. Әлбәттә инде, нәзберек җан ияләрен ничек карарга икәнен тәфсилләп аңлатып, кулыңа инструкциясен дә тоттырып җибәрәләр.

«Безгә барысы да уңай килеп торды, чөнки бу Казаныбыз өчен яңалык иде», – ди Эльза. Кешеләр бу паркка эмоцияләр, яңа кичерешләр эзләп килә. Бу җәйне исә парк тагын да зуррак бинага күчте, эшчәнлеге дә киңәйгән. Күбәләкләрне күрсәтергә мәктәпләргә, төрле бәйрәмнәргә дә

алып баралар. Россиядә мондый парклар өч шәһәрдә генә бар: Мәскәү, Петербург һәм Казанда. Чагыштырып караучылар Казаннныкы иң яхшысы, диләр икән, димәк, йокысыз төннәр һәм хыялны чын итү юлындагы тырышлык әрәм китмәгән.

Күз явын алырлык күбәләкләр Казанга Филиппиннан янсә Коста-Рикадан курчак хәлендә кайта. Анда аларны теплица кебек җирләрдә үрчетәләр. Санкцияләр аркасында күбәләкләрнең дә юллары озайган – Казахстан аша кайта башлаганнар. Нәтиҗәдә кайбер күбәләкләр юлда ук туып өлгерә икән.

«Күбәләкләр паркы – күңел эше генә түгелме, керем дә китерәме?» – дигән соравыма каршы Эльза бер тарих сөйләде. Элекке заманда бер кешенең, хәзерге тел белән әйтсәк, бизнес ачып җибәрәсе килгән. Өч-дүрт фикердәш табып, эш башлап җибәргәннәр. Эшләре әйбәт баргач, тагын берничә кешене алганнар. Шулай итеп болар тугыз кеше җыелган. Сатулары да, керемнәре дә яхшы гына бара. Тик хуҗа унынчы кеше дә алырга тели. Эзлиләр-эзлиләр, тик туры килгән кешене һаман тапмыйлар. Ниһаять, беркөнне әйтә хуҗа: мин унынчы кулдашыбызны таптым, ди. «Кем ул?» – диешәләр сабырсызланып. «Унынчыбыз Аллаһ Тәгалә булачак, – дип җавап бирә ул. – Безнең эшләребезнең уңышлы баруында Аллаһның да өлеше бар, керемне дә унга бүләчәкбез», – ди һәм унынчы өлешне Аллаһ юлында тота башлыйлар.

«Без дә Аллаһ хакына малны кызганмыйбыз. Эшебезнең уңай баруы, күтелмәгәндә киракле кеше белән очрашулар – болар Аллаһтан бит», – ди Эльза. Парк өчен яңа бинаны озак эзли ул. Йә мәйданы, йә урыны, йә бәясе туры килми. Ниһаять, ул эзләгән бина табыла – бар яклап панорамалы тәрәзәләр белән! Бу бит хыял! Эльза хисләнеп тәрәзәдән карый һәм шакката: аста мәчет төзелеп ята… Бу бит Аллаһның нигъмәте дип кабул итеп, төзелешкә дә хәленнән килгәнчә өлешен кертә башлый. Хәйриячелек – Эльзаның эшендәге аерылмас бер өлеш, мәчетләргә, балалар йортларына, хосписка һәрвакыт ярдәм итеп тора. Эшмәкәр ханым Җәлил исемле биш яшьлек «егет»нең әнисе дә әле. Декрет ялының ни икәнен дә белмичә,

бала табу йортында ук эшлекле язышулар белән мәсьәләләрне хәл итеп ятса да, улына тиешле җылылыкны да, мөстәкыйльлекне дә бирергә тырыша ул. Сизәм, күбәләкләр паркы – аның башындагы идеяләрнең соңгысы түгел. «Хәзер – мөмкинлекләр заманы. Илле ел бер урында эшләргә димәгән. Иң мөһиме, эшең хәләл булсын, башкаларга зыян салмасын, ә файда китерсен», – ди Эльза, якты елмаеп. Ә һәр эшне башлау, хыялны чынга ашыру юлындагы кыенлыклар аны куркытмый, чөнки ул: «Сине үтермәгән һәр нәрсә сине көчле итә», – дип яшәүчеләрдән.

Эльмира СИРАҖИ.

Ул халык җырчысы иде

Радиодан, телевидениедән халык җырчысы Рәшит Сөләйманов башкаруында җыр яңгырый башласа, ничектер күңелгә рәхәт булып китә. Аның тавышын беркем белән дә бутап булмый. Ул затлы, ниндидер тылсым иясенә охшаган.

Рәшит Чистай районының Иске Роман авылында туа. Колхозда аш пешерүче Маһирә апа белән тракторчылар бригадиры Шакирҗан абзый гаиләсендә биш кыз – Мәрвия, Фәүзия, Нажия, Нәкыя һәм Роза арасында бер малай булып үсә ул. «Әнием бик матур җырлый, Сабантуйларда һәрчак беренче урынны ала иде. Әтием оста гармунчы иде. Дин юлында булганлыктан, яшереп кенә уйнады», – дип сөйли иде Рәшит Сөләйманов.

Әтисе мөнәҗәтләр әйтергә яраткан. Мөгаен, Рәшитнең сәхнәгә омтылуы да сәнгатькә гашыйк әти-әнисеннән башлангандыр. Кечкенә вакытта малай бик оялчан була, әтисеннән отып калган мөнәҗәтләрне качып кына җырлый.

Сугышта аягын имгәтеп кайткан Дан орденнары кавалеры әтисен чанага яисә арбага утыртып, авылның икенче башына мич чыгарырга алып барган мизгелләрне дә сагынып искә ала иде ул. Әтиләре сугыш яраларыннан вафат булгач, 1969 елда 8 нче сыйныфны тәмамлаган Рәшитне Уфада яшәүче Фәүзия апасы белән Әдһәм җизнәсе Мәүлиевлар үз яннарына алдыра. Үсмер егет, укуын кичке мәктәптә дәвам итеп, Уфа шәһәрендәге заводларның берсенә токарь ярдәмчесе булып эшкә урнаша. «Кызыл таң» газетасында эшләүче җизнәсе, каенише күңелендә яткан моңны тоеп, аны баян буенча түләүле кичке түгәрәккә йөртә башлый. Ул өч ел рәттән Уфа сәнгать училищесына укырга кереп карый, әмма уңышсыз була. Үҗәтләнеп дүртенче мәртәбә бара һәм теләгенә ирешә.

Аны заводта токарь булып эшләгәндә үк Уфа опера һәм балет театрының хорына алалар. Опера – аның өчен үзе бер мәктәп. Училищеда укыганда ук «Салават Юлаев», «Князь Игорь», «Борис Годунов» кебек опералларда, күп кенә комедияләрдә уйный-җырлый. Озын буйлы булганга аңа Дон Кихот ролен уйнарга да тәкъдим итәләр.

Сәнгать училищесын тәмамлаганнан соң да белемен тирәнәйтәсе килә аның. Казан консерваториясенә имтихан биреп карый, алай-болай үтсәм, филармониядә булса да эшләрмен дип өметләнә. Ләкин үтми. Җыр һәм бию ансамблендә эшләп ала. Ниһаять, 1982 елда консерваториянең вокал бүлегенә укырга керә, профессор В.А.Вороновта белем ала.

Консерватория тәмамлагач, язмыш аны янә Уфа якларына озата. Ул «Энергетик» мәдәният сараенда вокаль ансамбль җитәкчесе булып эшли. Балаларны җырларга өйрәтә. Концертлар куеп йөри. Тик күңеле барыбер Казанга тартыла. Рәшитне Лима ханым Кустабаева җыр һәм бию ансамленә солист итеп чакыра. Ул анда «Кошлар кебек», «Рәйхан», «Болын», «Тәфтиләү», «Туган тел», «Кара урман», «Сарман», «Зөбәрҗәт» кебек халык җырларын җырлый.

Артист халкының гомере юлда үтә. Рәшит тә дөньяның кайсы гына кыйтгаларында булмаган да татар моңын кайларга гына таратмаган! Ә дистәләгән җырлары «Татарстан» радиосы һәм телевидениесенең алтын фондында саклана. Тик бер сорау туа, ни өчен халыкның яраткан җырчысы Рәшит Сөләймановның бер мактаулы исеме дә юк икән? Ул моңа үзе исән чакта ук бик лаек иде бит.

Язучы Госман Гомәр «Даһилар мөнбәре» дигән китабында Рәшит Сөләйманов турында менә ниләр яза: «Олы гәүдәле, әмма табигате белән сабый җанлы Рәшит Сөләйманов озак еллар дәвамында Татарстан җыр һәм бию ансамблендә хезмәт куйды. Казанда фатиры булмау сәбәпле, Чаллыдагы гаиләсен алып килә алмады, үзе тулай торакта ялгыз яшәде. Ниһаять, аңа фатир бирделәр. Гаиләсе белән чөкердәшеп яши башлады. Җыр сәнгатендә яңа баскычка күтәрелде. Мәшһүр җырчыбыз Усман Әлмиевнең иҗат кичәсендә ул моны тагын бер кат раслады. «Казан сөлгесе» җырын башкарып, тамашачыларны таң калдырды.

– Күрдеңме, иң каты кул чабучы мин идем, – дим, җырчы сәхнәдән төшкәч.

– Шайтан чакырган икәнсең алайса, – ди. Диндар кешенең сүзе бу.

Рәшит – биш намаз әһеле. Рамазан аенда тәрәвих мөнәҗәтен имам-хатыйп Фәрит хәзрәт Кадыйри белән бергә көйли. Җырчы таланты анысына да юл ачты.

Мин Рәшитне бу яктан күпләргә үрнәк итеп куям. Иманлы инсан!..»

– Язмыш мине һәр өлкәдә сынады. Тормыш кыенлыклары алдында калган чаклар аз булмады. Иҗат юлымда аркылы төшүчеләр күп булды. Дин юлында гына күңелемә тынычлык таптым. Ходай Тәгалә ярдәме белән, тормышта үзем күзаллаган максатларга соңлап булса ла ирешә барам, шөкер, – дип әйтә иде Рәшит Сөләйманов сабыр гына. Аның моңлы, аһәңле тавышы белән яздырылган азан Согуд Гарәбстанына барып ирешә. Нәтиҗәдә 1999 елда аңа хаҗ кылып кайту бәхете насыйп була.

– Кагъбулла янында әти-әнием, туганнарым, авылдашларыма гына түгел, Салих Сәйдәшев, Нәҗиб ага Җиһанов, Сара апа Садыйкова һәм башкалар рухына да дога кылдым, – ди иде ул шөкер итеп.

Рәшитне җырларга Мәскәүгә дә чакыралар. Аны шунда Төркиягә барырга да күндергәннәр. Үзе иҗат иткән җырлар дискы да тиз арада таралып беткән. Рәшит Сөләйманов белән минем үземә дә концертларда катнашырга туры килде. Ул ап-ак костюмын киеп чыгып басуга сәхнә яктырып, нурланып китә. Халык аны алкышларга күмә, рәхмәтләрен әйтә иде. Ул Татарстан җыр һәм бию ансамблендә бик яратып эшләде, һаман да егетләр кебек, шат күңелле, шаян иде. Вакыты булуга хәләл җефете Фирүзә ханым белән балалары, оныклары янына ашыкты.

Хәзер дә «Тәртип» радиосыннан халык җырчысы, милләтебезнең талантлы, затлы улы Рәшит Сөләймановның җырлаганын яратып тыңлыйм. Моңлы сандугачыбызның иҗаты, суга төшеп югалган күк юкка чыкмасын иде шул.

Зөлфәт ХӘЙРУЛЛИН.

Мамадышта тәэсирләнү

Казаннан чыгып ике сәгатьләп баргач Мамадышка юл тотсан, җитештерү бакчасы «Вятка» промышленность паркына юлыгасың. Әле ике-өч ел элек кенә район башлыгы Анатолий Иванов үзенең планнары белән таныштырган иде. Бәрәкалла, әлеге четерекле, әмма игелекле ыргылыш тормышка ашып ята. Әлеге җитештерү паркының мәйданы 80 гектар булып, инде дистәләгән объект төзелгән. Биләмәләр белән танышып чыктык. Югары технологияләр эшләү нәтиҗәсендә «Мамадыш пыяла җитештерү» компаниясенең җитәкчесе Альберт Нигъмәтуллинның сүзләренә караганда, биредә җитештерелгән пыялалар гадиенә караганда 9 мәртәбә ныграк икән. Промпаркның эчендә дә яхшы асфальт юл, уңай логистика, электр, су, газ – барысы да кертелгән. Чистарту корылмалары бар куәтенә эшли. Әлеге җирлектә шулай ук утыргычлар, йөк машиналары өчен көзгеләр дә җитештерелә. Якутиянең экс-мэры Александр Иванов агач, он, төзелеш материаллары ясауны да үз өстенә алган. Гарәп Әмирлекләреннән килгән Диб Хәлил бүген-иртәгә гранит ташлар эшкәртү цехын җанландырып җибәрәчәк. Кирәкле материал белән ихтыяҗны Һиндстан тәэмин итә, ә Төркия инвесторы 5 гектар мәйданда томатлар җитештерәчәк. Санкт-Петербург резиденты чүп-чар өчен полиэтилен капчыклар чыгарачак. «Биредә бер генә таләп бар: экологиягә зыян салмасыннар. Тагын 2-3 елдан җитештерү бакчасы тулысынча эшли башлаячак, әгәр дә банклардан 5% лы ипотекалар алуга комачаулыклар тудырылмаса!» – ди район җитәкчесе Анатолий Петр улы. Резидентларга таләпләре нык. А.Иванов берничә бизнес-идеяны да тормышка ашырырга тәкъдим керткән. Аның беренчесе – сөт заводыннан калган калдыклардан протеин җитештерү, чөнки сыр заводында көнгә 500 тонна сөт эшкәртелә, шуннан аертылган ризык суын эшкә җибәрәчәкләр. Әлеге товарны чит илләргә импортлау да каралган, үзебезнең илдә дә ихтыяҗ зур. Чыгымнар 800 миллион сумга җитсә дә, алар бер ел эчендә капланачак. Икенче идея – сугымнан җыелган авыл хуҗалыгы мал-туарының каныннан кош-кортлар өчен ашамлык хәстәрләү.

– «РМ-Агро» ит комбинатында көн дәвамында 5-6 тонна кан туплана, без аны файдага кулланачакбыз! Әлеге андый азыкны чит илләрдән алдыртабыз. Шулай ук безнең биләмәләрдә 15 фермерлык хуҗалыгы җиләк-җимеш җитештерә. Аны саклауны, эшкәртүне оештырырлык инвестор кирәк. Әлеге җитештерү аланы «Нократ» 30% ка гына кулланыла. Мөмкинлекләр җитәрлек, рәхим генә итсеннәр. Ләкин баштан ук кисәтеп куябыз: Мамадыш экологик чиста район санала, табигатькә зыянлы җитештерүчеләргә мөмкинлек булмаячак, – дип искәртә район башлыгы.

Нократ төшеп Чулман белән кушылган җирлектә елга порты төзер өчен уңай урын да сайлаганнар, әзер товарны Россия буенча һәм чит илләргә таратыр өчен дә мөмкинлекләр артачак.

Мамадыш – тормыш итү өчен иң уңайлы урыннарның берсе. Район үзәге күп тапкырлар Татарстан буенча, ике тапкыр Рәсәй киңлекләрендә дә «Иң уңай шартлар тудырылган шәһәр» дигән конкурсларда җиңеп чыккан. Бигрәк тә җәйге елларда, каникулларда Нократ елгасы ярларында рәхәтләнеп өч шәһәр күлендә коенып, спорт җайланмаларда шөгыльләнеп, ял итәргә мөмкин. Иң мөһиме, җирле халыкка эш бар. Әлеге җитештерү паркының ачылуы да хезмәт урыннарын арттырган, якын-тирәдәге Яр Чаллы, Алабуга, Түбән Кама, Менделеевск, Минзәлә кебек шәһәрләрдә хезмәт урыны табу кыенлышканда, Мамадышта җиң сызганып эшләргә нигез җитәрлек. Бүген паркта, башка җирлекләрдә хезмәт итәрлек һөнәрмәннәрне – 650 студент-шәкертне политехник колледж әзерли. Ел саен әлеге уку йортын 2500 ләп белгеч тәмамлый. Хезмәт хаклары да чагыштырмача әйбәт: 65 мең тирәсе. Районда эшкә яраклы 19 мең кеше булса, шуның 14 меңе туган җирендә хезмәт кыла, калганнары гаиләләре, пропискалары монда булган килеш, эш эзләп, читтә йөри. Әлеге 5 мең кешенең бер өлеше Себергә, Мәскәүгә, Питерга йөреп эшләсә, 1,5 меңе Казанга йөз тота, 6900 ләп кеше көн саен Алабугага чаба. Районда җитештерү арткан саен, кешеләр туган җирләренә кире кайта. Андый «мигрантлар» белән район җитәкчелеге аерым эш алып бара, аларга уңай вариантлар тәкъдим ителә. Әйтик, Рафис Әхмәтшинның вторсырьедан ярдәмчел материаллар җитештерә торган биләмәләренә эшкә урнашасың. Башка цехлардагы йөзләгән эш урыннары да һөнәрмәннәр көтә...

Рәдиф СӘГЪДИ,
Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе.

Икмәк кунакханәсе

Соңгы вакытта Швециядә өйдә пешерелгән ипи бик популяр, шунлыктан илдә хәтта “икмәк кунакханәләре” ачыла башлаган. Анда махсус номерларда ачыткы яки камырны калдырып була. Хуҗасы ялдан яки командировкадан кайтканчы, аларны дөрес шартларда саклыйлар. Баштарак “икмәк кунакханәләре” буш торган, хәзер исә клиентларга урын җиткереп булмый икән. Ачыткы махсус температура режимлы ячейкаларда саклана, аны органик он һәм чиста су белән яңартып, туглап торалар. Камырны яки ачыткыны бер атна буе кунакханәдә тоту 100-200 кронага төшә.

(“TravelAsk”).

Кара чәчәк тиз җиңелгән

СССР җитәкчелеге күргән тиңдәшсез чаралар нәтиҗәсендә генә 1959-1960 ел кышында Мәскәүдә кара чәчәк кизүе булдырылмый калган. Танылган рәссам, ике тапкыр Сталин премиясе лауреаты Алексей Кокорекин Һиндстанга сәяхәтеннән йоктырып кайта ул коточкыч куркыныч чирне – билгесез авырудан вафат булган брахманны Ганг елгасына агызып җибәрү мәрасименә бик затлы келәмгә төреп алып киләләр, рәссам индусларны шушы келәмне үзенә сатарга күндерә. Инде аэропортта ук Кокорекинның температурасы күтәрелә, югал интектерә башлый, тик ул моны һинд климаты тәэсиредер, дип кенә уйлый. Мәскәүдә келәмне сөйгәненә бүләк итә, үзенең хәле начарайганга, өенә кайтып китә. Иртән рәссамны хастаханәгә салалар, кичен ул вафат та була. Диагноз куяр өчен, патологоанатом академик Николай Краевскийны да чакыра, ул исә Ленинградтан кунакка килгән дустын да үзе белән ала. Нәкъ менә шул карт табиб моның кара чәчәк булуын ачыклый да инде – Советлар Берлегендә бөтен кешегә вакцинация ясау нәтиҗәсендә 1936 елда әлеге чир тулысынча җиңелгәнгә, яшь табибләр диагноз куя алмый, ул исә Гражданнар сугышы вакытында әлеге мәкерле чир белән очрашкан була. Бер тәүлектән соң Кокорекин яткан Боткин хастаханәсе хезмәткәрләре һәм пациентлары чирли башлый, инцидент турында илнең югары җитәкчелегенә хәбәр итәләр. Никита Хрущев тиз арада кичектергесез чаралар күрүне оештыра: рәссам белән бергә самолетта очучылар, таможня хезмәткәрләре, туганнары-дуслары, коллегалары – барысы да изоляцияләнә. Кокорекинның кызы Валерия белән аралашкан 150 студентны университетта лекциядә утырган җирләреннән алып китәләр. Рәссам алып кайткан келәм һәм башка бүләкләрнең комиссион кибетләргә куелуын белгәч, чекистларның чәче агара яза, әмма алар тиз арада бөтен сатып алучыны ачыклап, куркыныч бүләкләрне юк итә. Мәскәү карантинга ябыла, бер атна эчендә 10 меңгә якын кеше Боткин хастаханәсенә китерелә. Бәхеткә, илдә әзер вакцина була – Томск һәм Ташкент институтларыннан, Краснодар төбәк эпидемиология станциясеннән самолетлар белән 10 миллион доза кайтарыла. Мәскәүдә һәм Мәскәү өлкәсендә атна саен 1,5 миллион кешегә вакцина кадала. Тиз чара күрү нәтиҗәсендә, шәһәрдә барлыгы 46 кеше генә кара чәчәк йоктыра, шулардан өчесе үлә. Бер айдан эпидемия тулысынча җиңелә.

(“Мир новостей”).

Йөзгә кадәр яшәтә

Галимнәр әйтүенчә, зәйтүн мае куллану йөз яшькә кадәр яшәү мөмкинлеге бирә икән. Әлеге сихәтле ризыкның могҗизалы үзлекләре аңардагы бердәнбер ингредиентка – монотуендырылмаган май кислоталарына бәйле (аларга байлыгы белән тагын авокадо һәм чикләвек “мактана” ала). Май кислоталары, күзәнәкләрне картаюдан саклап, гомерне озайта. Күптән түгел галимнәр суалчаннар белән тәҗрибә үткәргән. Гадәттә бер-ике атна яшәгән суалчаннар, май кислоталары ашаткач, уртача ике көнгә озаграк яшәгән. Хәзер галимнәр монотуендырылмаган май кислоталарының гомерне ни рәвешле озайтуын аңларга маташа. Элгәрәк бу майларның диабет һәм йөрәк-кан тамырлары авыруларыннан саклавы дәлилләнгән иде. Күп күләмдә зәйтүн мае куллануга нигезләнгән Урта диңгез диетасы Европаның көньягындагыларга озак һәм актив яшәргә мөмкинлек бирә. Кан басымы югары булганнарга исә медиклар, зәйтүн мае белән бергә, калийга бай банан, шпинат һәм батат ашарга киңәш итә.

(“Лента.ру”).

Лотерея тарихыннан

Хәзер лотереяләрнең күпчелеге нинди дә булса бер шатлыклы вакыйга уңаеннан үткәрелә. Әмма Европадагы иң беренче лотерея сагышлы юбилейга багышланган була. Аны 1466 елның 24 февралендә Нидерланд рәссамы Ян ван Эйкның тол калган хатыны иренең вафатына 25 ел тулу уңаеннан оештыра. Бельгиянең Брюгге шәһәре ярлылары өчен хәйрия лотереясе була ул. Бөтен җыелган сумма хәйрия максатларында тотыла, рәссам хатыны үзенә оештыру чыгымнарын капларлык кына сумманы алып кала. Шул вакыттан бирле 24 февраль Лотерея туган көн буларак бөтен дөньяда билгеләп үтелә. Хәзер дәүләт лотереяләре нигездә намуслы уздырыла, әмма еш кына төрләре аны социаль максатларда файдалана һәм шактый гаҗәп шартлар уйлап таба. Мәсәлән, илдә бала тууны киметү максатыннан, 2011 елда Һиндстанда халыкның үзе теләп стерилизация ясатуда катнашуын арттыру өчен оештырыла – көнкүреш техникасы уйнатыла, төп приз исә машина була. Фәкыйрь катлам әлеге мөмкинлектән бик теләп файдалана. Тайваньдә исә экологларның креативлыгы хәттин аша: лотерея билетлары урамда йөрткәндә үз йорт хайваннарының нәҗесләрен җыештырып алучыларга бирелә. Тайбэй шәһәрендә бик күп бүләк уйнатыла, өч төп приз исә бигрәк тә саллы була: 12 мең, 18 мең һәм 60 мең долларлык саф алтын коелмасы! Хайван асрамаучы халык та читтә калмый – шәһәр экологиясен бозучыны фотога төшереп хакимияткә күрсәтүчеләргә дә билет бирелә. Отыш намуслы оештырыла, шәһәр исә тиз арада чистарып кала.

(“Die Presse”).

Кайнар чишмәле комлык

Яңа Зеландиянең көнчыгыш яр буендагы Коромандел ярымутравы комлыгына туристлар һәм җирле халык көн саен көрәк күтәреп килә, чөнки бу урын уникаль сәламәтләндерү үзәге булып тора. Бирегә океан яры “Кайнар чишмәле комлык” дип атала да. Ком астында, йөзләрчә метр тирәнлектә, бик югары температуралы кыя урнашкан, аңардан кайнар чишмәләр бәреп чыга. Җир өстенә килеп җиткәндә, су уртача 64 градуска кадәр суына һәм яр буендагы комны җылыта. Океан суы чигенгәндә, кешеләр көрәк белән үзләренә мини-бассейн казый һәм кайнар суга кереп ята, үзенә кирәкле җылылыкны аяк табанын комга тыгып карап билгеләргә була. Гейзерлардан агып чыккан су төрле микроэлементларга искиткеч бай. Кайнар суы чокырда ятканда, әледән-әле дулкын кага һәм салкынча су белән коендыра. Океан суы кире үз урынына кайтканда, дулкыннар кеше казыган чокырларны ярты сәгать эчендә тигезли дә куя, табигатькә берниди зыян килми. Әлеге комлыкта елның теләсә кайсы вакытында шулай бушлай дәваланырга була.

(“Вокруг света”).



Ай бормалы, бормалы...

Дөньяда иң бормалы урам – Ломбард-стрит. Ул АКШ ның Сан-Франциско шәһәрендәге Рус калкулыгында урнашкан. Җиһандагы иң кәкре урамны күреп хозурланырга теләгән һәркем озакламый пошлина түләргә мөмкин. Нибары 400 метр озынлыктагы сигез борылышлы юл туристлар арасында шулкадәр популяр ки, хәтта бу аның янәшәсендәге йортларда яшәүчеләргә шактый кыенлык тудыра икән. Шәһәр хакимияте, машина белән әлеге юлдан үтәргә ниятләүчеләрдән 10 доллар акча алу бирәдәге бөкедән һәм артык каты тавыштан котылырга булышыр, дип өметләнә.

(“Batona.net”).

Газета өчен Алсу ЗӘЙДУЛЛИНА әзерләде.

Дүшәмбе

31 июль

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
6.00, 7.10 «Манзара». 16+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 16+
8.10 «Здравствуйте!» 16+
9.00, 16.30 «КИТӘМ, ДИМӘ». 16+
10.00, 23.30 «УЧИТЕЛЯ». 16+
11.00 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+
11.30 «Заман көзгесе». 6+
12.00, 22.30 «ЧЕМПИОННАР ӘНИЛӘРЕ». 16+
13.00 «Семь дней». 16+
14.00, 0.25 «Соотечественники». 16+
14.45 «Музыкаль мәйдан». 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә». «Акыл батл».
16.00 «Переведи!» 6+
17.30 «Трибуна «Нового века». 16+
19.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.00 «Туган авылым». 12+
20.15 «Күчтәнәч».
21.00 «Ватандашлар». 16+
22.00 «Реальная экономика». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.00 «Халкым минем». 12+
5.40 «Ватандашлар». 16+
6.00, 13.05 «Манзара». 16+
8.00 «Үткәннәр сагындыра». 12+
8.40, 18.20, 23.10 «Башваткыч». 12+
9.50 «Семь дней». 16+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
11.30 «Родная земля». 12+
12.05 «Йөрәктән-йөрәккә». Роберт Миңнуллин турында телеочерк. 16+
15.30 «Әдәби хәзинә». 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
16.30 «Йөрәктән-йөрәккә». Илфак Ибраһимов турында телеочерк. 16+
17.30 «Яшьләр тукталышы». 6+
19.10, 22.15 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+
19.30 «Калеб». 6+
20.00 «Заман көзгесе». 6+
20.30 «Таяну ноктасы». 16+
21.25 «Әниемнең җылы кочагы». 16+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «ЗАГОВОРЕННЫЙ». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «КОТОВСКИЙ». 16+
11.30 «НАРУШЕНИЕ ПРАВИЛ». 12+
12.30, 18.30 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «ЦАРЕВНА ЛЯГУШКИНА». 12+
14.35 «Культурное наследие России». 12+
15.00 «Энциклопедия загадок». 12+
15.30 «Русский след Ковчега Завета». 12+
16.20 «ПЛЮС ЛЮБОВЬ». 16+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.50 «Короче говоря». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20, 0.40 «АнтиФейк». 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50, 12.15, 15.15, 16.50, 18.30 Информационный канал. 16+
16.00 «Мужское/Женское». 16+
19.55 «Куклы наследника Тутти». 16+
21.00 «Время».
22.00 «КАЗАНОВА». 16+
23.00 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «ГОДУНОВ». 16+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «ЛОВЕЦ СНОВ». 12+
23.15 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30 «Пешком...»
7.05 «Любовь Соколова. Своя тема».
7.50, 15.50 «Океан надежд».
8.30 «Жизнь и судьба».
8.50 «ЛЕВ УШЕЛ ИЗ ДОМА».
10.00, 12.30, 17.00, 19.30 Новости культуры.
10.15 «РИМЛЯНКА».
11.45 «Осовец. Крепость духа».
12.45 Моя любовь - Россия! «К северу от Оймякона».
13.15 «Легкое сердце живет долго».
13.55 «Забытое ремесло».
14.10 «Святыни Кремля».
14.40 «ЛИЧНОЕ СЧАСТЬЕ».
16.30 «Франция. Замок Шенонсо».
17.15 Концерт «Ромео и Джульетта».
18.25 «Императрицы Древнего Рима: женщины на вершине власти».
19.45 «Хранитель».
20.45 «Спокойной ночи, малыши!»
21.00 Спектакль «Дядя Ваня».
23.45 «СПРУТ-3».

«НТВ»

5.00 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 12+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «ЛЕСНИК». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «СКОРАЯ ПОМОЩЬ». 16+
16.45 «ЗИМОРОДОК». 16+
20.00, 0.00 «МЕНТОВСКИЕ ВОЙНЫ». 16+

Сишәмбе

1 август

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
6.00, 7.10 «Манзара». 16+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 16+
8.10 «Здравствуйте!» 16+
9.00, 17.00 «КИТӘМ, ДИМӘ». 16+
10.00, 23.00 «УЧИТЕЛЯ». 16+
11.00 «Фолиант в столетнем переплёте». 16+
11.15 «Память сердца». 16+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.00 «ЧЕМПИОННАР ӘНИЛӘРЕ». 16+
13.00 «Родная земля». 12+
13.30 «Юлчы». 16+
14.00 «Путь». 16+
14.15 «Не от мира сего...» 16+
14.45 «Музыкаль мәйдан». 16+
15.15 «Төймә».
16.00, 21.00 «Ватандашлар». 16+
18.00 «Әдәби хәзинә». 16+
19.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.00 «Туган авылым». 12+
20.15 «Күчтәнәч».

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.10 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00, 13.05 «Манзара». 16+
8.00 «Үткәннәр сагындыра». 12+
8.40, 18.20, 23.10 «Җырлыйк әле!» 12+
9.40 «Халык җырлары». 6+
10.30 «Заман көзгесе». 6+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
11.30 «Нәсыйхәт». 16+
12.05, 21.25 «Ком сәгате». 16+
15.30 «Әдәби хәзинә». 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
16.30, 20.30 «Таяну ноктасы». 16+
17.00 «Музыкаль мәйдан». 16+
17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
19.10, 22.15 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+
20.00 «Халкым минем». 12+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «ЗАГОВОРЕННЫЙ». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30 «КОТОВСКИЙ». 16+
11.30 «НАРУШЕНИЕ ПРАВИЛ». 12+
12.30, 18.30 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «ЦАРЕВНА ЛЯГУШКИНА». 12+
14.35 «Архивы истории». 12+
15.00 «Энциклопедия загадок». 12+
15.30 «Афганистан 1979 - 1989». 12+
16.30 «СОЛНЦЕ В ПОДАРОК». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.50 «Короче говоря». 16+
20.00 «ЧЕРНЫЕ ВОЛКИ». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20, 0.00 «АнтиФейк». 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50, 12.15, 15.15, 16.50, 18.30 Информационный канал. 16+
16.00 «Мужское/Женское». 16+
19.55 «Куклы наследника Тутти». 16+
21.00 «Время».
22.00 «КАЗАНОВА». 16+
23.00 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «ГОДУНОВ». 16+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «ЛОВЕЦ СНОВ». 12+
23.15 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30 «Пешком...»
7.05 Легенды мирового кино.
7.35 «Первые в мире».
7.50, 15.50 «Власть над климатом».
8.30 «Жизнь и судьба».
8.50 «ЛЕВ УШЕЛ ИЗ ДОМА».
10.00, 12.30, 17.00, 19.30 Новости культуры.
10.15 100 лет со дня рождения Валентины Леонтьевой. XX век. «От всей души. Ростовские встречи».
11.30, 23.45 «СПРУТ-3».
12.45 Моя любовь - Россия!
13.10, 18.25 «Императрицы Древнего Рима: женщины на вершине власти».
14.10 «Святыни Кремля».
14.40 «ЛИЧНОЕ СЧАСТЬЕ».
16.30 «Князь Потёмкин. Свет и тени».
17.15 Владимир Федосеев и Большой симфонический оркестр имени П.И. Чайковского.
18.10 «Забытое ремесло».
19.45 «Космический рейс. Миссия на Марс».
20.45 «Спокойной ночи, малыши!»
21.00 Спектакль «Мнимый больной».
23.20 «Нижний Новгород. Усадьба Рукавишниковых».

«НТВ»

4.55 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 12+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «ЛЕСНИК». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «СКОРАЯ ПОМОЩЬ». 16+
16.45 «ЗИМОРОДОК». 16+
20.00, 0.00 «МЕНТОВСКИЕ ВОЙНЫ». 16+

Чәршәмбе

2 август

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
6.00, 7.10 «Манзара». 16+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 16+
8.10 «Здравствуйте!» 16+
9.00, 17.00 «КИТӘМ, ДИМӘ». 16+
10.00, 23.00 «УЧИТЕЛЯ». 16+
11.00, 0.00 «Каравай». 6+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.00 «ЧЕМПИОННАР ӘНИЛӘРЕ». 16+
13.00 «Җырлыйк әле!» 12+
14.00, 20.00 «Туган авылым». 12+
14.15 «Если хочешь быть здоровым». 16+
14.45 «Музыкаль мәйдан». 16+
15.15 «Бергәләп өйрәник».
16.00 «Переведи!» 6+
18.00 «Халкым минем…». 12+
19.00, 0.50 «Таяну ноктасы». 16+
20.15 «Күчтәнәч».
21.00, 0.25 «Соотечественники». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.10, 8.40, 18.20, 23.10 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00, 13.05 «Манзара». 16+
8.00 «Үткәннәр сагындыра». 12+
9.40 «Йөрәктән - йөрәккә». Шәүкәт Галиев турында телеочерк. 16+
10.40 «Туган авылым». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 21.25 «Кунак БИТ Шоу». 16+
15.30 «Әдәби хәзинә». 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
16.30, 20.30 «Таяну ноктасы». 16+
17.00 «Музыкаль мәйдан». 16+
19.10, 22.20 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+
20.00, 0.15 «Гаилә учагы». 16+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30 «ЗАГОВОРЕННЫЙ». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ЧЕРНЫЕ ВОЛКИ». 16+
11.30 «НАРУШЕНИЕ ПРАВИЛ». 12+
12.30, 18.30 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «ОХОТНИКИ ЗА КАРАВАНАМИ». 16+
14.45 «География вкуса». 12+
15.00 «Энциклопедия загадок». 12+
15.30 «Афганистан 1979 - 1989». 12+
16.30 «СОЛНЦЕ В ПОДАРОК». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.50 «Короче говоря». 16+
23.00 «ЛЕКАРСТВО ПРОТИВ СТРАХА». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20, 0.00 «АнтиФейк». 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50, 12.15, 15.15, 16.50, 18.30 Информационный канал. 16+
16.00 «Мужское/Женское». 16+
19.55 «Куклы наследника Тутти». 16+
21.00 «Время».
22.00 «КАЗАНОВА». 16+
23.00 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «ГОДУНОВ». 16+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «ЛОВЕЦ СНОВ». 12+
23.15 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30 «Пешком...»
7.05 Легенды мирового кино.
7.35 «Первые в мире».
7.50, 15.50 «О, спорт! Чем станешь ты?»
8.30 «Жизнь и судьба».
9.00 «КАК МЫ ИСКАЛИ ТИШКУ».
10.00, 12.30, 17.00, 19.30 Новости культуры.
10.15, 18.10 «Забытое ремесло».
10.35 «СПРУТ-3» 6, 7 с.
12.45 Моя любовь - Россия! «Лики невьянской иконы».
13.10, 18.25 «Императрицы Древнего Рима: женщины на вершине власти».
14.10 «Святыни Кремля».
14.40 «ЛИЧНОЕ СЧАСТЬЕ».
16.30 «Князь Потёмкин. Свет и тени».
17.15 Владимир Федосеев и Большой симфонический оркестр имени П.И. Чайковского. П.И. Чайковский.
19.45 «Третий командующий. Иван Затевахин».
20.45 «Спокойной ночи, малыши!»
21.00 Спектакль «Двенадцатая ночь».

«НТВ»

4.45 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 12+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «ЛЕСНИК. СВОЯ ЗЕМЛЯ». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «СКОРАЯ ПОМОЩЬ». 16+
16.45 «ЗИМОРОДОК». 16+
20.00, 0.00 «МЕНТОВСКИЕ ВОЙНЫ». 16+

Пәнҗешәмбе

3 август

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
6.00, 7.10 «Манзара». 16+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 16+
8.10 «Здравствуйте!» 16+
9.00, 16.30 «КИТӘМ, ДИМӘ». 16+
10.00, 23.00 «УЧИТЕЛЯ». 16+
11.00 «Каравай». 6+
11.30, 16.00 «Татарлар». 12+
12.00, 22.00 «ЧЕМПИОННАР ӘНИЛӘРЕ». 16+
13.00 «Кәмит Җәвит». 16+
14.00, 20.00 «Туган авылым». 12+
14.15 «Классный час». 16+
14.45 «Музыкаль мәйдан». 16+
15.15 «Шома бас» һәм «Алты хәреф».
17.30 «Точка опоры». 16+
19.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.15 «Күчтәнәч».
21.00 «Погружение на 100». 12+
21.10, 0.25 «Соотечественники». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.10 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00, 13.05 «Манзара». 16+
8.00 «Үткәннәр сагындыра». 12+
8.40, 23.10 «Кәмит Җәвит». 16+
9.40 «Гаилә учагы». 16+
10.40 «Туган авылым». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 20.00 «Әниемнең җылы кочагы». 16+
15.30 «Әдәби хәзинә». 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
16.30 «Таяну ноктасы». 16+
17.00 «Музыкаль мәйдан». 16+
18.20 «Кунак БИТ Шоу». 16+
19.15, 22.15 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+
21.25 «Рухының - үз күге». Равил Фәйзуллин турында телеочерк. 16+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «ЛЕКАРСТВО ПРОТИВ СТРАХА». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ЧЕРНЫЕ ВОЛКИ». 16+
11.30 «ОТЕЛЬ «ПРЕЗИДЕНТ». 12+
12.30, 18.30 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «ОХОТНИКИ ЗА КАРАВАНАМИ». 16+
14.45 «География вкуса». 12+
15.00 «Энциклопедия загадок». 12+
15.30 «Афганистан 1979 - 1989». 12+
16.30 «СОЛНЦЕ В ПОДАРОК». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.50 «Короче говоря». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20, 0.00 «АнтиФейк». 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50, 12.15, 15.15, 16.50, 18.30 Информационный канал. 16+
16.00 «Мужское/Женское». 16+
19.55 «Куклы наследника Тутти». 16+
21.00 «Время».
22.00 «КАЗАНОВА». 16+
23.00 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+

11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «ГОДУНОВ». 16+
16.30 «Прямой эфир». 16+
21.20 «ЛОВЕЦ СНОВ». 12+
23.15 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30 «Пешком...»
7.05 Легенды мирового кино.
7.35 «Первые в мире».
7.50, 15.50 «Космические спасатели».
8.30 «Жизнь и судьба».
8.50 «КАМИЛА».
10.00, 12.30, 17.00, 19.30 Новости культуры.
10.15 «Нижний Новгород. Усадьба Рукавишниковых».
10.50, 23.45 «СПРУТ-4».
12.45 Моя любовь - Россия!
13.10 «Императрицы Древнего Рима: женщины на вершине власти».
14.10 «Святыни Кремля».
14.40 «ЛИЧНОЕ СЧАСТЬЕ».
16.30 «Князь Потёмкин. Свет и тени».
17.15 Владимир Федосеев и Большой симфонический оркестр имени П.И. Чайковского. И. Брамс. Симфония №4.
18.00 100 лет со дня рождения Вадима Коростылева. Острова.
18.40 «Елизавета I: королева-убийца?»
19.45 «Между двух бездн».
20.45 «Спокойной ночи, малыши!»
21.00 Спектакль «№13».
23.05 «Кинескоп».

«НТВ»

4.55 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 12+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «ЛЕСНИК. СВОЯ ЗЕМЛЯ». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «СКОРАЯ ПОМОЩЬ». 16+
16.45 «ЗИМОРОДОК». 16+
20.00, 0.00 «МЕНТОВСКИЕ ВОЙНЫ». 16+

Җомга

4 август

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
6.00, 7.10 «Манзара». 16+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 16+
8.10 «Здравствуйте!» 16+
9.00, 17.00 «КИТӘМ, ДИМӘ». 16+
10.00 «Йөрәктән - йөрәккә». 16+
11.00 «Нәсыйхәт». 16+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00 «Ком сәгате». 16+
13.00 «Башваткыч». 12+
14.00 «Актуальный ислам». 16+
14.15 «Здоровая семья: мама, папа и я». 12+
14.45 «Музыкаль мәйдан». 16+
15.15 «Тизрәк! Алга! Җитезрәк!» һәм «Алты хәреф».
16.00 «Әдәби хәзинә». 6+
18.00 «Туган җир». 12+
19.00 «Болгар радиосы» концерты. 16+
20.00 «Туган авылым». 12+
20.15 «Көчтәнәч».
21.00 «Юлчы». 16+
22.00 «ДЕЖА ВЮ». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.10 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00, 13.05 «Манзара». 16+
8.00 «Үткәннәр сагындыра». 12+
8.50, 18.20, 23.10 «Ком сәгате». 16+
9.50, 16.30, 0.15 «Нәсыйхәт». 16+
10.30 «Татар халык җырлары». 6+
11.00, 15.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 21.25 «Рухиның - үз күге». Равил Фәйзуллин турында телеочерк. 16+
15.30 «Әдәби хәзинә». 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.00 «Музыкаль мәйдан». 16+
18.00 «Яңалыклар». 12+
19.15, 22.20 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+
20.00 «Туган җир». 12+
20.30 «Таяну ноктасы». 16+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «ЛЕКАРСТВО ПРОТИВ СТРАХА». 16+
9.25, 11.25, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ЧЕРНЫЕ ВОЛКИ». 16+
11.30 «ОТЕЛЬ «ПРЕЗИДЕНТ». 12+
12.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00, 23.45 «МУЗЫКА КРЫШ». 16+
14.30 «Архивы истории». 12+
15.00 «Энциклопедия загадок». 12+
15.30 «Афганистан 1979 - 1989». 12+
16.30 «СОЛНЦЕ В ПОДАРОК». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.20 «Fam TV». 16+
18.50 «Короче говоря». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50, 12.15, 15.15, 16.50, 18.35 Информационный канал. 16+
16.00 «Мужское/Женское». 16+
19.50 «Поле чудес».
21.00 «Время».
21.45 Музыкальный фестиваль «Жара». Юбилейный вечер Олега Газманова. 16+
23.15 «ВИЛЛА «КАПРИЗ». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.40, 21.15 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
15.05 «Странная война». 16+
16.30 «Прямой эфир». 16+
21.30 «Удивительные люди. Лучшее». 12+
23.55 «РОДНЫЕ ДУШИ». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30 «Пешком...»
7.05 Легенды мирового кино.
7.35 «Первые в мире».
7.50, 15.50 «Куда ведут железные дороги».
8.30 «Жизнь и судьба».
8.50 «КАМИЛА».
10.00, 12.30, 17.00, 19.30 Новости культуры.
10.15 «Одинцово. Васильевский замок».
10.50, 23.50 «СПРУТ-4».
12.45 Моя любовь - Россия! «О чем мечтают абазины?»
13.15 «Елизавета I: королева-убийца?»
14.10 «Святыни Кремля».
14.40 «ЛИЧНОЕ СЧАСТЬЕ».
16.30 «Князь Потёмкин. Свет и тени».
17.15 Владимир Федосеев и Большой симфонический оркестр имени П.И. Чайковского. Шедевры мировой оперы.
18.45 «Повелитель гироскопов. Александр Ишлинский».
19.45 «Смехоностальгия».
20.15 К 75-летию Вячеслава Гордеева.
21.10 «Цирк». Я хотела быть счастливой в СССР!» Авторский фильм Александра Казакевича.
21.50 «ЦИРК».
23.20 «Вологда. Усадьба Брянчаниновых».

«НТВ»

4.45 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 12+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00 «Сегодня».
8.25, 10.35 «ЛЕСНИК. СВОЯ ЗЕМЛЯ». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «СКОРАЯ ПОМОЩЬ». 16+
16.45 «ЗИМОРОДОК». 16+
20.00 «МЕНТОВСКИЕ ВОЙНЫ». 16+
0.00 «Авторитеты». 16+

Шимбә

5 август

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
6.00 «Йөрәктән - йөрәккә». 16+
7.00 «Сиңа Миннән Сәлам». 16+
9.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
10.00 «Кайнар хит». 16+
11.00 «Туган авылым». 12+
11.20 «Ничек сезнең хәлләрегез?» Зәйнәб Фәрхетдинова. 12+
12.00 «Каравай». 6+
12.30 «Видеоспорт». 16+
13.00 «Соотечественники». 16+
13.30 «Гаилә учагы». 16+
14.00 Спектакль «Йөзек кашы». 16+
16.30 «Уроки истории». 6+
17.30 «Әдәби хәзинә». 6+
18.00 «Кәмит Җәвит». 16+
19.00 «Халкым минем...» 12+
19.30, 21.30 Новости в субботу. 16+
20.00 «Ватандашлар». 16+
20.30 «Җырлыйк әле!» 12+
22.00 «КунакБит-шоу». 16+
23.00 «ВЕК АДАЛИН». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.10 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00 «Әдәби галәмгә тәрәзә». Фәрваз Миңнуллин истәлегенә багышланган телеочерк. 16+
7.00, 15.00 «Сиңа Миннән Сәлам». 16+
9.00 «Кунак БИТ Шоу». 16+
10.00 «Кайнар хит». 16+
11.00, 18.15 «Башваткыч». 12+
12.05, 19.05 «Җырлыйк әле!» 12+
13.00 «Туган авылым». 12+
13.20 «Китмә, сандугач». Илһам Шакиров ядкәре. 16+
17.15 «Казаннан казанга». 16+
17.45 «Халкым минем». 12+
20.00 Зөфәр Хәйретдиновның 60 яшьлек юбилей кичәсе. 16+
22.50 Спектакль «Син бит минем бергенәм». 16+

«ЭФИР»

5.00 «Архивы истории». 12+
5.25 «Земля людей». 12+
5.50 «Легенды кино». 16+
6.30, 14.20 «Театральное закулисье». 12+
7.00 «Смешарики».
7.30 «Фиксики».
8.00 «Круиз-контроль». 12+
8.30 «География вкуса». 12+
8.45 «СВОДНЫЕ СУДЬБЫ». 12+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «АМЕРИКАНСКИЙ ДЕДУШКА». 16+
14.50 «Александр Третий. Сильный, державный...». 12+
15.45 «ЯЩИК ПАНДОРЫ». 16+
19.00 «Город». 16+
21.00 «КРУПНЫЙ КАЛИБР». 16+
22.50 «ИНДИЙСКОЕ ЛЕТО». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

6.00 «Доброе утро. Суббота».
9.45 «Слово пастыря».
10.00, 12.00, 18.00 Новости.
10.15 К 100-летию Валентины Леонтьевой. «Объяснение в любви». 12+
11.10 «Поехали!» 12+
12.15 День Анатолия Папанова. «Надо просто любить и верить». 12+
13.15 «ПРИХОДИТЕ ЗАВТРА...»
15.10 Анатолий Папанов. «Ну, погоди!»
16.00 «ХОЛОДНОЕ ЛЕТО ПЯТЬДЕСЯТ ТРЕТЬЕГО...» 16+
18.20 «Поле чудес».
19.55 «Кто хочет стать миллионером?»
21.00 «Время».
21.35 «Сегодня вечером». 16+
23.30 «ЭВИТА». 12+

«РОССИЯ»

5.00 «Утро России. Суббота».
8.00 Вести. Местное время.
8.20 Местное время. Суббота.
8.35 «По секрету всему свету».
9.00 «Формула еды». 12+
9.25 «Пятеро на одного».
10.10 «Сто к одному».
11.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.55 «ЦЫГАНСКОЕ СЧАСТЬЕ». 12+
15.05 «Петросян-шоу». 16+
17.50 «Привет, Андрей!» 12+
21.00 «ВОСПИТАТЕЛЬНИЦА». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30 «Библейский сюжет».
7.05 Мультфильмы.
8.00 «ЦИРК».
9.30 «Классная тема!»
10.00, 19.30 Новости культуры.
10.15 Тайны старого чердака. «Как художники всё изменили».
10.45 К 100-летию со дня рождения Вадима Коростылева. Острова.
11.20 «ЗДРАВСТВУЙТЕ, ВСЕ!»
13.30 Неизвестные маршруты России. «Кабардино-Балкария. От Нальчика до Джилы-Су».
14.10 «Серенгети».
15.05 Большой балет.
17.10 «Вологда. Усадьба Брянчаниновых».
17.40 «БРАВИССИМО».
19.45 «Эстрада, которую нельзя забыть».
20.30 «ГОНКИ ПО ВЕРТИКАЛИ».
23.50 «Одинцово. Васильевский замок».

«НТВ»

5.20 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 12+
8.00, 10.00, 16.00, 19.00 «Сегодня».
8.25 «Поедем, поедим!» 16+
9.25 «Едим дома».
10.20 «Главная дорога». 16+
11.00 «Живая еда». 12+
12.00 «Квартирный вопрос».
13.00 «Секрет на миллион». 16+
15.00 «Своя игра».
16.20 «Следствие вели...» 16+
19.25 «ПРОСТО ДЖЕКСОН». 16+
21.15 «МЕНТОВСКИЕ ВОЙНЫ. ЭПИЛОГ». 16+
23.20 «Маска». 12+

Якшәмбе

6 август

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
6.00 «Сынатмыйк яшик!» Илсур Сафинның 60 яшьлек юбилей кичәсе. 16+
8.30 Мультфильмы.
8.45 «Әти һәм мин».
9.15 «Тамчы- шоу».
9.45 «Яшьләр тукталышы».
10.15 «Ачыктан ачык». 16+
11.20 «Туган авылым». 12+
11.20 Концерт «Бир кулыңны». 12+
12.00 «Каравай». 6+
12.30 «Татар халык җырлары».
13.00 «Ватандашлар». 16+
13.30 «Погружение на 100». 12+
13.40 «ЯЗМЫШЛАРДАН УЗМЫШ ЮК ИКӘН». 16+
15.00 «Әниемнең җылы кочагы». 16+
16.00 «Ком сәгате». 16+
17.00 «Видеоспорт». 16+
17.30 «Соотечественники». 16+
18.00 «Башваткыч». 12+
19.00, 22.00 «Семь дней». 16+
20.00 «Заман көзгесе». 6+
20.30 «Болгар радиосы» концерты. 16+
21.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
23.00 «ЖИВИ СВОЕЙ ЖИЗНЬЮ». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05, 12.35 «Халкым минем». 12+
5.30 «Нәсыйхәт». 16+
6.00 «Заман көзгесе». 6+
6.30 «Шаян хәлләр». 16+
7.00 «Күңел эретерлек сүзләр бар». Гөлүсә Шаһбанның иҗат кичәсе. 16+
9.00 «Йөрәктән - йөрәккә». 16+
10.00 «Әдәби хәзинә». 6+
10.30 «Калеб». 6+
11.10 «Тамчы-шоу». 6+
11.40 «Бергәләп өйрәник». 6+
12.05, 0.40 «Яшьләр тукталышы». 6+
13.00 «Туган авылым». 12+
13.20 «Гаилә учагы». 16+
13.50 «Үткәннәрдән киләчәккә сезнең белән якынлап барам». Хәния Фәрхи. 16+
16.20, 21.00 «Әниемнең җылы кочагы». 16+
17.15 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
18.10 «Кәмит Җәвит». 16+
19.05, 23.50 «Ком сәгате». 16+
20.00 «Семь дней». 16+
21.50 Спектакль «Ул бит кичә иде». 16+

«ЭФИР»

5.00 «Архивы истории». 12+
5.25 «Земля людей». 12+
5.50 «Легенды телевидения». 12+
6.30 «Театральное закулисье». 12+
7.00 «Смешарики».
7.30 «Фиксики».
8.00 «Круиз-контроль». 12+
8.30 «География вкуса». 12+
8.45 «ЯЩИК ПАНДОРЫ». 16+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «ПАСПОРТ». 6+
14.40 «Пять причин поехать...» 12+
14.50 «Блин. Ком». 16+
15.45 «СВОДНЫЕ СУДЬБЫ». 12+
19.00 «Город». 16+
21.00 «ЛЕОПАРД». 12+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

6.00, 10.00, 12.00, 18.00 Новости.
6.10 Подкаст.лаб «Космические истории». 16+
6.55 «Играй, гармонь любимая!» 12+
7.40 «Часовой». 12+
8.10 «Здоровье». 16+
9.20 «Мечталлион». 12+
9.40 «Непутевые заметки». 12+
10.15 Жанна Бадоева в проекте-путешествии «Жизнь других». 12+
11.10 «Повара на колесах». 12+
12.15 День десантника. «Часовой». 12+
12.45 «Вяземский десант. Боевое крещение». 16+
13.40 «В ЗОНЕ ОСОБОГО ВНИМАНИЯ». 12+
15.30 «ОТВЕТНЫЙ ХОД». 12+
17.05 «Герои. Десант на линии огня». 16+
19.00 «Три аккорда». 16+
21.00 «Время».
22.35 «СЕРЕБРЯНЫЙ ВОЛК». 16+
23.35 Подкаст.лаб «Мелодии моей жизни». 16+

«РОССИЯ»

6.10 «СОСЕДИ ПО РАЗВОДУ». 12+
8.00 Местное время. Воскресенье.
8.35 «Когда все дома с Тимуром Кизяковым».
9.25 «Утренняя почта с Николаем Басковым».
10.10 «Сто к одному».
11.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.55 «ЦЫГАНСКОЕ СЧАСТЬЕ». 12+
15.05 «Петросян-шоу». 16+
17.50 «Песни от всей души». 12+
22.00 «Воскресный вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 10.45 Мультфильмы.
7.25 «ПОВОД».
9.35 Диалоги о животных.
10.15 Тайны старого чердака. «Что из этого получилось?»
11.20 «ДУША ПИРАТА».
12.45 Человеческий фактор. «Сельский блогер».
13.15 «Охотники за охотниками».
14.00 «Игра в бисер» «Оскар Уайльд. «Портрет Дориана Грея».
14.40 Спектакль «Портрет Дориана Грея».
17.10 «Дороги Анатолия Новикова».
18.00 «Нам дороги эти позабыть нельзя...»
19.30 Новости культуры.
19.45 «ВРЕМЯ ДЛЯ РАЗМЫШЛЕНИЙ».
20.55 Шедевры мирового музыкального театра.
23.00 «КАК ВАМ ЭТО ПОНРАВИТСЯ».

«НТВ»

5.05 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 12+
8.00, 10.00, 16.00, 19.00 «Сегодня».
8.20 «У нас выигрывают!» 12+
10.20 «Первая передача». 16+
11.00 «Чудо техники». 12+
11.55 «Дачный ответ».
13.00 «НашПотребНадзор». 16+
14.00 «Однажды...» 16+
15.00 «Своя игра».
16.20 «Следствие вели...» 16+
19.45 «ЧЁРНЫЙ ПЁС-2». 16+
23.55 «Маска». 12+

Әҗәлгә таба адым

Сәрхүш ирләр белән иза чигеп яшәүче хатын-кызлар аз түгел. Еш кына газаплы тормыш гүзәл затлар өчен хәвефле тәмамлана. Кайвакыт бичара ханымнарның гомерләренә куркыныч янавын күрә торып соңгы чиккә кадәр җиткәнче араны өзмәүләренә, ул гына да түгел, явыз бәндәләрне яклап һәм аклап килүләренә гаҗәпләнергә дә туры килә.

Әлмәт кешесе Д.Хәбибуллин да өметсез ир-атлар рәтендә саналырга хаклы. 1987 елгы Денисның үткән тормышы, кылган гамәлләренә күз салгач, хәтта үз туганнары "шомартырга" тырышып сөйләгәннәр белән танышкач та, аның теләсә нинди явызлыкка сәләтле икәне күренә.

Бу җәһәттән, аның белән шактый вакыт газаплар күреп яши алган Ләйсәннең (кайбер исемнәр үзгәртелә) шомлы истәлекләренә тукталыйк. Алар 20-21 яшьләрендә үк язылышмыйча бергә тора башлый, Әлмәттә ир-егетнең әнисе фатирында гомер итәләр. 2012 елда уртак малайлары туа. Ләйсәннең әйтүенчә, Денис яшьтән үк хәмергә хирыслана, мин эчәргә һәм йокларга яратам, дип даими эшкә урнашмый, шабашкаларга йөргәли, еш кына юк сәбәпне бар итеп хатынны кыйный, этеп-төртеп кенә калмый, рәхимсез рәвештә тукмый.

Эчү генә түгел, ул "травка", "соли" дип йөртелгән наркотиклар куллана, дип шикләнүчеләр дә бар. 2015 ел башында шундый тилерткеч матдәләргә бәйле җинаять эшләгән өчен өч елга шартлы рәвештә ирегеннән мәхрүм ителә, әлеге хөкем таләпләрен үтәмичә төрле законсыз гамәлләр кылып йөргәч, өч елга колониягә озатыла. Аннан кайткач та инде Азнакайда яшәүче Ләйсән белән тагын кавышалар, балабыз булгач, гаиләне сакларга тырыштым, ди хатын – кыз. Ләкин тәртибе үзгәрми, малаен тәрбияләргә өлеш кертми хөрәсән. Ләйсән тагын күгәргән-шешенгән кыяфәт белән йөри башлагач, аны фатирына кертми, араны өзә, димәк.

Әмма котылдым дигәнне белдерми бу, малайны күрергә дигән булып сирәк-мирәк килгәли ир Азнакайга. 2018 елда да шул сылтау белән пәйда була, шунда кунарга да кала һәм төнлә белән хуҗабикәне аяусыз рәвештә кыйнарга керешә, имеш, аның телефонында башка ирләр белән язышкан язуларны күрә. Әгәр алты яшьлек улым уянып ашыгыч ярдәм чакырмаса үтергән булыр иде, ди Ләйсән. Шуннан соң бер айга якын сырхауханәдә ятып чыга, полициягә гариза да яза, ләкин суд утырышында итәгенә ут капкач мескенләнә белгән Д.Хәбибуллинны кызганып, аның гаебен киметеп һәм аклап сөйли, нәтиҗәдә, бары тик үтерү белән янауда гаепле, дип табылган явыз ир-ат сигез айлык шартлы хөкем белән котыла. Акылга утырмый, әлбәттә. Сарманда да хөкем ителә, узган ел Әлмәттә административ күзәтчелек таләпләрен үтәмәгән өчен өч ай утырып та чыга. Сүз уңаеннан искәртеп үтик, әнисенең әйтүенә караганда, Денисның этисе дә 14 ел гомерен колониядә уздырган, аны тәрбияләүдә катнашмаган, улы белән элек тә, соңгы вакытта да аралашмаган.

Алма агачыннан ерак төшми дигән әйтемдәгечә, Денис та тайгак юлдан китә. Без әйтеп узган җинаять һәм хөкемнәр алга таба булган хәлләр белән чагыштырганда вак-төяк кенә булып күренер һәм Азнакай кызы ошбу бәндәдән вакытында котылган, дигән фикер туар. Чөнки аннан соң пәйда булган ханым андый омтылышны ясап та карамый, тиздән җәзасын да ала.

Аңлашыла ки, эшлексез сәрхүшне юньле хатын-кыз якын җибәрмәячәк. Денисның ун яшькә өлкәнрәк яңа "сожительница"сы Надежда Носова да – эчү аркасында түбән тәгәрәгән зат. Беркайчан да гаиләсе, балалары булмаган аның. Әлмәттә өлкән яшьтәге этисе белән яшәгән, яшьрәк чагында дизайнер булып эшләгән, тора-бара сәрхүшлеккә чыккан, өлкән яшьтәге этисе белән аның пенсиясе хисабына көн күргән. Туганнарыннан бигрәк энесенең хатыны Марина, туганнан туган сеңлесе Карина, сирәк-мирәк кенә энесе Егор белән аралашкан.

Якыннары Надежданың күптәннән эчүен әйтә, ләкин Д.Хәбибуллин белән тора башлагач айнымаска әйләнде, диләр. Хәер, Денисның туганнары да аның эчкечелеккә бирелүен киленнән күрә. Ир кеше 1934 елгы әбисе һәм аның өлкән яшьтәге кызы белән бер фатирда яши.

Карчыклар икесе дә Денисны мактап бетерә алмый, әби кеше дару да алып кайта, миңа укол да кадый дип, аны "золотой мальчик" дип атый хәтта. "Алтын" егетнең кыланышлары турында күп сөйләргә була. Ул котырынып өйдәге әйберләрне туздыра башлагач, карчык Җәлил бистәсендә яшәүче кызына, ягъни Денисның әнисенә шалтырата, анысы полиция чакыртып китергәч, өйдәгеләр мәш килеп дуамал кешене якларга керешә. Күршеләр фатирда чырчу, бигрәк тә ир кеше акырган, пыяла чәлпәрәмә килгән тавышлар көн саен ишетелә, диләр, йорт җиһазларын җимерү, соңгы вакытта дүрт телевизорны ватуын әйтәләр. Төгәл санын каян белгәннәр дисәк, исерек бәндә аларны тәрәзәдән урамга томыра икән. Карчыкның юньсез оныкны яклау сәбәбе мәгълүм. Троллейбуста егылып бот сөяген сындыру сәбәпле инде биш ел урын өстендә ул. Шуңа күрә аны аңларга була, кайвакыт ярдәме тиеп куя торган ир кеше кирәк бит өйдә.

2021 елның җәендә фатирдагыларга Н.Носова да өстәлгәч, тавыш-гауга тагын да көчәя. Шундый ярсу егет булганда кычкырышулар – бәрелешүгә барып җиткән, төгәлрәге, хатын-кызның тетмәсен-тетеп ташлаган чаклар да була, билгеле. Сүз саулыкка җитди зарар китермәгән бәргәләүләр хакында гына түгел, 2021 елда Надеждага сәламәтлегенә авыр зыян салган очраклар да була. Гаҗәп, ләкин явыз бәндә җәзасыз калып килә. Төп сәбәп – зарар күргән ханымның гариза язып сөйгәнен утыртырга теләмәвендә. Аның болай кылануы полиция өчен дә кулай. "Алкашлар" бәрелеше буенча җинаять эше кузгатып мәшәкатьләнәсе юк бит.

Кыз туганнары Надежда тәнендәге күгәргән-шешкән урыннарны көйсез кияү белән кушылуына ике атна узгач ук күрә башлый. 2021 елның июлендә Марина кайнатасы фатирына килә, балконда сәләмә ирләр киеме кигән кайнапасының тәмәке көйрәтеп утыруын күрә. Аның кушуы буенча Надежда киемнәрен алыштырырга керешкәч, бипиһая күп суккан урыннар булу ачыклана, төпчекә торгач хатын-кыз моның кияү эше икәнен әйтә, полициягә хәбәр итәргә үгетләүләргә колак салмый, бары да әйбәт, ул мине ярата, ди. Ошбу "ярату" нәтиҗәсендә ул чакта аның дүрт кабыргасы чәрдәкләнеп сынган була. Сырхауханәгә бармаганга күрә, бу хакта шактый вакыт узгач кына мәгълүм була.

2021 елның 2 сентябрендә парлылар ир-атның элеккеге күршесе В.Ипеев фатирында бәйрәм итә. Сәрхүшләр мәҗлесендә хуҗа Викторның улы Денис, соңгысының 25 яшьлек сеңлесе һәм Илсур атлы тагын бер дуслары катнаша. Беренче көн ярыйсы гына тәмамлана, иртәгесен тегеләр тагын җыела, бераздан В.Ипеев белән Д.Хәбибуллин гына аякта кала, бүтәннәр йокларга түнә. Бер мәлне Денис котырынып хатынын уятырга керешә, ниятенә ирешә алмагач, аны бар көчен эшкә җигеп дөмбәсли, тамак чыгырдан чыгып үзен туктатырга тырышкан хуҗаны этеп-төртеп подъездга озата һәм ишекне бикләп куя. Абзый ике-өч сәгать буе, күршеләр чакырган полиция килеп җиткәнче, шунда оекчан басып тора. Шулай итеп Надежда "Татнефть" сырхауханәсенә эләгә. Аның яңак, борын сөякләре сынган, баш миенә зыян ясалган, кыскасы, сәламәтлегенә авыр зыян килгән булып чыга. Табибләр шулай ук аның дүрт кабыргасында төзәлеп килә торган сынган урыннарны да күрә. Болар – инде без югарыда телгә алган җәрәхәтләр, дип табыла. Сырхауханәдән хәбәр килгәч тә, анда полиция килеп җитә, әмма Н.Носова сөйгән ярына дәгъвам юк, дип аңлатмага имза сала, Д.Хәбибуллин да гаебен кире кага. Шул рәвешле ике авыр җинаять күләгәдә кала.

Бераз тернәкләнә башлагач та ханым тиз явыз янына кайта. Ул чакта 43 яшендә булган хатын-кызның ялгызлыктан котылырга теләве аңлашыла да кебек. Әмма гомерен, саулыгын куркыныч астына куеп ашкынуын сәрхүшлеккә сылтамый булмастыр. Марина, Карина һ.б. туганнары Сергей абзыйның кызы Надеждага эчәргә рөхсәт итмәвен, димәк, хәмергә акча бирмәвен әйтә, аның хәтта төнлә белән Денис янына качып китүләрен дә искә төшерә. Бу галәмәт, иң әүвәл, ике инвалид пенсионер карчыклар яшәгән фатирда тамак чылату мөмкинлеге булу белән аңлатыла.

Сәрхүш тормыш рәвешенең чираттагы нәтиҗәсе озак көттерми. Ике атна дигәндә авыр хәлдәге Н.Носова нейрохирургия бүлегенә салына, аңа "шунтирование" дигән катлаулы операция ясала. Чынлыкта, гарип калдырылган ханымны бичара этисе карый, кулдан ашата, артыннан җыештыра, кыз туганнарының "сиделка" яллаган чаклары да була. Бер айдан соң этисе фатирына кайтарылган ханымга алга таба еш кына ашыгыч ярдәм чакырырга туры килә. Чөнки аңын җуя, күзән җыерып тартышырга керешә, авызыннан күбек китә. Туганнары, өненә килсә Надежда үзе дә стационардан баш тарта.

Медицина кәгазьләрендә 2022 елның 10 мартында да табибләрнең укол кадап һәм авыруны йоклатып китүләре мәгълүм. Ошбу хәлләрнең Д.Хәбибуллин башка сугу нәтиҗәсе икәне табибләргә дә әйтелә, бу хакта полициядә дә беләләр. Сәер, ләкин котырынкы кеше иректә йөри бирә, төрле начарлыклар кылып җавапка тартыла, югарыда әйтелгәнчә, шул араларда өч ай төрмәдә утырып кайтырга да өлгерә. Иң гаҗәбе шунда ки, саулыгы азрак рәтләнә башлаган Надежда шул ук март аенда теге бәндә янына кайтып рәхәтләнкә, ягъни сәрхүшлеккә чума. Күрше карчыгы әйтмешли, фатирда "фильм ужасов " тагын башлана. Хатын-кызның әҗәлен таба атлаган соңгы адымы була бу. 2022 елның 14 июнендә ир кеше ашыгыч ярдәмгә "подругам" үлде, дип хәбәр итә. Табибләр Денис фатирындагы караватт белән стена арасындагы идәндә яткан Н.Носованың җансыз икәнен рәсмиләштерә.

Экспертиза мәрхүмнең баш миенә кан саву нәтиҗәсендә җан биргүен белдерә. Барысы да аерымачык кебек күренсә дә тикшерү озак бара. Чөнки Д.Хәбибуллин күрсәтмә бирүдән баш тарта, өйдәге әбиләр башка бүлмәдә идек, күрмәдек дип бара. Шулай да, фатирда башка кеше булганы юк дип, алар моның Денис эше икәненә ишарәли.

Тикшерү барышында Д.Хәбибуллин Н.Носова башына кимендә бер тапкыр суккан һәм бу үлемгә кадәр бер атна чамасы элек булган дип табыла. Димәк, хатын-кыз шактый вакыт өйдә газапланып яткан була. Әлбәттә, подъездда бер мәртәбә сугу гына түгел, алданрак тукмаулары нәтиҗәсе дә була бу. Моңа кадәр күләгәдә булган өч очракны да "казып" чыгарырга туры килә Тикшерү комитетының Әлмәт бүлегеннән Эмиль Солтановка.

Медицина документлары, шаһитлар күрсәтмәләре буенча Д.Хәбибуллинга 2021 елда кылынган кеше сәламәтлегенә авыр зыян китерү дигән өч җинаятьтә рәсми гаепләү белдерелә. Әлбәттә, ул аңлы рәвештә кеше үтерүдә дә гаепләнә.

Тикшерү барышында һәм суд утырышларында зарар күрүче буларак мәрхүмнең энесе Егор чыгыш ясый. Шаһитлар арасында гаилә башлыгы Сергей агай юк, чөнки ул кызының әҗәленнән соң тиз арада вафат була. Чынлыкта, әлеге яшәү рәвешенең аяныч нәтиҗәләре турындагы җинаять эшен Әлмәт шәһәр судында озак карала, 1987 елгы Денис Хәбибуллин дүрт җинаять кылуда гаепле дип табыла һәм 14 елга кырыс режимлы колониягә озатылырга тиеш, дигән хөкем карары игълан ителә.

Наил ВАХИТОВ.

Хикмәтле бизәкләр

Казан Кремлендәге Татарстан дәүләтчелеге музеенда бу көннәрдә гүзәл затлар аеруча күп, чөнки күптән түгел Санкт-Петербургтагы Россия этнография музее бирегә хатын-кызларның бизәнү әйберләрен алып килде.

Әлек хатын-кызның бизәнгечләренә карап җәмгыятьтәге урынын, гаилә хәлен белеп булган. Алка, беләзек, хаситәләр гүзәл затларны явыз рухлардан саклаган, тегe яки бу халыкның ышануларын гәүдәләндергән. Бүген кендек тиштереп, шәрә корсакларын, ярым ачык күкрәкләрен күрсәтеп йөрүче кызларыбызга элеккеге гадәтләрне белү файдалы булыр иде.

Ни кызганыч, җәмгыяттә хатын-кызга карата дөрес булмаган караш калыплашты. Күпләр өчен ул матур уенчык кына булып калды. Ир затлары, матуррак «уенчыкка» ия булып, үзләрен дәрәҗәле итеп күрсәтмәкче була. Шул ук вакытта гүзәл затларның чын асылы нәсел дәвам итү икәнен бөтенләй онытып бетердек. Төрле хаситә, билбаулар матурлык өчен генә түгел, нәселне барлыкка китерүче нәфис затларны саклау максатында кулланылган.

Кечкенә генә күргәзмәдә дөньядагы төрле халыкларның бизәнү сәнгатен тәкъдим иткәннәр. Биредә Идел буендагы төрки һәм фин-угор халыкларының алка, беләзекләре дә, Балтыйк буе һәм Көнбатыш-Себер зонасында яшәүчеләрнең зәркән сәнгате дә, Урта Азия, Казахстан гүзәлләренең бизәнгечләре дә, Урал һәм Ерак Көнчыгыш, Себер халыкларыныкы да урын алган. Бизәнгечләрнең эшләнү вакыты – XVIII гасырдан алып 2000 елларга кадәр. Оста зәркәнчеләр иҗат иткән эшләнмәләр дә, кыз-хатыннар кич утырып сәйләннәрдән үз куллары белән ясаган муенса, чулпылар да бар. Күргәзмәдәге экспонатларга карап, кайсы халык тимерне сәнгатьчә эшкәртүнең кайсы төрен яратарак төшкәне турында да фикер йөртергә мөмкин. Бүген зәркән сәнгате югалып барган заманда, элеккеге osталарның кул эшләрен халыкка күрсәтү аеруча әһәмиятле. Экспозициядәге фотосурәтләр аркылы тулы бизәнү комплексларын күзалларга мөмкин булуы да бик мөһим.

Күргәзмәдә баскетбол тубы кереп утырырлык җиз ләгән сыман бизәкле бер җиһаз күпләрнең игътибарын җәлеп итте. «Баш киеме ме бу, нәрсә бу?» – дип үзара фикер алыша матурлык күрергә килгән халык. Псков губернасы Печерски өязеннән күкрәк бизәге икән. «Сыльг»дип атала. XIX йөздә ханымнар күкрәкләрен калган сыман бизәнгечләр белән нык саклаган. Бүген буыннарның һаман сыеклана баруы ханымнарыбызның бер күнлек күбәләк сыман гамьсез яшәүләренең нәтиҗәсе түгелме икән?

Миләүшә ГАЛИУЛЛИНА.

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ –
«ТАТМЕДИА»
АКЦИОНЕРЛЫК ҖӘМГЫЯТЕ

«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы
директоры – баш мөхәррир

Вахит Шәих улы ИМАМОВ

Җаваплы сәркатип өчен
В. ИМАМОВ

Шылтыратыгыз:

222-09-83 (1562) – кабул итү бүлмәсе;

222-05-47 (1560) – җаваплы сәркатип, компьютер үзәге;

222-05-47 (1561) – иҗтимагый-сәяси тормыш, мәгариф һәм фән, сәнгать бүлекләре; хатлар һәм социаль көнкүреш, тәрҗемә бүлекләре;

222-09-84 (1266) – бухгалтерия.

**Реклама хезмәте телефоны:
(843)222-05-47 (1560)**

Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләр өлкәсенә күзәтчелек итү федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2019 елның 9 октябрендә ПИ №ФС 77–76961 нче санлы теркәү таныклыгы алды

Индекс П2355

Авторлар фикере редакция фикере белән аваздаш булмаска да мөмкин

Редакциянең рәсми оешмаларда юллаучы булып йөрү мөмкинлеге юк

Хатлар, кулъязмалар, фотографияләр, рәсемнәргә бәяләмә бирелми һәм алар кире кайтарылмый

© Газетада чыккан материалларны күчереп бастырганда редакциядән язмача рөхсәт алу мәҗбүри

Реклама һәм белдерүләрнең төгәллеге өчен реклама бирүчеләр үзләре җаваплы

Безгә иганәлек ярдәме күрсәтергә теләүчеләр өчен редакциянең исәп-хисап счеты:

**ИНН 1655144950 КПП 165802012
ПАО «АК БАРС» банк,
г. Казань
р/с 40702810600020010312
к/с 30101810000000000805
БИК 049205805 ОГРН 1021600000124**

**НӘШЕР ИТҮЧЕ –
«ТАТМЕДИА» АҖ**

420097, Казан, Академия урамы, 2

Редакция, гамәлгә куючы һәм басмаханәнең адресы:

420066, Казан,
Декабристлар урамы, 2

E-mail: m-jomga@mail.ru

**«Мәдәни җомга» газетасы Интернетта:
www.madanizhomga.ru**

Басмаханә гаебе белән җибәрелгән сыйфат җитешсезлекләре хакында 562-10-61 номерлы телефон буенча шылтыратырга

**Газета һәр атнаның җомга көнендә чыга.
Бу санның
чыгу көне 28.07.2023**

График буенча бу санга 15 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 14 сәгать 30 минутта.

«Татмедиа» АҖ филиалы – «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды

Газетаның сатудагы бәясе ирекле

Тираж – 2500 данә

Заказ 2628

16+